


# ГЕРОИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ГЕРОЙЛАРЫ

ОБЩЕСТВЕННАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ «ГЕРОИ ТАТАРСТАНА»
РЕДАКЦИЯ «КНИГА ПАМЯТИ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
АКАДЕМИЯ ВОЕННО-ИСТОРИЧЕСКИХ НАУК

**А.А. ИВАНОВ**

# ГЕРОИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

КАЗАНЬ
РЕДАКЦИЯ «КНИГА ПАМЯТИ»
2012

«ТАТАРСТАН ГЕРОЙЛАРЫ» ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ «ХӘТЕР КИТАБЫ» РЕДАКЦИЯСЕ
ХӘРБИ-ТАРИХИ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

**А.А. ИВАНОВ**

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ГЕРОЙЛАРЫ

КАЗАН
«ХӘТЕР КИТАБЫ» РЕДАКЦИЯСЕ
2012

УДК 94(470.41)(092)
ББК 63.3(2Рос.Тат.)-8
Г39

Государственная программа
«Патриотическое воспитание граждан Российской Федерации на 2011–2015 г.г.»

Республиканская программа
патриотического воспитания молодежи Республики Татарстан на 2011–2013 гг.

Иванов А.А.
Г39 **Герои Российской Федерации.** Сборник очерков/А.А. Иванов.– Казань, Редакция «Книга Памяти», 2012. – 192 с.
ISBN 978-5-900018-23-2

Эта книга – знак благодарности и восхищения Героями Российской Федерации, до конца выполнившими свой гражданский и воинский долг. На ее страницах – очерки об уроженцах Республики Татарстан, тех, кто учился в военных и гражданских учебных заведениях Казани, героях-татарах из регионов страны.

УДК 94(470.41)(092)
ББК 63.3(2Рос.Тат.)-8

ISBN 978-5-900018-23-2

©Иванов А.А., 2012

**Звание**
**ГЕРОИ РОССИИ**
**установлено**
**Законом Российской Федерации**
**от 20 марта 1992 года № 2553-1**
**Знак особого отличия – медаль «Золотая Звезда»**



Закон Российской Федерации
об установлении звания Героя Российской Федерации
и учреждения знака особого отличия –
медали «Золотая Звезда»
Верховный Совет Российской Федерации постановляет:
Установить звание Героя Российской Федерации
для присвоения за заслуги перед государством и народом,
связанные с совершением геройского подвига.
В целях особого отличия граждан, удостоенных звания
Героя Российской Федерации, учредить знак особого отличия –
медаль «Золотая Звезда».
Утвердить Положение о звании Героя Российской Федерации.
Утвердить описание медали «Золотая Звезда».

Президент Российской Федерации
Б. ЕЛЬЦИН

Москва, Дом Советов
20 марта 1992 года
№ 2553-1


БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЧЫЛАРГА
ТИРӘН ИХТИРАМ БЕЛӘН ТАТАРСТАН ХАЛКЫННАН
ОТ БЛАГОДАРНОГО НАРОДА ТАТАРСТАНА-
УЧАСТНИКАМ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ



Советлар Союзы Геройлары
1941-1945
Герои Советского Союза



Президент Республики Татарстан
**Рустам Минниханов**

Татарстан Республикасы Президенты
**Рөстәм Миңнеханов**

## Дорогие друзья!

Символично, что нынешнее издание выходит в свет в Год российской истории, когда вся страна отмечает 400-летие изгнания интервентов из Москвы – событие, ставшее переломным моментом в период Смутного времени, и 200-летие Победы России в Отечественной войне 1812 года.

Совсем скоро мы будем торжественно праздновать 70-летие завершения героической Сталинградской эпопеи.

Эти даты обращают нашу память к самым светлым страницам истории Отечества, закрепляют чувства искреннего уважения к памяти героев. Мужество и самоотверженность не могут утратить с течением времени свою значимость и силу примера.

Из всех современных государственных наград нашей страны особое место занимает высшая степень отличия ратного подвига – звание Героя России.

За последние годы этого звания было удостоено немало людей, связанных с нашей республикой страницами трудовой биографии, узами родства и духовной близости.

Земля Татарстана во все времена рождала мужественных, беззаветно преданных народу, верных долгу людей. Это продолжается и сегодня.

Биография каждого героя новой России является школой патриотизма. Уверен, что их подвиги и жизненный опыт были, есть и будут нравственным примером для многих поколений.

Крепкого здоровья, долголетия, счастья, успехов и благополучия всем ныне живущим героям, а ушедшим из жизни – вечная слава и добрая память!

## Кадерле дуслар!

Бүгенге басманың Россия тарихы елында – бөтен илнең Болгавыр чордагы хәлиткеч моментка әверелгән вакыйганы – илбасарларны Мәскәүдән куунның 400 еллыгын һәм Россиянең 1812 елгы Ватан сугышында Җиңүенең 200 еллыгын билгеләп үткән елда дөнья күрүе бик мөһим.

Якын арада без героик Сталинград эпопеясының 70 еллыгын тантаналы төстә бәйрәм итәчәкбез.

Әлеге даталар безнең хәтеребезне Ватан тарихының иң якты истәлекләренә юнәлтәләр, күңелләрдә батырлар рухына саф хөрмәт хисләрен уяталар. Чөнки батырлык һәм фидакарьлек үзенең әһәмиятен һәм тәрбияви көчен вакытлар узу белән югалтмый.

Безнең илнең хәзерге дәүләт бүләкләре арасында сугышчан батырлыкның иң югары дәрәҗәсен күрсәтүче  Россия Герое исеме аерым урын алып тора.

Соңгы елларда хезмәт юллары, туганлык җепләре һәм рухи якынлыгы аша безнең республикабыз белән бәйле күп кенә кешеләр әлеге исемгә лаек булды.

Татарстан туфрагы һәрвакыт батыр йөрәкле, халкына чын күңелдән тугърылыклы, үз бурычларын ышанычлы үтәүче кешеләрне тудыра килгән. Һәм бу хәзер дә дәвам итә.

Яңа Россиянең һәрбер героеның тормышы патриотлык мәктәбе булырлык. Аларның батырлыклары һәм тормыш тәҗрибәсе бик күп буыннар өчен әхлакый үрнәк булып торды, тора һәм киләчәктә дә шулай булыр дип ышанам.

Бүген безнең арабызда яшәүче батырларыбызга нык сәламәтлек, озын гомер, һәр гамәлләрендә уңышлар һәм иминлек телим. Бакыйлыкка күчкәннәрнең якты истәлекләрен онытмыйк, мәңгелек дан аларга!



Президент Академии военных наук России,
генерал армии

**Махмут Гареев**

Россиянең Хәрби фәннәр академиясе президенты,
армия генералы

**Мәхмүт Гәрәев**



**Уважаемые читатели!**

Вы взяли в руки книгу, повествующую о людях, проявивших при защите Родины, ее целостности и независимости образцы подлинной воинской доблести, отваги, чести и мужества и по праву удостоенных высокого звания Героя России. Прочитайте книгу внимательно, вникая в судьбу каждого героя, и вы, если молоды по возрасту, откроете для себя, а если не молоды, еще раз утвердитесь в истине, что земля держалась и держится прежде всего на отваге и подвижничестве людей смелых по духу, готовых к самопожертвованию во имя остального общества.

Для меня, старого воина, прошагавшего огненными верстами Второй мировой войны, всю свою жизнь посвятившего «профессии – Родину защищать», эта истина незыблема.

Главный урок, вытекающий из уроков Великой Отечественной войны, состоит в том, что все народы нашей страны объединились вокруг русского народа и совместными самоотверженными усилиями отстояли честь и независимость своего Отечества. Мы, ветераны той войны, завещаем современным и будущим поколениям всемерно беречь и укреплять единство страны, солидарность и дружбу между народами как важнейшее условие обеспечения ее национальной безопасности.

Любовь к Родине, патриотизм – священное чувство, объединяющее общество, это фундамент, на котором основана национальная система ценностей. Я убежден, что пройдут десятилетия и века, сменится не одно поколение, но память о ратных и трудовых делах славных сынов Отечества будет жить вечно.

Пусть эта книга станет продолжением летописи героических свершений многонационального народа нашей страны в пору непростых поворотов в ее истории. Герои книги честно выполнили свой гражданский и конституционный долг. Пример их – как яркий факел, освещающий путь новым поколениям.

**Хөрмәтле укучылар!**

Сез кулыгызга Ватанны, аның бөтенлеген һәм бәйсезлеген яклаганда чын мәгънәсендә сугышчан гайрәтлелек, егетлек, намуслылык һәм батырлык күрсәткән һәм хаклы рәвештә Россия Герое дигән югары исемгә лаек булган кешеләр турында бәян итүче китапны алдыгыз. Аны игътибар белән, һәрбер геройның язмышын тирәнтен аңлап укыгыз. Әгәр сез яшь булсагыз, Җирнең көчле рухлы, җәмгыять хакына үзен корбан итәргә әзер кешеләрнең батырлыгына һәм фидакарьлегенә тотынып торганлыгы турындагы хакыйкатьне үзегез өчен ачарсыз, әгәр инде өлкәнрәк булсагыз, бу хакыйкатькә тагын бер кат инанырсыз.

Минем өчен – Икенче Бөтендөнья сугышының утлы чакрымнарын атлап узган, бөтен гомерен «Ватанны яклау һөнәре»нә багышлаган карт сугышчы өчен – бу хакыйкать какшамас.

Бөек Ватан сугышы сабакларыннан килеп чыга торган төп сабак шуннан гыйбарәт: илебезнең бар халыклары рус халкы тирәсенә берләште һәм бергәбергә, фидакарь тырышлык куеп, үз ватаннарының намусын һәм бәйсезлеген саклап калдылар. Без, шул сугышның ветераннары, хәзерге һәм киләчәк буыннарга илнең бердәмлеген, аның милли куркынычсызлыгын тәэмин итүнең мөһим шарты булган теләктәшлекне һәм халыклар дуслыгын бөтен көчләрен куеп сакларга һәм ныгытырга васыять итәбез.

Ватанга мәхәббәт, патриотлык – җәмгыятьне берләштерүче изге хис, ул кыйммәтләрнең милли системасы нигезләнә торган фундамент. Мин ышанам: уннарча ел һәм гасырлар үтәр, буыннар алышыныр, ләкин ватанның данлы уларының сугышчан һәм хезмәттәге эшләре турында истәлек мәңге яшәр.

Бу китап илебез тарихының катлаулы борылышлары чорында аның күпмилләтле халкы күрсәткән батырлык үрнәкләре елъязмасының дәвамы булып торсын. Китапның геройлары үзләренең гражданлык һәм конституцион бурычларын намус белән үтәделәр. Аларның үрнәге яңа буыннарның юлын яктыртучы факел кебек.



Президент Российской Ассоциации Героев,
Герой Российской Федерации, генерал-полковник
**Владимир Шаманов**

Россия Геройлары ассоциациясе президенты,
генерал-полковник
**Владимир Шаманов**

## Уважаемые читатели!

Искренне и горячо поздравляю авторский коллектив с изданием о Героях – уроженцах и проживающих ныне в Республике Татарстан. Примечательно, что книга вышла из печати в канун памятной даты России – Дня Героев Отечества 9 декабря. Уважение к Великой Истории нашего государства – одна из главных национальных традиций. Она свидетельствует: Россия во все времена почитала и будет всегда чтить своих Героев.

Немеркнущая Слава предков и гордость за их ратные свершения объединили и сплотили народы нашей страны в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг., вдохновляли их на подвиги как на фронте борьбы с немецко-фашистскими захватчиками, так и в тылу. Боевой и трудовой героизм в годы войны носил поистине массовый характер.

В послевоенный период лучшие традиции Героев-Победителей с честью продолжили новые поколения граждан России. Многие из них за образцовое выполнение заданий правительства были удостоены государством высшей степени отличия – звания Героя Советского Союза и Героя Российской Федерации. Это большой отряд воинов–интернационалистов, решавших боевые задачи в Корее, Вьетнаме, Египте, Анголе, Афганистане, других районах мира, покорители космоса и Арктики, испытатели новейших образцов вооружения и техники, бесстрашные ликвидаторы последствий аварии на Чернобыльской АЭС, военнослужащие, выполнявшие и продолжающие выполнять конституционный долг в Северо-Кавказском регионе по обеспечению внутренней безопасности государства и участвующие в борьбе с международным терроризмом.

Подвиги Героев – бессмертны. Они навеки остаются в людских сердцах, вечная память о них передается из поколения в поколение. Герои Советского Союза, Герои Российской Федерации, полные кавалеры ордена Славы – прямые наследники героических свершений наших предков – всегда были и остаются авангардом и гордостью Отчизны, олицетворением воинской доблести, личного мужества и самоотверженности во имя Российской державы, ярким и убедительным примером истинного патриотизма, любви к Отечеству и беззаветной преданности своей Родине.

Герои Отечества своим личным примером доказали актуальность и жизненность тезиса – «В жизни всегда есть место подвигу!».

## Хөрмәтле укучылар!

Татарстан Республикасында туып үскән, шулай ук бүгенге көндә дә биредә яшәүче Геройлар турындагы бу китапны бастырып чыгаручы авторлар коллективын ихлас күңелдән һәм кайнар котлыйм. Шунысы мөһим, ул Россия өчен истәлекле вакыйга – Ватаныбыз Геройлары көне (9 декабрьда) алдыннан басылып чыкты. Безнең дәүләтебезнең Бөек Тарихына хөрмәт – иң мөһим милли традицияләребезнең берсе. Ул Россиянең үз Геройларын олылавын һәм олылап торачагын ачык раслый.

Ата-бабаларыбызның сүнмәс даны һәм аларның батырлык үрнәкләре белән горурлык 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларында илебез халыкларын бергә берләштерде һәм туплады, немец-фашист басып алучыларына каршы сугышларда һәм тылда батырлыкларга рухландырды. Сугыш елларындагы батырлык һәм хезмәт героизмы чын мәгънәсендә массакүләм төс алды.

Сугыштан соңгы елларда Герой-Җиңүчеләрнең иң яхшы традицияләрен Россия гражданнарының яңа буын вәкилләре намуслы дәвам иттеләр. Хөкүмәтебез заданиеләрен үрнәк төстә башкарып чыгулары өчен аларның күбесе дәүләтебезнең иң югары бүләгенә - Советлар Союзы Герое һәм Россия Федерациясе Герое дигән югары исемнәргә лаек булдылар. Мондыйлар арасында Кореяда, Вьетнамда, Египетта, Анголада, Афганистанда һәм дөньяның башка төбәкләрендә хәрби бурычларны үтәгән сугышчы-интернационалистларның зур бер отряды, Галәмне һәм Арктиканы буйсындыручылар, коралларның һәм техниканың иң яңа төрләрен сынаучылар, Чернобыль атом электростанциясе һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә куркусыз катнашучылар, Төньяк-Кавказ регионында үзләренең конституцион бурычларын үтәп, дәүләтнең эчке куркынычсызлыгын тәэмин итүчеләр һәм халыкара терроргa каршы көрәштә катнашучылар бар.

Геройлар батырлыгы үлемсез. Ул кешеләр күңелендә мәңгелеккә кала, аларның үлемсез истәлеге буыннардан-буыннарга күчә. Советлар Союзы геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары – безнең ата-бабаларыбыз батырлыгын дәвам итүчеләр – һәрчакта да Ватаныбыз горурлыгы булдылар һәм шулай булып калалар, алар сугышчан дан, шәхси батырлык һәм Россия дәүләтенә бирелгәнлек, чын патриотизм, Ватаныбызның ярату һәм туган илебезгә чиксез бирелгәнлек үрнәкләре күрсәттеләр.

Ватаныбыз Геройлары: «Тормышта батырлыкка һәрвакытта да урын бар!» – дигән сүзләрнең актуаль булып торуын үзләренең шәхси үрнәкләре белән бик ачык раслыйлар.



Председатель общественной организации
«Герои Татарстана» РТ, Герой Социалистического Труда
**Ильдус Мостюков**

ТР «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасы рәисе,
Социалистик Хезмәт Герое
**Илдус Мостюков**

## Уважаемые читатели!

Мы продолжаем издавать серию книг под условным названием «Герои земли татарстанской». До этого в предыдущие годы увидели свет книги о Героях Советского Союза, Героях Социалистического Труда, полных кавалерах ордена Славы. И вот новая книга – о героях России, – которую мы выпускаем по инициативе Общественной организации «Герои Татарстана» и по поручению Президента РТ Р.Н. Минниханова.

Представленные в ней очерки рассказывают о героях-татарстанцах, тех, кто обучался в военных учебных заведениях Казани, героях-татарах из разных регионов Российской Федерации и Советского Союза. Это люди, которые в различных жизненных ситуациях, верные своему долгу и воинской присяге, совершили подвиги, выполняя интернациональный долг либо участвуя в операциях по сохранению целостности государства, защищая ее от посягательств экстремистски настроенных граждан или иностранных наемников.

Одни из героев этих очерков в мирное время строили и испытывали боевую технику, спасая порой ценою жизни уникальные и дорогостоящие ее образцы. Другие, и их большинство, удостоены высшей награды – звания Героя России за ратные дела в афганской войне и во время боев на Северном Кавказе. Все они – гордость и слава современной Российской Федерации и Татарстана. Были и другие боевые действия, сопутствовавшие развалу Советского Союза, в том числе и по принуждению Грузии к миру.

Я хотел бы вкратце напомнить читателям о тех событиях и причинах, их породивших.

Весь конец XX века нашу страну – СССР, а затем Россию – сотрясали различного рода вооруженные конфликты. Особенно болезненными и трагичными оказались события, связанные с Афганистаном и Чечней.

Афганская война 1979-1989 годов – это вооруженные действия между афганскими правительственными и союзными с ними советскими войсками, стремившимися сохранить в Афганистане просоветский режим, с одной стороны, и мусульманским афганским сопротивлением – с другой. Мало кто предполагал, что в середине 70-х годов начнется один из самых продолжительных и интернационализированных современных региональных конфликтов. Его истоком послужил новый виток борьбы за власть в Кабуле между ведущими этническими группами – пуштунами и таджиками. Сдвиги внутри традиционной структуры власти в Афганистане на рубеже 70-80-х годов прошлого века неожиданно оказались в центре международной повестки дня. Создались условия, которые способствовали вовлечению в эту периферийную ситуацию ведущих мировых держав.

Силовой перехват власти в указанный период привел к тому, что конкуренция СССР, США и Китая совпала с ростом политических амбиций Ирана, Пакистана, Саудовской Аравии и Объединенных Арабских Эмиратов. Последние были склонны оказывать помощь различным

## Хөрмәтле укучылар!

Без «Татарстан җире каһарманнары» дигән шартлы исем белән китаплар сериясен бастыруны дәвам итәбез. Моңа кадәр алдагы елларда Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары турындагы китаплар дөнья күрде. Менә хәзер яңа китап – Россия Геройлары турында. Без аны «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасы инициативасы һәм ТР Президенты Р.М.Миңнеханов кушуы буенча чыгарабыз.

Анда урын алган очерклар татарстанлы геройлар турында, Казан хәрби уку йортларында белем алганнар турында, Россия Федерациясе һәм Советлар Союзының төрле төбәкләреннән чыккан каһарман татарлар турында сөйли. Болар – тормышның төрле очракларында үз бурычларына һәм хәрби антларына тугры калып, интернациональ бурычларын үтәгәндә яки дәүләт бөтенлеген саклау буенча операцияләрдә катнашып, аны экстремистларча фикер йөртүче гражданнарның яки чит ил ялчыларының кул сузуыннан саклап, батырлыклар күрсәткән кешеләр.

Бу очеркларның кайбер геройлары тыныч вакытта хәрби техника төзегәннәр һәм сынаганнар, кайвакыт гомерләре бәрабәренә аның уникаль һәм кыйммәтле үрнәкләрен саклап калганнар. Башкалары, һәм алар күпчелек, иң югары бүләккә – Россия Герое исеменә Әфган сугышындагы һәм Төньяк Кавказдагы сугышлар вакытындагы хәрби эшләре өчен лаек булганнар. Алар барысы да – хәзерге заман Россия Федерациясенең һәм Татарстанның горурлыгы һәм даны. Советлар Союзы җимерелүгә китергән, шул исәптән Грузияне солыхка мәҗбүр иткән башка хәрби хәрәкәтләр дә булган.

Мин шул вакыйгалар һәм аларны китереп чыгарган сәбәпләр турында кыскача гына укучыларның исенә төшерергә телим.

XX гасырның ахырында безнең СССР илебезне, аннан соң Россияне төрледән-төрле коралды конфликтлар дер селкетеп торды. Аеруча авыр һәм хәвефлеләре Әфганстан һәм Чечня белән бәйле вакыйгалар булды.

1979-1989 еллардагы Әфган сугышы – бер яктан, Әфганстанда советлар режимын саклап калырга омтылган Әфган хөкүмәте һәм союздаш совет гаскәрләре, икенче яктан әфган мөселманнары арасындагы коралды бәрелешләр. Җитмешенче еллар уртасында иң озакка сузылган һәм интернациональләшкән төбәк конфликтларының берсе башланып китәр дип кем генә күз алдына китерде икән?! Кабулда әйдәп баручы этник төркемнәр – пуштуннар һәм таҗиклар арасындагы хакимлек өчен көрәшнең яңа борылышы аның чыганагы булып торды. Әфганстанда хакимиятнең традицион структурасы эчендәге күчешләр узган гасырның 70-80 нче еллары чигендә көтмәгәндә халыкара «көн тәртибе»нең үзәгендә булып чыкты. Периферияләге бу вәзгыятькә дөньяның әйдәп баручы дәүләтләрен тартып керткән шартлар туды.

Әлеге чорда хакимлекне көч белән тартып алу СССР, АКШ һәм Кытай арасындагы конкуренциянең Иран,

афганским группировкам и фракциям. Это побуждало руководство в Кабуле считать, что оно находится в эпицентре мировых событий, толкало к соблазну силовых решений внутригосударственных споров. Все это в совокупности способствовало усугублению конфликта.

Интернационализация и эскалация конфликта вынудили руководство СССР принимать какие-то меры. По сути дела в Афганистане уже шла гражданская война, в которую были вовлечены политические и финансовые силы многих зарубежных стран и государств исламского мира.

После переворота 27 апреля 1978 года, названного Апрельской революцией, левые силы Афганистана передали власть двум партиям – «Хальк» и «Парчам», объединившимся в Народно-демократическую партию. К сожалению, они не пользовались безоговорочной поддержкой народа. В этих условиях новое правительство жестоко подавляло внутреннюю оппозицию. Волнения в стране и постоянные распри между сторонниками «Хальк» и «Парчам», с учетом недопущения усиления влияния США в Центральной Азии, подтолкнули советское руководство к вводу в декабре 1979 года частей Советской Армии в Афганистан с мотивировкой предоставления интернациональной помощи.

Решение о вводе войск в Афганистан было принято 12 декабря 1979 года. Несмотря на возражения А.Н. Косыгина, оно было принято узким кругом членов Политбюро ЦК КПСС в составе Ю.В. Андропова, Д.Ф. Устинова, А.А. Громыко и Л.И. Брежнева.

Не буду останавливаться на всех перипетиях политической и военной борьбы, скажу лишь о том, что афганская война продолжалась с 25 декабря 1979 года до 15 февраля 1989 года, почти десять лет. Всего участие в боевых действиях приняли 546 255 советских солдат и офицеров. В конфликте также участвовали вооруженные силы правительства Демократической Республики Афганистан с одной стороны и вооруженная оппозиция (моджахеды, или душманы) – с другой. Моджахедам оказывали поддержку военные специалисты США, ряда европейских стран-членов НАТО, а также пакистанские спецслужбы. В течение 1980-1988 годов помощь стран Запада моджахедам составила в денежном эквиваленте 8,5 миллиарда долларов, половину из которых предоставили США.

Что касается внутригосударственного конфликта на Северном Кавказе, то он был спровоцирован разными причинами и не в последнюю очередь развалом Советского Союза. Чеченская война – трагедия нашей страны, и она была вызвана целым комплексом объективных и субъективных причин глобального, регионального и местного происхождения. В наиболее общем виде, по словам Р.Г. Абдулатипова, известного политического деятеля современной России, они сводятся к следующим: кризис советского строя, развал СССР, революционно-шоковое, лихорадочное реформирование России «сверху» (включая национальные отношения), лишенное квалифицированного обеспечения и здравого смысла.

Пакьстан, Согуд Гарәбстаны һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең сәяси амбицияләре үсү белән туры килүгә китерде. Соңгылары төрле әфган төркемнәренә һәм фракцияләренә ярдәм итү ягында булдылар. Бу Кабулдагы җитәкчелеккә үзләрен дөнья вакыйгаларының үзәгендә торган итеп санарга этәргеч бирде, дәүләт эчендәге бәхәсләрне көч кулланып чишәргә кызыктырды. Болар бөтенесе бергә кушылып, низагны тагын да тирәнәйтә төште.

Конфликтның интернациональләшүе һәм киңәюе СССР җитәкчелеген ниндидер чаралар күрергә мәҗбүр итте. Чынлыкта, Әфганстанда күп кенә чит илләрнең һәм ислам дөньясы дәүләтләренең сәяси һәм финанс көчләре җәлеп ителгән гражданнар сугышы бара иде инде.

1978 елның 27 апрелендәге «Апрель революциясе» дип аталган кискен борылыштан соң Әфганстанның сул көчләре хакимлекне ике партиягә – Халык-демократик партиясенә берләшкән «Хальк» һәм «Парчам» партияләренә тапшырды. Кызганычка каршы, алар халыкның һичсүзсез хуплавына ия түгелләр иде. Бу шартларда яңа хөкүмәт эчке оппозицияне рәхимсез рәвештә буйсындырып торды. Илдәге тынычсызлыклар һәм «Хальк» һәм «Парчам» яклылар арасында һәрвакыт булып торган каршылыклар, Үзәк Азиядә АКШ йогынтысын көчәйтүгә юл куймас өчен, совет җитәкчелеген 1979 елның декабрендә, интернациональ ярдәм күрсәтү сылтавы белән, Әфганстанга Совет Армиясе частьларын кертергә этәрде.

Әфганстанга гаскәрләр кертү турындагы карар 1979 елның 12 декабрендә кабул ителде. А.Н.Косыгинның каршы килүенә карамастан, карар КПСС ҮК Политбюросы әгъзалары Ю.В.Андропов, Д.Ф.Устинов, А.А.Громыко һәм Л.И.Брежнев тарафыннан кабул ителде.

Сәяси һәм хәрби көрәшнең барлык кискен үзгәрешләренә тукталып тормыйм, шуны гына әйтәм: Әфган сугышы ун елга якын – 1979 елның 25 декабреннән 1989 елның 15 февраленә кадәр дәвам итте. Сугышчан хәрәкәтләрдә барлыгы 546 255 совет солдаты һәм офицеры катнашты. Низагта шулай ук, бер яктан – Әфганстан Демократик Республикасы хөкүмәтенең кораллы көчләре, икенче яктан кораллы оппозиция (мөҗәһитләр, яки душманнар) катнашты. Мөҗәһитләргә АКШның, НАТО әгъзалары булып торучы кайбер Европа илләре хәрби белгечләре, шулай ук Пакьстан махсус хезмәтләре ярдәм күрсәтте. 1980–1988 еллар дәвамында мөҗәһитләргә Көнбатыш илләренең акчалата ярдәме 8,5 миллиард доллар тәшкил итте, шуның яртысын АКШ бирде.

Төньяк Кавказдагы дәүләт эчендәге низагка килгәндә, ул төрле сәбәпләр, шул исәптән Советлар Союзы җимерелү аркасында килеп чыкты. Чечня сугышы – илебезнең трагедиясе, һәм ул глобаль, төбәк һәм җирле объектив һәм субъектив сәбәпләрнең тулы бер комплексы аркасында чыкты. Хәзерге Россиянең танылган сәяси эшлеклесе Р.Г.Абдулатипов сүзләре белән әйткәндә, бу сәбәпләргә түбәндәгеләр керә: советлар строе кризисы, СССР таркалу, Россияне «өстән» квалификацияле тәэмин



Взаимно личная неприязнь двух политически во многом похожих лидеров, Ельцина и Дудаева, подогреваемая столичными и зарубежными «экспертами» по Кавказу, приблизила развязку. Поведи себя Ельцин тоньше, или будь на его месте человек с другим складом ума и характера, все могло бы сложиться иначе. А предыстория северокавказских событий такова.

Летом 1991 года мир узнал о том, что некая, не вполне определенная часть Чечено-Ингушской АССР выходит из состава РСФСР и СССР и объявляет себя независимым государством под названием Чеченская Республика. Так решил самопровозглашенный общенациональный съезд чеченского народа, постановивший, что высшим органом власти в этой не имеющей границ с внешними государствами республике является исполнительный комитет во главе с его председателем, генералом в отставке Д. Дудаевым.

В начале сентября 1991 года вооруженные национальные гвардейцы Дудаева силой захватили здания Совета Министров, радио и телецентра, а затем, 6 сентября, ворвались в помещение, где шло заседание Верховного Совета, и взяли его штурмом. Таким образом, в Чечне был совершен государственный переворот. Был распущен ее Верховный Совет, и, в нарушение ряда статей Конституции РСФСР, 27 октября 1991 года были проведены незаконные выборы президента Чеченской Республики и депутатов нового Верховного Совета.

Возросшее влияние национал-сепаратизма в Чечне угрожало еще не устоявшейся Российской государственности. Воспользовавшись противоречиями, переросшими в открытое противостояние между федеральными органами страны, Дудаев провозгласил и стал осуществлять идею выхода Чечни из состава Российской Федерации.

Федеральные власти пытались упорядочить обстановку в Чеченской Республике, разрешить кризисную ситуацию политическими средствами. Однако их усилия не дали желаемого результата, что привело к вооруженному конфликту. Меры, предпринятые федеральной властью по наведению конституционного порядка в Чечне, нанесли жестокий урон обеим противоборствующим сторонам. Отзвук этой политики до сих пор слышен в стране.

Проведение операции по разоружению незаконных вооруженных формирований на территории Чеченской Республики стало наиболее крупным применением федеральных войск для разрешения кризиса внутри страны. Выполняя свой конституционный долг, солдаты и офицеры Российской Федерации совершали героические поступки. Многие из них заслуженно были удостоены высокого звания Героя России.

Данная книга повествует о героях, участниках боев в Афганистане и Чечне, учившихся воинскому искусству в военных училищах Казани, а также об уроженцах разных уголков страны, татарах по национальности.

итүдән, аек акылдан мәхрүм булган революцион һәм шок рәвешендәге ашык-пошык үзгәртеп кору.

Бер-берсенә күп яктан охшаган ике сәяси лидерның – Ельцин белән Дудаевның үзара шәхси дошманлыгы, Кавказ буенча башкала һәм чит ил «экспертлары» тарафыннан кыздырылып, чишелешне якынайтты. Әгәр Ельцин барлык нечкәлекләрне истә тотып эш итсә яки аның урынында башка төрле акыллы һәм холыклы кеше булган булса, барысы да башкача килеп чыгарга мөмкин иде. Ә Төньяк Кавказдагы вакыйгаларның тарихы мондый.

1991 елның җәендә Чечен-Ингуш АССРның ниндидер бер өлеше РСФСР һәм СССР составыннан чыгып, үзен Чечня Республикасы исеме белән бәйсез дәүләт дип игълан итте. Чечен халкының үзе билгеләп куйган гомуммилли съезды тышкы дәүләтләр белән чикләре булмаган бу республикада хакимиятнең иң югары органы – башкарма комитет, ә аның рәисе – отставкадагы генерал Җ.Дудаев була дигән карар кабул итте.

1991 елның сентябрь башында Дудаевның кораллы милли гвардиячеләре Министрлар Советы бинасына басып керде, радио һәм телеүзәкне тартып алды, ә аннары, 6 сентябрьдә, Югары Совет утырышы барган бүлмәгә бәреп кереп, аны штурм белән алдылар. Шулай итеп Чечнядә дәүләт перевороты булды. Аның Югары Советы таратылды һәм, РСФСР Конституциясенең кайбер маддәләрен бозып, 1991 елның 27 октябрендә, законсыз рәвештә, Чечня Республикасы Президенты һәм яңа Югары Совет депутатлары сайлап куелды.

Чечняда милләтчел сепаратизмның үсә барган йогынтысы әле ныгып җитмәгән Россия дәүләтчелегенә куркыныч тудырды. Илнең федераль органнары арасындагы ачыктан-ачык каршы торуга әверелгән каршылыклардан файдаланып, Дудаев Чечняның Россия Федерациясе составыннан чыгу идеясен игълан итте һәм аны тормышка ашыра башлады.

Федераль хакимиятләр Чечен Республикасындагы хәлне тәртипкә салырга, кризис вәзгыятен сәяси чаралар ярдәмендә хәл итәргә тырышып карадылар. Ләкин аларның тырышлыгы тиешле нәтиҗәне бирмәде, кораллы низагка китерде. Федераль хакимият тарафыннан Чечняда конституциячел тәртип кертү буенча күрелгән чаралар каршы якларның икесенә дә бик зур зыян китерде. Бу сәясәтнең кайтавазы илдә хәзергә кадәр ишетелә әле.

Чечня Республикасында законсыз кораллы формированиеләрне коралсызландыру операциясен уздыру ил эчендәге кризисны бетерү өчен федераль гаскәрләрне файдалануның иң зур очрагы булды. Үзләренең конституцион бурычларын үтәп, Россия Федерациясе солдатлары һәм офицерлары батырлык үрнәкләре күрсәттеләр. Аларның күбесе Россия Герое дигән югары исемгә лаек булдылар. Бу китап Казан хәрби училищеларында сугышчан сәнгать серләрен өйрәнгән Әфганстан һәм Чечнядагы сугышларда катнашучылар, шулай ук илнең төрле почмакларында туган, татар милләтеннән булган батырлар турында бәян итә.


ӘФГАНСТАНДА ҺӘЛАК
СУГЫШЧЫЛАР ХӘТЕРЕБЕЗДӘ
ВЕЧНАЯ ПАМЯТЬ
ПОГИБШИМ В
БУЛГАН
МӘҢГЕ САКЛАНЫР
ВОИНАМ
АФГАНИСТАНЕ





# АБДУЛЛИН Раушан Ахмедович

Родился 26 июня 1988 года в деревне Нариманово Тюменской области. «В раннем детстве Раушан был спокойным, послушным мальчиком, – рассказывает его мама Гульфруз Сергеевна.– В начальных классах он учился только на «4» и «5». В старших в числе первых учеников он не значился, «виной» чему был спорт: Раушан занимался во всех секциях, которые действовали в школе, и на выполнение домашних заданий, естественно, оставалось меньше времени. В шутку я советовала сыну: «На тренировку захвати с собой раскладушку, чтобы там же и заночевать». Сражаться за честь класса, школы, деревни, района для него было святым делом. Будучи еще школьником, сын не раз заявлял, что после окончания школы пойдет служить в армию.

И вот наступила его школьная выпускная весна 2006 года. Раушан сдал экзамены за одиннадцать классов и стал ждать призыва в армию. 26 июня ему исполнилось 18 лет. На следующий день пошли мы с ним на призывной пункт военкомата. Там нам сказали, что весенний призыв закончился и надо ждать осени. Думала, что к тому времени отговорю сына от армии.

«Нет, мам, – ответил, – решил, я пойду служить». Я много раз убеждалась в том, что мой младшенький – человек слова. Сказал – значит, сделает. Как должна в такой ситуации поступать мать? Ей нужно поддержать своего ребенка. Вот я и предложила Раушану времени зря не терять, а выучиться за лето на автоводителя. Предложила сыну пойти на платные курсы. «Не надо,– сказал,– тратить на меня такие деньги. После армии я сам решу, что мне делать. А пока помогу вам по хозяйству, заготовим сено, выкопаем картошку, и я со спокойной душой уйду служить».

Незадолго до призыва сын узнал, что в группу спецназа требуется один боец. Его могут взять, но с условием, что он сдаст какие-то нормативы. Загоревшись, Раушан тренировался днем и ночью и добился своего.

В Краснодаре он начал службу в спецназе – разведчиком-сапером. Служба Раушану нравилась. Он никогда не жаловался на командиров, сослуживцев, казарменную обстановку, питание. Сын был доволен, поэтому и у нас, родителей, на душе было спокойно. Конечно, наш мальчик скучал по дому, родной земле. Часто признавался по телефону, как ему не хватает нас. И мы скучали! Но понимали, что надо потерпеть. Вот встретимся – наговоримся, наобнимаемся!..

За время службы сына из его части в Нариманово пришло несколько благодарственных писем. Читали их всей семьей, радовались: наш Раушан «грамотный, ответственный, трудолюбивый военнослужащий, умеющий подчинять личные интересы общественным, доводить начатое дело до конца».

Через год службы, перед новым, 2007 годом Раушан приехал в отпуск на два месяца. Спрашиваю его: «Сынок, как же так: ведь солдатам обычно дают всего две недели?»

«Мам, не беспокойся,– отвечает, – я с двумя своими товарищами выполнил важное задание, вот нас и поощрили».

1988 елның 26 июнендә Төмән өлкәсенең Нариман авылында туган. «Кечкенә чагында Раушан тыныч, тыңлаучан малай иде, – дип сөйли аның әнисе Гөлфруз Сергей кызы. – Башлангыч сыйныфларда ул бары тик «4ле» һәм «5ле» билгеләренә генә укыды. Өлкән классларда ул алдынгы укучылардан саналмады, моңа спорт гаепле иде. Раушан мәктәптә эшләп килгән барлык секцияләрдә шөгыльләнде. Шуңа күрә өй эшләрен әзерләүгә, әлбәттә инде, вакыты аз кала иде. Улыма шаяртып: «Тренировкага барганда, раскладушкаңны үзең белән ал, шунда гына кунып калырсың», – дип әйтә идем. Сыйныф, мәктәп, авыл, район данын яклау аның өчен изге эш иде. Әле мәктәптә укыганда ук улым, мәктәпне тәмамлагач, хезмәт итәргә армиягә барачагын бер генә тапкыр әйтмәгәндер.

Менә аның 2006 елгы чыгарылыш язы килеп җитте. Раушан, 11 нче сыйныфны тәмамлап, имтиханнар тапшырды һәм армиягә чакыру көтә башлады. 26 июньдә аңа унсигез яшь тулды. Икенче көнне без военкоматның чакыру пунктына киттек. Анда безгә, язгы чакырылыш тәмамланды, көзне көтәргә кирәк дип әйттеләр. Эчемнән генә, ул вакытка кадәр улымны армиягә китү теләгеннән кире кайтара алырмын әле, дип уйладым.

«Юк, әни, мин хәл иттем инде, хезмәт итәргә барам», – диде ул. Кечкенәбезнең әйткән сүзендә торучан кеше икәнлегенә күп тапкырлар ышанган идем инде мин. Әйттеме – димәк, эшли. Мондый очракта әни кеше нишләргә тиеш? Аңа үз баласын хупларга кирәк. Шуңа күрә мин Раушанга вакытын әрәм үткәрмәскә, җәй көне автомобиль йөртүчегә укырга тәкъдим иттем. Түләүле курсларга йөрергә киңәш бирдем. «Минем өчен ул кадәр акча түгәргә кирәкми, – диде. – Армиядән кайткач нишләргә кирәген үзем хәл итәрмен. Хәзергә сезгә өйдә булышам, печән әзерләрбез, бәрәңге алырбыз һәм мин хезмәт итәргә тыныч күңел белән китәрмен».

Чакырылыш алдыннан улым спецназ төркеменә бер сугышчы кирәклеген белеп алган. Ниндидер нормативларны тапшырса, аны алырга мөмкиннәр икән. Дәртләнеп китеп, Раушан көн-төн шөгыльләнде һәм үз дигәненә иреште.

Краснодарда ул хезмәтен спецназда разведчик-сапер булып башлады. Раушан армия хезмәтен ярата иде. Ул беркайчан да командирларыннан, иптәшләреннән, казармадагы хәлләрдән, ашатудан зарланмады. Улыбыз канәгать булгач, безнең, әти-әниләренең дә, күңелебез тыныч булды. Әлбәттә, безнең малай өен, туган-җирен сагына иде. Безне ничек сагынуын телефоннан еш әйтә килде. Без дә сагындык! Ләкин түзәргә кирәклеген аңлый идек. Менә очрашкач, туйганчы сөйләшербез, кочаклашырбыз әле дип уйладык.

Улыбыз хезмәт иткән вакытта аның частеннан Наримanга берничә рәхмәт хаты килде. Бөтен гаиләбез белән укып, Раушаныбызның «белемле, җаваплы, хезмәт сөючән, шәхси мәнфәгатьләрен җәмгыятьнекенә буйсындыра белүче, башлаган эшен ахырына җиткерүче хәрби хезмәткәр» булуына шатлана идек.





Перед отъездом из дома Раушан сказал старшему брату Давлату, что решил продолжить службу по контракту. Родители узнали о его решении случайно, когда он уже был в Южной Осетии.

События августа 2008-го года по отражению нападения войск режима Саакашвили на Южную Осетию воспроизведены буквально по часам. Они – в описании подвига рядового контрактной службы, разведчика-сапера Раушана Абдуллина.

8 августа в составе отряда спецназа 10-й отдельной бригады специального назначения Северо-кавказского военного округа рядовой Раушан Абдуллин находился в составе батальона российских миротворческих сил, который принял первые удары грузинских войск. В течение всего дня они вели огонь по объектам миротворцев. Раушан, находясь на своей позиции, корректировал огонь своих товарищей, передавая по рации расположение огневых позиций грузинской пехоты. В зоне корректировки огня он получил сквозное ранение в левую ногу. Перебинтовал ногу и, превозмогая боль, открыл огонь из автомата, сразив четырех военнослужащих противника.

Протаранив ворота контрольно-пропускного пункта, на территорию городка миротворческого батальона, при поддержке пехоты, прорвался грузинский танк и начал обстреливать санитарную часть. Рядовой Раушан Абдуллин, видя, что под угрозой оказались жизни раненых солдат, велел прикрыть его огнем рядовому Абоимову, намереваясь подобраться к танку противника. В этот момент танк повернул башню в сторону Абдуллина и произвел выстрел. Мгновенно сориентировавшись, Раушан броском накрыл своим телом Абоимова. В результате разрыва снаряда он получил множественные осколочные ранения спины и ноги и сильную контузию. Под плотным огнем грузинских солдат, истекая кровью, Абдуллин все же приблизился к танку и подбил его из ручного противотанкового гранатомета. От полученных множественных ран и потери крови отважный воин скончался на поле боя.

Указом Президента Российской Федерации от 9 сентября 2009 года за мужество и героизм, проявленные при исполнении воинского долга в Северо-Кавказском регионе, рядовому Абдуллину Раушану Мухамедовичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).

Похоронен он на кладбище в родной деревне Нариманово.

5 декабря 2009 года в администрации Тюменской области состоялась торжественная церемония вручения знака особого отличия Героя Российской Федерации – медали «Золотая Звезда» родителям погибшего при исполнении служебного долга рядового Р.М. Абдуллина – Гульфруз и Мухамеду Абдуллиным. Благодарные односельчане на свои сбережения решили в память о герое построить мечеть «Раушан», а на здании школы, в которой он учился, появилась мемориальная доска.

Бер ел хезмәт иткәннән соң яңа 2007 ел алдыннан Раушан ике айга отпускыга кайтты. «Улым ничек алай соң: гадәттә солдатларга ике генә атна бирәләр бит?» – дип сорадым.

«Әни, борчылма мин ике иптәшем белән бергә мөһим задание үтәдем, шуңа күрә безне бүләкләделәр», – дип җавап бирде».

Өйдән китәр алдыннан Раушан өлкән абыйсы Дәүләткә контракт буенча хезмәтен дәвам итәргә дигән фикергә килгәнен әйткән. Аның бу карары хакында әти-әниләре очраклы гына, инде Көньяк Осетиядә булганда белгәннәр.

Саакашвили режимы гаскәрләренең 2008 елның августындагы Көньяк Осетиягә һөҗүмен кире кайтару вакыйгалары сәгате-минутына кадәр билгеле. Алар – контракт хезмәте рядовое, разведчик-сапер Раушан Абдуллин батырлыгы тасвирламасында.

8 август көнне Төньяк Кавказ хәрби округы махсус билгеләнештәге унынчы аерым бригаданың спецназ отрядында рядовой Раушан Абдуллин Грузия гаскәрләренең беренче һөҗүмнәренә дучар булган Россиянең тынычлык урнаштыручы көчләре батальоны составында булган. Грузия гаскәрләре көн буе тынычлык урнаштыручыларның объектларына ут яудырганнар. Үз позициясендә торган килеш Раушан грузиннар пехотасының ут позицияләре урнашкан урыннар турында рациядән хәбәр итеп, үз иптәшләренең яудырган утына төзәтмәләр кертеп торган. Шул вакытта аның сул аягы үтәли яралана. Аягын бинт белән чорнап куя да, авыртуны җиңеп, ул автоматтан ут ача һәм дошманның дүрт хәрбиен егып сала.

Тикшерү-үткәрү пункты капкасын аударып, пехота ярдәме белән, тынычлык урнаштыручы батальон шәһәрчеге территориясенә грузиннар танкы бәреп керә һәм санитар частька ата башлый. Яралы солдатларның гомере куркыныч астында калганны күреп, рядовой Раушан Абдуллин дошман танкына якынрак килү нияте белән, рядовой Абоимовка үзен ут белән каплап торырга куша. Бу мизгелдә танк башнясын Абдуллин ягына таба бора һәм атып җибәрә. Бик тиз уйлап алып, сикереп, Раушан үз гәүдәсе белән Абоимовны каплый. Снаряд шартлау нәтиҗәсендә осколоклардан аркасына һәм аякларына бик күп яралар һәм көчле контузия ала. Грузин солдатларының көчле уты астында, каны аккан килеш, Абдуллин барыбер танкка якын килә һәм аңа танкка ата торган кул гранатометыннан ата. Яралардан һәм күп кан югалтудан батыр сугышчы сугыш кырында һәлак була.

Россия Федерациясе Президентының 2009 ел, 9 сентябрендәге Указы белән Төньяк Кавказ төбәгендә хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен рядовой Абдуллин Раушан Мөхәммәт улына үлгәннән соң Россия Федерациясе Герое исеме бирелә.

Ул туган авылы Нариман зиратында җирләнгән.

2009 елның 5 декабрендә Төмән өлкәсе хакимиятендә Россия Федерациясе Героеның аеруча аерылып тору билгесен – «Алтын Йолдыз» медален хезмәттәге бурычын үтәгәндә һәлак булган Р.М.Абдуллинның әти-әнисе Гөлфруз һәм Мөхәммәт Абдуллиннарга тапшыру тантанасы булды. Рәхмәт йөзеннән авылдашлары герой истәлегенә үз акчаларына «Раушан» мәчетен төзергә карар итәләр, ә ул укыган мәктәп бинасында мемориаль такта барлыкка килә.







# АЛИМОВ Владимир Ришадович

Родился 6 декабря 1957 года в селе Караидель Караидельского района Башкирской АССР. Окончив среднюю школу, поступил в Саратовское высшее военное авиационное училище летчиков, которое успешно окончил в 1979 году.

Служебная карьера Владимира также складывалась успешно: за сравнительно короткое время он дослужился до заместителя командира эскадрильи по воспитательной работе 440-го отдельного боевого управления вертолетного полка.

Когда в апреле 1986 года случилась катастрофа на Чернобыльской АЭС, Алимов в числе первых вызвался лететь туда. Для укрощения огнедышащего ядерного вулкана стали сбрасывать с воздуха свинцовые болванки. Заходили на цель на высоте 200 метров на скорости 50 километров. За два дня Владимир совершил 35 заходов на реактор, сбросив на него более 45 тонн специального груза. Вертолетчик, как и другие его коллеги, получил 31 рентген радиации, но тогда им было не до вычисления рентгеновской дозы. Разумеется, все это не могло, к сожалению,

1957 елның 6 декабрендә Башкортстан АССРның Караидел районы Караидел авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Саратов югары хәрби авиация училищесына укырга керә, аны 1979 елда уңышлы гына тәмамлый.

Владимирның хезмәт карьерасы шулай ук уңышлы башлана. Чагыштырмача кыска вакыт эчендә ул вертолет полкының 440 нчы аерым хәрби идарәсе тәрбия эшләре буенча эскадрилья командиры урынбасары дәрәҗәсенә ирешә.

1986 елның апрелендә Чернобыль АЭСында катастрофа булгач, Алимов, беренчеләрдән булып, шунда очарга теләк белдерә. Ялкын чәчеп торучы атом-төш вулканын тынычландыру өчен һавадан кургаш болванкалар ташларга тотыналар. 200 метр биеклектә 50 километр/сәгать тизлек белән очалар. Ике көндә Владимир реактор өстенә 35 тапкыр очыш ясый, 45 тоннадан артык махсус йөк  ташлый. Башка хезмәттәшләре кебек үк, вертолетчы 31 рентген радиация ала, ләкин ул чакта аларның рентген дозаларын исәпләп торырга вакытлары булмый. Билгеле инде, болар эзсез генә үтмәгән. Алимов госпитальдә сигез ай ята. Кем



пройти бесследно. Восемь месяцев провел Алимов в госпитале. Как говорится в таких случаях, Бог был на его стороне, предотвратил напасти. Строгая медицинская комиссия дала «добро» на дальнейшую летную работу.

Владимир шлифовал летное искусство в воздухе и на земле. Друзья отмечали его необыкновенное упорство. Бывший комэск, боевой друг Алимова Николай Пырин, дважды прошедший горнило Афганистана и немало полетавший с ним, вспоминает: «Таких «горных» летчиков-ночников, как Алимов, было единицы. У него особый талант боевого летчика.

За пятнадцать лет знакомства мне довелось видеть Владимира в самых различных ситуациях: на службе, в семье, на полковых вечерах отдыха. И всегда он умел создавать благоприятную атмосферу для работы, общения, отдыха окружающих его людей, которой проникаешься при любом настроении. Его состояние души как-то непринужденно воспринимается и передается другим».

«Летчик от Бога», – так характеризовали его боевые друзья, прошедшие вместе с Алимовым не одну «горячую точку». За два месяца в Чечне Владимир совершил 250 боевых вылетов, то есть выходит, что по четыре вылета в сутки. Причем половину из них – ночью. За два месяца он с экипажем уничтожил более 80 машин с боевиками, боеприпасами, топливозаправщиков.

Вертолет Ми-8 не оборудован для ведения боевых и поисковых работ ночью. Алимов компенсировал этот недостаток скрупулезным изучением местности, данных разведки, потому всегда был готов к выполнению самой сложной боевой задачи. Владимир Ришадович безошибочно высаживал в тылу противника разведгруппы, точно в назначенное время забирал их на борт после выполнения

Журналист одного из центральных изданий Владимир Матяш приводит несколько эпизодов боевой работы Владимира Алимова:

«4 октября 1999 года экипаж проводил разведку на фронте выдвижения 276-го мотострелкового полка. Им была обнаружена группа боевиков на господствующей высоте. Майор Алимов огнем бортового оружия уничтожил боевиков, а затем высадил разведгруппу. Это позволило подразделениям мотострелкового полка без потерь личного состава и техники занять нужные позиции.

15 октября 1999 года экипажу майора Алимова было приказано эвакуировать группу спецназовцев, окруженных боевиками на высоте 509,9 в районе Серноводска. С группой огневой поддержки из двух вертолетов Ми-24 майор прибыл в указанный район и с ходу вступил в бой. Под прикрытием Ми-24 Алимов посадил свой вертолет, погрузил спецназовцев и ушел из зоны противодействия боевиков. Личный героизм Владимира Ришадовича позволил спасти от неминуемой гибели двенадцать солдат.

13 декабря 1999 года группа вертолетов, ведомая майором Алимовым, выполняла задачу по поиску летчика Су-25, сбитого в Аргунском ущелье и упавшего в районе чеченского села Старые Атаги. Метеоусловия были сложные, нижняя кромка облаков опустилась на 80-90 метров при видимости меньше одного километра. При подходе к Ярыш-Марды вертолеты были обстреляны боевиками. Один из ведомых, майор Вячеслав Христофоров, доложил о прямом попадании снаряда в его машину. Отдав приказ

әйтмешли, аны Алла саклаган, үлемнән алып калган. Катгый медицина комиссиясе алга таба да очарга рөхсәт бирә.

Владимир очу сәнгатен һавада да, җирдә дә камилләштерә. Дуслары аны гаҗәеп үҗәт булуын әйтәләр. Элекке эскадрилья командиры, Әфганстан җәһәннәмен ике тапкыр үткән сугышчан дусты Николай Пырин болай дип искә төшерә: «Алимов кебек төнлә оча торган тау очучыларын берәмләп кенә санарлык иде. Аңарда сугышчан очучы өчен кирәкле аерым талант бар.

Таныш булган унбиш ел эчендә миңа Владимирны төрледән-төрле хәлләрдә күрергә туры килде: хезмәттә, гаиләсендә, полктагы ял кичәләрендә. Ул һәрвакыт кеше белән аралашу, әйләнә-тирәсендәге кешеләрне ял иттерү өчен уңайлы атмосфера тудыра белә иде. Аның күңел халәте ничектер үзеннән-үзе кабул ителә һәм башкаларга да йога».

Алимов белән бергә әллә ничә «кайнар нокта»ны узган сугышчан дуслары аны «Ходай очучы итеп яраткан» дип йөртәләр. Чечняда булган ике ай эчендә Владимир 250 тапкыр хәрби очыш ясый, ягъни тәүлегенә  дүртәр очыш килеп чыга. Аларның яртысы төнлә әле. Шушы ике айда үз экипажы белән бергә ул боевиклар, сугыш кирәк-яраклары, ягулык төягән сиксәннән артык машинаны юк итә.

«Ми-8» вертолеты хәрби һәм эзләнү эшләрен төнлә алып бару өчен җиһазландырылмаган. Алимов бу җитешсезлекне урынны, разведка мәгълүматларын тәфсилләп өйрәнү белән тутыра, шуңа күрә иң катлаулы хәрби бурычны да үтәүгә һәрвакыт әзер була. Владимир Ришат улы разведка төркемен дошман тылына бер дә ялгышмыйча төшерә, хәрби бурычны үтәгәннән соң аларны билгеләнгән вакытта бортына ала. Хәтта куркусыз  спецназ егетләре дә очучының осталыгына һәм батырлыгына шаккаталар: ул бит аларны өметсез булып күренгән хәлләрдән дә тартып чыгара.

Бер үзәк  басманың журналисты Владимир Матяш Владимир Алимовның сугышчан эшчәнлегеннән берничә эпизод китерә:

«1999 елның 4 октябрендә экипаж 276 нчы мотоукчылар полкының хәрәкәт фронтында разведка үткәрә. Майор Алимов бер биеклектә боевиклар төркемен күреп ала. Ул борт коралы ярдәмендә боевикларны юк итә, ә аннары разведка төркемен төшерә. Бу мотоукчылар полкы подразделениеләренә, сугышчыларын һәм техниканы югалтмыйча, кирәкле позицияләргә урнашырга мөмкинлек бирә.

1999 елның 15 октябрендә майор Алимов экипажына Серноводск районында 509,9 биеклегендә боевиклар чолганышында калган спецназ төркемен эвакуацияләргә боерык бирелә. Ике «Ми-24» вертолетыннан торган ярдәм төркеме белән майор әлеге районга килеп җитә һәм шунда ук сугышка керә. «Ми-24» вертолетына ышыкланып, Алимов үз вертолетын утырта, спецназчыларны төйи һәм боевиклар чолганышыннан чыгып китеп бара. Владимир Ришат улының шәхси батырлыгы 12 солдатны үлемнән коткара.

1999 елның 13 декабрендә майор җитәкчелегендәге вертолетлар төркеме Аргун тарлавыгында бәреп төшерелгән һәм Иске Атак дигән чечен авылы тирәсенә егылып төшкән «Су-25» очучысын эзләү белән шөгыльләнә. Һава торышы начар, болытлар 80-90 метрда йөзә, күз күреме бер чакрымнан да азрак була. Ярыш-Мардага килеп

второму ведомому на прикрытие, Алимов повел свой вертолет на посадку. Во время снижения попал под шквальный огонь боевиков, в результате чего была выведена из строя связь, система управления огнем, повреждена половина приборов… Приземлившись, Алимов приказал личному составу парашютно-десантной группы, находившейся на борту, рассредоточиться и огнем прикрыть эвакуацию экипажа и десантной группы сбитого вертолета.

22 минуты под огнем понадобилось командиру, чтобы погрузить на борт солдат, пятеро из которых были ранены. Осознавая личную ответственность за жизнь боевых товарищей, имея на борту тройную перегрузку, в условиях разряженного воздуха гор, Алимов сумел взлететь. 40 минут с таким количеством народа, с пробитыми баками и простреленными лопастями, в сложных метеоусловиях, без радиосвязи, с неработающим компасом пилот долетел и произвел в Моздоке посадку. На вертолете насчитали 40 пробоин, из них 12 – в пилотской кабине. Как говорят в таких случаях, долетел на собственном сердце, потому что после приземления вертолет не подлежал восстановлению и был списан.

– Во время боя за спасение экипажей и десантников,– рассказывает один из членов экипажа Алимова,– наш вертолет получил значительные повреждения. Тут о вынужденной посадке бы думать, но ведь внизу наши товарищи… И командир тогда мне сказал: «Или мы все уйдем, или все останемся здесь». Владимир Ришадович в тот памятный день под плотным огнем противника, по сути дела, спас 38 солдат и офицеров.

Из таких эпизодов и складывалась боевая работа майора Алимова. Участвуя в различных кампаниях, в том числе и за границей, он выполнил около 1000 боевых вылетов. Наверное, самой судьбой начертано Владимиру, постоянно рискуя, выручать людей из беды. Спасать, несмотря ни на какие трудности.

Указом Президента Российской Федерации от 15 февраля 2000 года за мужество и героизм, проявленные при исполнении воинского долга в ходе контртеррористической операции в Северо-Кавказском регионе, майору Алимову Владимиру Ришадовичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

В 2004 году ему присвоена высшая летная квалификация «летчик-снайпер». А вскоре вслед за этим и почетное звание «Заслуженный военный летчик Российской Федерации». Владимир Ришадович – почетный гражданин Вяземского района Смоленской области. На малой родине – в селе Караидель Башкортостана одна из улиц названа его именем. Он член совета клуба заслуженных военных летчиков и летчиков-испытателей, почетный член пилотажной группы «Русь».

Полковник Алимов В.Р. продолжил службу в Вооруженных Силах России. Работал старшим инспектором отдела боевой подготовки штаба 16-й воздушной армии. Награжден также орденами Красной Звезды, Мужества, «За военные заслуги», медалями.

җитәрәк, боевиклар вертолетларга ут ача. Майор Вячеслав Христофоров үзенең машинасына снаряд тию турында җиткерә. Икенче машинага каплап торырга боерык биреп, Алимов үз вертолетын утыртырга уйлый. Түбәнәйгән чакта боевикларның ут өермәсенә эләгә, нәтиҗәдә элемтә, утны идарә итү системасы сафтан чыга, приборларның яртысы зыян күрә. Җиргә төшеп җиткәч, Алимов бортта булган парашютчы-десантчылар төркеменә таралып урнашырга һәм бәреп төшерелгән вертолетның экипажы белән десант төркемен ут белән каплап торырга боера.

Бишесе яралы булган солдатларны ут астында бортына төяү өчен командирга 22 минут вакыт кирәк була. Сугышчан иптәшләренең гомере өчен җаваплылыкны үз өстенә алып, бортында өч тапкыр артык йөк булган килеш, тауларның сирәкләнгән һавасы шартларында Алимов очып китә ала. Шулкадәр кеше, тишек баклар һәм канатлар белән, начар һава шартларында радиоэлемтәсез, җимерек компас белән очучы 40 минут эчендә Моздокка барып җитә һәм вертолетын утырта. Соңыннан вертолетта 40 тишек саныйлар, шуларның 12се очучы кабинасында. Андый очракларда «үз йөрәгендә очкан» диләр, чөнки вертолет инде төзәтерлек хәлдә булмый һәм списать ителә.

– Экипажны һәм десантчыларны коткару өчен сугышта безнең вертолет шактый зыян күрде, – дип сөйли Алимов экипажы әгъзаларының берсе. – Мәҗбүри төшеп утыру турында уйлар идек, ләкин аста безнең иптәшләр бит… Шунда командир миңа: «Йә без барыбыз да китәбез, йә барыбыз да монда калабыз», – дип әйтте. Ул истәлекле көндә дошманның көчле уты астында Владимир Ришат улы 38 солдат һәм офицерны коткарды.

Майор Алимовның хәрби эшчәнлеге шундый эпизодлардан тора да инде. Төрле кампанияләрдә катнашып, шул исәптән чит илдә дә, ул меңгә якын хәрби очыш ясый. Мөгаен, даими рәвештә хәвеф-хәтәр астында булып, кешеләрне бәладән коткару Владимирның язмышына язылгандыр. Бернинди авырлыкка да карамастан коткару.

Төньяк Кавказ төбәгендә террорчылыкка каршы операция барышында хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен, Россия Федерациясе Президентының 15 февраль, 2000 ел Указы нигезендә, майор Алимов Владимир Ришат улына Россия Федерациясе Герое исеме бирелә һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

2004 елда аңа иң югары – «Очучы-снайпер» очучылык квалификациясе, шуннан соң озак та үтми, «Россия Федерациясенең атказанган хәрби очучысы» дигән мактаулы исем дә бирелә. Владимир Ришат улы – Смоленск өлкәсе Вязьма районының мактаулы гражданины. Туган ягында – Башкортстанның Караидел авылында бер урам аның исемен йөртә. Ул атказанган хәрби очучылар һәм очучы-сынаучылар клубы советы әгъзасы, «Русь» очучылар төркеме шәрәфле әгъзасы.

Полковник В.Р. Алимов Россиянең Коралллы көчләрендә хезмәтен дәвам иттерә. 16 нчы һава армиясе штабының сугышчан хәзерлек бүлеге өлкән инспекторы булып эшли. Шулай ук Кызыл Йолдыз, Батырлык, «Хәрби казанышлар өчен» орденнары, медальләр белән бүләкләнә.







# АЛЫКОВ
## Марат Равильевич

Родился 20 августа 1959 года в поселке Капустин Яр ныне Ахтубинского района Астраханской области в семье военнослужащего. В 1980 году окончил Качинское высшее военное училище летчиков. Служил в строевых частях ВВС. Участвовал в боевых действиях в Афганистане. В качестве старшего летчика, затем командира звена совершил 214 боевых вылетов на истребителе-бомбардировщике Су-17. За выполнение боевых заданий награжден орденом Красной Звезды. В 1985 году ушел в запас. Но в 1987-м окончил Школу летчиков-испытателей и до 2005 года находился на летно-испытательной работе в ОКБ имени А.И. Микояна. В ноябре 1997 года поднял в небо и провел испытания сверхзвукового истребителя МиГ-29СМ. Участвовал также в испытаниях МиГ– 29СМТ, МиГ-29УБТ, МиГ-29М2, МиГ-31, МиГ-АТ.

За мужество и героизм, проявленные при испытании новой авиационной техники, Алыкову Марату Равильевичу 31 мая 1998 года присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

В 2006 году заслуженный летчик-испытатель 1-го класса, кандидат технических наук, Герой России Алыков М.Р. окончил Российскую академию государственной службы при Президенте Российской Федерации. Жил в Москве, а с 2006 года проживает в городе Жуковском Московской области. Награжден также орденом «За личное мужество».

1959 елның 20 августында Әстерхан өлкәсенең хәзерге Актүбә районы Капустин Яр бистәсендә хәрби хезмәткәр гаиләсендә туа. 1980 елны Качинск очучылар югары хәрби училищесын тәмамлый. Хәрби һава көчләре частьларында хезмәт итә. Әфганстандагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнаша. Өлкән очучы, аннары звено командиры сыйфатында «Су-17» истребитель-бомбардировщикта 214 сугышчан очыш ясый. Хәрби заданиеләрне үтәгән өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. 1985 елдан запаска чыга. Әмма 1987 елда Очучы-сынаучылар мәктәбен тәмамлый һәм 2005 елга кадәр А.И.Микоян исемендәге ОКБда очу-сынау эшләрендә катнаша. 1997 елның ноябрендә тавыш тизлегеннән дә тизрәк оча торган «МиГ-29СМ» истребителен һавага күтәрә һәм сынаулар үткәрә. Шулай ук «МиГ-29СМТ», «МиГ-29УБТ», «МиГ-29М2», «МиГ-31», «МиГ-АТ» истребительләрен сынауда да катнаша.

Яңа авиация техникасын сынаганда күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен Алыков Марат Равил улына 1998 елның 31 маенда Россия Федерациясе Герое исеме бирелә һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Атказанган беренче класслы очучы-сынаучы, техник фәннәр кандидаты, Россия Герое 2006 елда Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия дәүләт хезмәте академиясен тәмамлый. Мәскәүдә яши, ә 2006 елны Мәскәү өлкәсенең Жуковск шәһәренә күчә. «Шәхси батырлык өчен» ордены белән дә бүләкләнгән.





# АХПАШЕВ Игорь Николаевич

Родился 24 декабря 1969 года в селе Аскиз Аскизского района Хакасской автономной области Красноярского края (ныне Республика Хакасия). После окончания средней школы поступил в Самарский политехнический институт, но, проучившись там год, решил избрать профессию военного. И это не случайно. «Он с детских лет мечтал быть военным, – вспоминает учитель математики и классный руководитель Игоря в пятых-восьмых классах Лариса Ширингина. – Очень любил математику, участвовал в олимпиадах. И надо было видеть, какой радостью светились его глаза, когда Игорь справлялся с самой трудной задачей. Он был открытым, целеустремленным, с большим уважением относился к девочкам. Его родители Николай Гаврилович и Лидия Ивановна были моими первыми помощниками в классе».

Игорь мечтал стать офицером, и не просто офицером, а офицером-танкистом. Мечта эта шла из детства, когда мальчик на даче вырыл себе землянку под «командный пункт» и оттуда командовал игрушечными «боевыми» машинами.

С первого раза в военное училище поступить не удалось, и, чтобы не терять год, юноша поступил в Сызранский филиал Самарского политехнического института. А через год вновь попытал счастье и поступил-таки в Казанское высшее командное танковое училище.

Четыре года учебы в танковом пролетели незаметно. Игорь был любознательным и увлеченным человеком. В школе и в училище помимо своей основной профессии танкиста он освоил навыки токаря, шофера, автослесаря, инженера-механика.

1969 елның 24 декабрендә Красноярск крае Хакасия автономияле өлкәсенең (хәзер – Хакасия Республикасы) Аскиз районы Аскиз авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Самара политехника институтына укырга керә. Ләкин бер ел укыганнан соң хәрби хезмәткәр һөнәрен сайларга карар итә. Бу очраклы гына түгел. «Ул балачактан ук хәрби кеше булырга хыялланды, – дип искә төшерә Игорьның 5-8 нче сыйныфлардагы математика укытучысы һәм сыйныф җитәкчесе Лариса Ширингина. – Математиканы бик ярата, олимпиадаларда катнаша иде. Иң авыр мәсьәләне чишкәч, аның күзләреннән шатлык чаткылары сибелә иде. Ул ачык күңелле, максатка омтылучан, кызларны бик хөрмәт итүчән. Аның әти-әниләре Николай Гаврилович һәм Лидия Ивановна сыйныфта минем беренче ярдәмчеләрем булдылар».

Игорь офицер булырга хыяллана, гади офицер гына түгел әле, офицер-танкист булырга. Аның бу хыялы бала чагыннан ук килә. Ул чакта малай дачаларында землянка казып, «команда пункты» ясый һәм шуннан торып уенчык «хәрби» машиналар белән җитәкчелек итә.

Хәрби училищега беренче тапкырдан ук керә алмый, шуңа күрә елын югалтмас өчен, яшүсмер Самара политехника институтының Сызраньдагы филиалына керә. Ә бер елдан кабат бәхетен сынап карый һәм Казан югары командa танк училищесына укырга керә.

Танк училищесында укыган дүрт елы сизелми дә үтеп китә Игорь кызыксынучан һәм һәвәс кеше була. Үзенең төп танкист һөнәреннән тыш, училищеда ул токарь, шофер, автослесарь, инженер-механик һөнәрләрен дә үзләштерә.





И вот первое назначение, первая самостоятельная должность – командир танкового взвода 386-го танкового полка 2-го армейского корпуса СибВО.

Приезжая в отпуск, Игорь увлеченно рассказывал о воинской службе. Родители видели в возмужавшем парне настоящего командира, чувствовавшего и несшего ответственность за своих подчиненных.

1 декабря 1994 года Ахпашева назначают командиром танковой роты 74-й отдельной гвардейской мотострелковой бригады 28-го корпуса СибВО. Почему именно его? На этот вопрос друзья отвечали так: потому что открытый, прямой, ответственный и надежный.

13 декабря бригаду подняли по тревоге, приказали спешно снять технику с хранения, получить боеприпасы и приготовиться к будущим боевым действиям. Некоторые офицеры написали рапорты с отказом от участия в боевых действиях и тут же были уволены. В батальоне, где служил Игорь, таких не нашлось. Правда, молодые солдаты и офицеры не знали тогда, что их ждет впереди.

А ждала их Чечня. В ночь с первого на второе января 1995 года танкисты вступили в бой. Как вспоминает друг Игоря Александр Гаврилюк, первый бой получился бестолковым: куда стрелять, что делать не знали. Появились первые потери – погиб один экипаж. Одним словом, боевой опыт приобретали ценой потерь.

В этой неразберихе один из взводов роты Ахпашева попал в засаду, командир взвода был ранен. Нужно было срочно идти на выручку. Дважды на броне командира роты разрывались гранатометные снаряды, но экипаж остался живым и выручил своих боевых друзей. Пять-шесть боев происходило в день. Воевать учились на ходу. В одном из

һәм менә беренче билгеләнү, беренче мөстәкыйль вазыйфа – СибВО 2 нче армия корпусы 386 нчы танк полкының танк взводы командиры.

Отпускыга кайткач, Игорь дәртләнеп, хәрби хезмәте турында сөйли торган була. Әти-әниләре егетнең үз кул астындагылар өчен җаваплылык тоючы чын командир булып җитлеккәнен күрәләр.

1994 елның 1 декабрендә Ахпашевны СибВО 28 нче корпусы 74 нче аерым гвардия мотоукчылар бригадасының танк ротасы командиры итеп билгелиләр. Нигә нәкъ менә аны рота командиры итеп билгеләделәр икән соң? Бу сорауга дуслары, ачык күңелле, туры сүзле, җаваплы һәм ышанычлы булганы өчен, дип җавап бирәләр.

13 декабрьдә бригаданы тревога буенча күтәрәләр, тиз генә техниканы саклаудан чыгарып, боеприпаслар алырга һәм сугышчан хәрәкәтләргә әзерләнергә боерык бирәләр. Кайбер офицерлар, хәрби хәрәкәтләрдә катнашудан баш тартып, рапорт язалар һәм шунда ук азат ителәләр. Игорь хезмәт иткән батальонда андыйлар табылмый. Дөрес, яшь солдат һәм офицерлар ул чакта алда үзләрен ни көткәнен белмиләр әле.

Аларны Чечня көткән икән. 1995 елның икенче гыйнварына каршы төндә танкистлар сугышка керә. Игорьның дусты Александр Гаврилюк искә төшергәнчә, беренче сугыш мәгънәсез килеп чыга: кая атарга, нәрсә эшләргә белмиләр. Беренче югалтулар да барлыкка килә – бер экипаж һәлак була. Кыскасы, сугышчан тәҗрибәне югалтулар бәрабәренә туплыйлар.

Бу чуалчык вакытында Ахпашев ротасының бер взводы засадага эләгә, взвод командиры яралана. Ашыгыч рәвештә аларны коткарырга кирәк була. Рота командиры броньясы өстендә ике тапкыр гранататадан атылган снарядлар шартлый, ләкин экипаж исән кала һәм сугышчан дусларын коткара. Көнгә биш-алты сугыш булып тора. Сугышырга шулай өйрәнәләр, сугыш вакытында, Грозныйда Совмин бинасын һәм Президент сараен штурмлаганда, рота миномет уты астында кала. Авыр яраланган Юрий Моисеев бер тәүлек кенә яшәп кала. «Куркыныч иде, – дип искә ала Александр Гаврилюк. – Техника яна, ут астында кешеләр арлы-бирле йөгерешә, биналар җимерелә. Волгоград полкы батальон командиры майор Рафиков: «Егетләр, монда үтерәләр. Төнгә сак куеп калдырыгыз, юкса боевиклар суеп китәрләр. Урам сугышлары вакытында зенит пулеметыннан атмагыз – снайпер сизеп алыр. Кирәкмәгәндә башларыгызны чыгармагыз!» – дип киңәш бирде. Ул безгә нәрсә эшләргә, ничек сакланырга икәнен аңлатучы бердәнбер офицер булды, без аңа бик рәхмәтле. Бер очрак истә калган. Сугышның иң кызган вакытында безнең янга полковник – Волгоград корпусының сугышчан хәзерлек бүлеге начальнигы йөгереп килде дә: «Егетләр, ярдәм итегез, мотоукчылар ротасы засадага эләкте, каплагыз әле», – дип үтенде. Ул танкка утырды да сугышка ташланды. Боевиклар машинага алты тапкыр гранатометтан атып тидерделәр, ләкин экипаж исән калды. Полковник рациядән кычкыра: «Улым, мин янам, чыдап тора алырсыңмы?!» Чыдыйм, дип җавап бирәм. Без ротаны каплый алдык... Взводны бүләккә тәкъдим иттеләр.

Игорь белән соңгы очрашуыбыз, – дип дәвам итә Александр Гаврилюк, – гыйнварның 12 сеннән 13 енә каршы



боев при штурме здания Совмина и президентского дворца в Грозном рота попала под минометный обстрел. Тяжелую рану получил Юрий Моисеев, проживший после этого только сутки. «Было страшно, – вспоминает Александр Гаврилюк.– Техника горит, люди под огнем мечутся, здания рушатся. Майор Рафиков, комбат из Волгоградского полка, настойчиво посоветовал: «Мужики, здесь убивают. Ночью выставляйте охрану, не то боевики порежут. Во время уличных боев не стреляйте из зенитного пулемета – снайпер засечет. Лишний раз не высовывайтесь!» Он был единственным офицером, который объяснил нам, что делать, как сберечься, за что ему мы были благодарны. Запомнился такой случай. К нам в разгар боя подбежал полковник, начальник отдела по боевой подготовке Волгоградского корпуса, и попросил: «Ребята, помогите, мотострелковая рота попала в засаду, прикройте». Он сел в танк и повел его в бой. В машину шесть раз боевики попали из гранатомета, но экипаж остался жив. Полковник кричит по рации: «Сынок, я горю, продержишься?!». Отвечаю, что продержусь. Роту мы прикрыли… Взвод был представлен к награде.

А последняя наша встреча с Игорем, – продолжает Александр Гаврилюк, – произошла с 12 на 13 января – на поминках капитана Юрия Моисеева. Девять дней прошло, как погиб наш товарищ.

Потом вновь был бой. Комбат капитан Александр Новкин сообщил, что выделяется бронегруппа для прикрытия десантников, которые пойдут штурмовать здание Совмина. В эту бронегруппу вошли капитан Игорь Суббота, Павел

капитан Юрий Моисеевны искә алганда булды. Иптәшебез һәлак булганга тугыз көн узган иде.

Аннан соң яңадан сугыш. Комбат капитан Александр Новкин Совмин бинасын штурмлауга барачак десантчыларны каплау өчен бронетөркем җыелуын хәбәр итте. Бу бронетөркемгә капитан Игорь Суббота, Павел Немцов һәм мин эләктек. Иртәнге сәгать дүртләрдә штурм башланды. Бинаның ике катын тиз алдык, ә менә өченчесендә атыш башланды. Без бинаны шәһәр белән бәйләп торучы күперне утка тоткалап, хәрәкәткә контрольлек иттек. Күпер аша дудаевчылар чолганыштагы боевикларга корал һәм сугыш кирәк-яраклары ташыйлар иде. Ул урыннан иң соңгы булып мин киттем. Снарядлар һәм ярдәм кирәк иде. Павел Немцов танкларны кая алып барырга икәнен күрсәтү өчен генә Игорь Ахпашев машинасына күчеп утырды. Танк кузгалып китте, ләкин Игорь бары тик бер тапкыр гына атарга өлгерде...

Бу сугышта булган кешеләр, дошман минасы туп-туры килеп тиде, дип сөйлиләр. Башняның люгы ачык булган. Ике шартлау бергә кушыла – танк эчендәге снарядлар да шартлый. Павел Немцовның гәүдәсе башняга чыгарып ташлана. Ә Игорь аның эчендә янып үлә...»

Күпмедер вакыттан соң Александр Гаврилюк үзе дә яралана. Әсирлеккә эләгүдән аны экипаж егетләре – төзәүче Андрей Ильященко һәм механик-йөртүче Виталий Самарин коткара. Госпитальдә ятканда, Александр батальонның 31 машинасыннан дүртесе генә калганлыгын, калганнарының сафтан чыгарылганын яки яндырылганын белә.

Немцов и я. Часа в четыре утра начался штурм. Два этажа здания взяли быстро, а вот на третьем завязалась перестрелка. Мы контролировали движение, простреливая мост, который связывал здание с городом. По этому мосту дудаевцы перебрасывали осажденным боевикам оружие и боеприпасы. Последним с этого места уходил я. Требовалось пополнение снарядами и подкрепление. Павел Немцов перебрался в машину к Игорю Ахпашеву, чтобы показать, куда вести танки. Танк тронулся, но Игорь успел сделать только один выстрел…

Те, кто был в этом бою, рассказывают, что случилось прямое попадание вражеской мины. Люк башни был открыт. И два взрыва слились в один – сдетонировали снаряды внутри танка. Тело Павла Немцова выбросило на башню. А Игорь сгорел внутри нее…»

Через некоторое время был ранен и сам Александр Гаврилюк. От плена его спасли ребята из экипажа – наводчик Андрей Ильященко и механик-водитель Виталий Самарин. В госпитале Александр узнал о том, что из 31 машины батальона осталось всего четыре, остальные были подбиты или сожжены.

Указом Президента Российской Федерации от 15 мая 1995 года за мужество и героизм, проявленные при выполнении воинского долга, гвардии старшему лейтенанту Ахпашеву Игорю Николаевичу посмертно присвоено звание Героя Российской Федерации. Тело героя после гибели в горящем танке не поддавалось визуальной идентификации и до 2001 года находилось в Ростовской военной лаборатории. Только с помощью экспертов по ДНК его удалось идентифицировать. 7 февраля 2001 года с воинскими почестями останки героя похоронили на Подсиненском кладбище столицы Республики Хакасия – города Абакана.

В память о Герое России установлена мемориальная доска на здании школы №1 в родном селе, которую он окончил. Ему было всего 25 лет. В один из дней отец героя, Николай Ахпашев, по приглашению пришел в школу на торжество в память о его сыне.

– Спасибо большое, что не забываете нашего Игоря, – растроганно сказал Николай Гаврилович. – Пусть школа гордится своими выпускниками, а вам, дети, желаю успехов в учебе.

Минутой молчания почтили память отважного земляка школьники, педагоги, военные, представители администрации. Затаив дыхание, выслушали они однополчанина Игоря Ахпашева подполковника Олега Солодкого.

– Звание Героя России не дают просто так, – сказал он, медленно подбирая слова. – В том бою Игорь и его экипаж спасли десятки жизней, прикрывая отход товарищей. Он всегда жил по принципу «Сам погибай, а товарища выручай». На таких людях держится земля российская.

Помощник военного комиссара республики подполковник Олег Пегельс рассказал учащимся об истории локальных конфликтов, в которых погибли земляки, и вручил директору школы Людмиле Огурцовой Всероссийскую книгу памяти героев, погибших в локальных войнах в 1994-1996 годах. В эту книгу занесено и имя старшего лейтенанта Игоря Николаевича Ахпашева.

Земляки помнят героя. В Абакане ежегодно проводятся соревнования по рукопашному бою на приз Героя Российской Федерации Игоря Ахпашева.



Хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен гвардия өлкән лейтенанты Ахпашев Игорь Николаевичка, Россия Федерациясе Президентының 1995 елның 15 маендагы Указы нигезендә, үлгәннән соң, Россия Федерациясе Герое исеме бирелә. Янган танкта һәлак булганнан соң, геройның гәүдәсе идентификацияләнми һәм 2001 елга кадәр Ростов хәрби лабораториясендә саклана. Бары тик ДНК экспертлары ярдәме белән генә аны идентификацияләү мөмкин була. 2001 елның 7 февралендә геройның мәетен, хәрби хөрмәт күрсәтеп, Хакасия Республикасы башкаласы Абакан шәһәренең Подсиненск зиратына җирлиләр.

Туган авылының ул тәмамлаган беренче номерлы мәктәбе бинасына Россия Герое истәлегенә мемориаль такта куелган. Аңа бары 25 яшь иде. Көннәрдән бер көнне геройның әтисе Николай Ахпашев, чакыру буенча, улы истәлегенә оештырылган тантанага мәктәпкә килә.

– Безнең Игорьны онытмаганыгыз өчен бик зур рәхмәт, – ди күңеле нечкәргән Николай Гаврилович. – Мәктәп үзенең укучылары белән горурлансын, ә сезгә, балалар, укуыгызда уңышлар телим.

Батыр якташлары истәлеген укучылар, укытучылар, хәрбиләр, хакимият вәкилләре бер минутлык тынлык белән искә алдылар. Игорь Ахпашевның полкташы подполковник Олег Солодкой чыгышын алар тын да алмый тыңладылар.

– Россия Герое исемен болай гына бирмиләр, – диде ул, сүзләрен сайлап-сайлап кына. – Бу бәрелештә Игорь һәм аның экипажы уннарча кешенең гомерен саклап калдылар. Ул һәрвакыт «Үзең үлсәң үл, ә иптәшеңне коткар» дигән принцип белән яшәде. Россия җире нәкъ шундый кешеләргә таянып тора да инде.

Республика хәрби комиссары ярдәмчесе подполковник Олег Пегельс укучыларга якташлары һәлак булган низаглар тарихын сөйләде һәм мәктәп директоры Людмила Огурцовага 1994-1996 елларда локаль сугышларда һәлак булган геройларның Бөтенроссия Хәтер китабын тапшырды. Бу китапка өлкән лейтенант Игорь Николаевич Ахпашев исеме дә кергән.

Якташлары геройны хәтерли. Абаканда ел саен Россия Федерациясе Герое Игорь Ахпашев призына кул сугышлары ярышлары уздырыла.





# БАРИЕВ Радик Абрарович



Родился в 1961 году в городе Белокоровичи Житомирской области Украины в семье кадрового офицера. Пока военный сейсмолог Абрар Бариев колесил по огромной стране, называвшейся еще недавно СССР, значительная часть детства будущего героя прошла на родине отца – Ирнуре, что в Республике Марий Эл. Как вспоминают в здешней школе, Радик был круглым отличником, его постоянно ставили в пример. Школу он окончил со средним балом 4,9 – досадную четверку в аттестате вывели по истории. Вопроса «кем быть?» перед ним не стояло, парень давно решил, что будет летчиком.

В 1978 году он поступил в Качинское летное училище. Там в 19 лет впервые сел за штурвал самолета. Из более чем шести тысяч вылетов в его послужном списке первый, конечно же, запомнился больше всего из-за переполнявших эмоций. После окончания в 1982 году училища Бариев служил в 145-м истребительном полку в Ивано-Франковске в Прикарпатском военном округе. В 1988 году поступил в Военно-воздушную академию имени Ю.А. Гагарина.

С 1991 года Радик – в Центре подготовки летчиков-испытателей имени В.П. Чкалова в городе Ахтубинске. В январе 2002 года его назначают начальником 267-го летно-испытательного центра.

Здесь получают путевку в жизнь все новые модели самолетов – от спортивных до тяжелых бомбардировщиков. Задача испытателей – выявить предел возможностей новой машины и создать практическое руководство по управлению ей для строевых летчиков.

Под началом Бариева работали полторы тысячи профессионалов, в том числе 250 полковников, более десяти Героев России.

А всего за 90 лет существования Центра в нем выросли 5 дважды Героев Советского Союза, 92 Героя Советского Союза, 21 Герой России. Центр имеет свой диссертационный Совет, в котором защищено более 500 кандидатских диссертаций, 60 докторских. Сейчас в Центре служат 55 кандидатов и 12 докторов наук. Словом, это суперэлита отечественной авиации.

После длительного простоя отечественной военной авиации в лихие 90-е годы, когда самолеты больше стояли на земле, чем летали, найти асов было непросто. Поэтому прошедших отбор пилотов доучивали тут же, в Центре. Подготовка одного современного летчика-испытателя обходится государству в несколько миллионов долларов. Поэтому они товар штучный: на всю Россию насчитывается сегодня всего 15 испытателей истребителей и 20 испытателей бомбардировщиков. А вот зарплата до последнего времени явно не дотягивала до достойной, но в испытатели люди идут не корысти ради, а с осознанием огромной ответственности, ведь цена современных моделей самолетов приближается к ста миллионам долларов за штуку и нередко они существуют в единственном экземпляре. Потерять такой самолет – значит отбросить страну на два-три года назад. В городке, где располагается Центр, есть памятник летчикам-испытателям, погибшим при испытаниях машин. На стеле золотом выбиты около 50 фамилий.

Как вы, читатели, поняли, наверное, риск, нештатные ситуации для обитателей летного Центра – повседневная норма. Как признался немногословный начальник Центра, лично у него за время летной службы возникало десятка полтора нештатных ситуаций. Радик Абрарович не раз рисковал жизнью, спасая боевые машины. Первый раз

1961 елда Украинаның Житомир өлкәсе Белокоровичи шәһәрендә кадровый офицер гаиләсендә туа. Хәрби сейсмолог Әбрар Бариев әле күптән түгел генә СССР дип аталган зур ил буйлап йөргәндә, булачак геройның балачагы әтисенең туган ягы – Мари Иле Республикасындагы Ирнурда уза. Радик һәрвакыт «бик яхшы» билгеләренә генә укыды, аны гел үрнәк итеп куя идек, дип искә алалар хәзер мәктәптә. Мәктәпне ул уртача 4,9 балл белән тәмамлый, аттестатына бердәнбер «дүртле»не тарихтан куялар. Аның алдында «кем булырга?» дигән сорау беркайчан да тормый, егет очучы булачагын әллә кайчан хәл итеп куйган инде.

1978 елны ул Качинск очучылар училищесына керә. Шунда укыганда 19 яшендә беренче тапкыр самолет штурвалына утыра. Ул ясаган алты меңнән артык очышның иң беренчесе, әлбәттә, барысыннан да ныграк исендә калган. 1982 елны училищены тәмамлагач, Бариев Прикарпатск хәрби округында Ивано-Франковскиның 145 нче истребитель полкында хезмәт итә. 1988 елны Ю.А.Гагарин исемендәге Хәрби-һава академиясенә керә.

1991 елдан Радик – Актүбә шәһәрендәге В.П.Чкалов исемендәге Очучы-сынаучылар әзерләү үзәгендә. 2002 елның гыйнварында аны 267 нче очу-сынау үзәге начальнигы итеп билгеләп куялар.

Спорт самолетларыннан алып авыр бомбардировщикка кадәр барлык самолетларның яңа модельләре «тормыш»ка юлламаны моннан ала. Сынаучыларның бурычы – яңа машинаның мөмкинлекләре чиген ачыклау һәм строевой очучылар өчен аны идарә итү гамәле кулланмасын эшләү.

Бариев кул астында мең ярым профессионал, шул исәптән 250 полковник, уннан артык Россия Герое эшли.

Үзәк эшләгән 90 ел эчендә анда 5 ике тапкыр Советлар Союзы Герое, 92 Советлар Союзы Герое, 21 Россия Герое үсеп чыга. Үзәктә диссертация советы да эшләп килә, анда 500дән артык кандидатлык, 60 докторлык диссертацияләре якланган. Хәзер Үзәктә 55 фән кандидаты һәм 12 фән докторы эшли. Кыскасы, бу – безнең ил авиациясенең суперэлитасы.

Котырган туксанынчы елларда, самолетлар очуга караганда җирдә күбрәк басып торганда, илебезнең хәрби авиациясе озак вакыт торгынлыкта булганнан соң, «ас»ларны табу җиңел булмый. Шуңа күрә сайлап алынган очучыларны шушында – Үзәктә үк өйрәтәләр. Хәзерге заман очучы-сынаучыны әзерләү дәүләткә берничә миллион долларга төшә. Шунлыктан алар «исәпле товар»: бөтен Россиягә 15 истребитель сынаучысы һәм 20 бомбардировщик сынаучысы бар. Ә менә хезмәт хаклары соңгы вакытка кадәр хезмәтләренә бәрабәр түгел иде, ләкин кешеләр байлык хакына түгел, ә бик зур җаваплылык тоеп сынаучы булалар. Самолетларның заманча модельләре бәясе 100 миллион долларга якын һәм еш кына алар бердәнбер булалар бит. Шундый самолетны югалту – илне бер-ике елга артка алып ташлау дигән сүз. Үзәк урнашкан шәһәрчектә машиналарны сынаганда һәлак булган очучы-сынаучылар һәйкәле бар. Стеллага, алтын белән чокып, 50 гә якын фамилия язылган.

Үзегез дә аңлагансыздыр инде, укучыларым, очыш Үзәгендә эшләүчеләр өчен хәвеф-хәтәр, штаттан тыш вәзгыять – көндәлек норма. Үзәкнең аз сүзле начальнигы әйтүенчә, хезмәт итү барышында үзе дә шундый унбишләп очракка юлыккан. Радик Әбрар улы, хәрби машиналарны коткарганда, тормышын куркыныч астына бер генә тап-

между жизнью и смертью он оказался, когда ему было всего 24 года – в воздухе у самолета отказало управление. И хотя с земли последовала команда покинуть самолет, он посадил-таки МИГ-29, за что был награжден орденом Красной Звезды. В другой раз ракета, которую несет самолет, взорвалась сразу после пуска, едва отделившись от машины. Осколками повредило один двигатель, был пробит топливопровод, а до базы не меньше сотни километров. Бариев дотянул, причем едва колеса коснулись бетонки, как двигатель заглох – кончилось топливо. Говорят, когда готовили документы на очередное награждение, подсчитали, что на спасенных Бариевым самолетах он сэкономил для бюджета страны не менее миллиарда долларов.

Россия единственная страна, которая делает самолеты с управляемым вектором тяги, то есть с поворачивающимися двигателями. Такая машина может повисать в воздухе, крутиться как волчок, делать сальто-мортале. Применение управляемого вектора тяги в воздушных боях стало темой диссертации полковника Бариева. Он пока единственный в мире летчик, который, находясь в управляемом штопоре, поразил воздушную цель. Этот прием стал принципиально новой страницей в теории воздушного боя.

За период летной и испытательной работы Бариев освоил и испытал более 50 типов и модификаций самолетов. Он провел 13 государственных испытаний новой авиационной техники.

Указом Президента Российской Федерации от 4 февраля 2006 года за мужество и героизм, проявленные при испытании новой авиационной техники, старшему летчику-испытателю, начальнику летно-испытательного Центра Радику Абраровичу Бариеву присвоено звание Героя России.

«Полковник Бариев не раз рисковал своей жизнью, однако личное мужество и высокий профессионализм помогали ему всякий раз находить единственно верный выход из самых сложных ситуаций», – отметил Владимир Путин на церемонии награждения.

Несмотря на высокий пост, Бариев времени в небе проводит не меньше, чем раньше, ибо убежден, что в авиации «свадебных генералов» не бывает. С годами перегрузки даются все труднее, поэтому после полетов – обязательная реабилитация. Два часа в день Бариев обязательно проводит на тренажере и в общем-то физическоцй формой своей доволен. «Доктора сказали, что лет на десять меня еще хватит», – улыбается ас. Вот таков он, Герой России Радик Абрарович Бариев!

кыр куймаган. Беренче тапкыр яшәү белән үлем арасында калганда аңа бары тик 24 яшь кенә була: һавада самолет идарә ителми башлый. Җирдән «самолетны калдырып чыгарга» дигән команда бирелгән булса да, ул МИГ-29ны барыбер төшереп утырта. Моның өчен аны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр. Ә бервакыт самолет алып бара торган ракета, машинадан аерылып җитәр-җитмәс, кузгалып китүгә үк шартлый. Ярчыклар бер двигательне эштән чыгара, ягулык үткәргеч тишелә, ә базага кадәр әле 100 чакрымга якын кайтасы бар. Бариев кайтып җитә, көпчәкләр бетонга тиюгә мотор сүнә – ягулык бетә. Аңа чираттагы бүләккә документлар әзерләгәндә, үзе коткарган самолетлар белән ил бюджетына ким дигәндә миллиард доллар экономия ясаган, дип исәпләп чыгаралар.

Россия – идарә ителүче тарту векторлы, ягъни борылып йөри торган моторлы самолетлар эшләп чыгаручы бердәнбер ил. Андый машина һавада асылынып торырга, бөтерчек кебек әйләнергә, сальто-мортале ясарга мөмкин. Һава сугышларында идарә ителүче тарту векторын куллану полковник Бариевның диссертация темасына әйләнә. Әлегә ул – идарә ителүче штопорда торган килеш, һавадагы цельгә атып тидергән бердәнбер очучы. Бу алым һава сугышы теориясендә иң яңа сүз булып чыга.

Очучы һәм сынаучы булып эшләгән чорда Бариев самолетларның илледән артык тибын һәм модификациясен үзләштерә һәм сыный. Ул яңа авиация техникасына 13 тапкыр дәүләт сынавы уздыра.

2006 елның 4 февралендә яңа авиация техникасын сынаганда күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә өлкән очучысынаучы, Очыш-сынау үзәге начальнигы Радик Әбрар улы Бариевка Россия Герое исеме бирелә.

«Полковник Бариев берничә тапкыр гомерен куркыныч астына куйды, ләкин шәхси батырлыгы һәм югары профессиональлеге аңа һәрвакыт иң катлаулы хәлләрдән дә чыгуның бердәнбер дөрес юлын табарга ярдәм итә иде», – диде Владимир Путин бүләкләү тантанасында.

Югары вазыйфа биләвенә дә карамастан, Бариев хәзер дә күп вакытын күктә үткәрә, чөнки ул авиациядә «түй генераллары» булмый дип саный. Еллар узган саен зур йөкләмәләрне үтәү авырлаша бара, шуңа күрә очыштан соң тернәкләнү мәҗбүри. Көнгә ике сәгать вакытын Бариев тренажерда үткәрә һәм үзенең физик халәтеннән канәгать. «Тагын ун елга түзәсең әле, дип әйтте табиблар», – дип елмая «ас». Менә шундый ул – Россия Герое Радик Әбрар улы Бариев!







# БЕЛЯЕВ
# Николай Александрович

Родился 27 мая 1958 года в Куйбышеве (ныне Самара). В 1975 году окончил Казанское суворовское училище, после которого поступил в Рязанское воздушно-десантное командное училище. Как и все выпускники училищ, служебную карьеру начал с должности командира взвода в воздушно-десантных войсках.

Два года служил в Афганистане, где в составе 350-го гвардейского парашютно-десантного полка неоднократно участвовал в боях с моджахедами. В одном из боев был ранен. Не раз направлялся в командировки в Абхазию и Чечню.

В 1990 году окончил Военную академию имени М.В. Фрунзе.

Осенью 1993 года, после неконституционного роспуска Президентом Ельциным Верховного Совета в стране сложилась непростая, взрывоопасная ситуация. Результатом противостояния президента и Верховного Совета стал расстрел по приказу Ельцина из танковых орудий «Белого дома», в котором собрались народные депутаты. В эти часы необходимо было удержать ситуацию под контролем, оградить Москву от эскалации военных действий. В районе Останкино начальник штаба 119-го гвардейского парашютно-десантного полка 106-й гвардейской парашютно-десантной дивизии подполковник Николай Беляев, «...выполняя правительственное задание, проявил высокое

1958 елның 27 маенда Куйбышевта (хәзер Самара) туа. 1975 елны Казан Суворов училищесын тәмамлый, шуннан соң Рязань һава-десант команда училищесына укырга керә. Училище тәмамлаган барлык хәрбиләр кебек үк хезмәт карьерасын һава-десант гаскәрләрендә взвод командиры булып башлый.

Ике ел Әфганстанда хезмәт итә. 350 нче гвардия парашют-десант полкы составында күп тапкырлар мөҗәһитләр белән ярышларда катнаша. Сугышларның берсендә яралана. Берничә тапкыр Абхазиягә һәм Чечняга командировкаларга җибәрелә.

1990 елны М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлый.

1993 елның көзендә, Президент Ельцин Югары Советны таратканнан соң, илдә бик катлаулы хәл урнаша. Президент һәм Югары Совет арасындагы каршылык нәтиҗәсе булып Ельцинның халык депутатлары җыелган Ак йортка танк орудиеләреннән атарга биргән боерыгы тора. Әлеге сәгатьләрдә вәзгыятьне контрольдә тотарга, Мәскәүне хәрби хәрәкәтләр башланып китүдән сакларга кирәк була. Останкино районында 106 нчы гвардия парашют-десант дивизиясенең 119 нчы гвардия парашют-десант полкы штабы начальнигы подполковник Николай Беляев, «...Хөкүмәт заданиесен үтәгәндә, каушап калмады, югары



самообладание, выдержку и инициативу. Грамотно командовал десантниками в критической обстановке. Благодаря четким и уверенным действиям офицера были спасены жизни многих людей».

Указом Президента Российской Федерации от 7 октября 1993 года за мужество и героизм, проявленные при выполнении специального задания, Беляеву Николаю Александровичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

Помимо Звезды Героя до этого он был награжден советскими орденами Красного Знамени, Красной Звезды, российским орденом Мужества.

В июне 2007 года Беляеву Н.А. присвоено звание генерал-майора.

чыдамлык һәм инициатива күрсәтте. Критик хәлдә десантчылар белән дөрес җитәкчелек итте. Офицерның төгәл һәм ышанычлы гамәлләре аркасында күп кешеләрнең гомере саклап калынды».

1993 елның 7 октябрендә махсус задание үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, Беляев Николай Александровичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Моңа кадәр ул совет орденнары – Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, Россиянең Батырлык ордены белән бүләкләнгән була.

2007 елның июнендә Н.А. Беляевка генерал-майор дәрәҗәсе бирелә.







# ВЕТЧИНОВ Денис Васильевич

Родился 23 июня 1976 года в поселке Шантюбе Атбасарского района Кокчетавской (ныне Акмолинской) области Северного Казахстана. В 1993 году окончил среднюю школу № 1 имени В.М. Комарова, где его отец преподавал физкультуру и автодело. С детства мечтой Дениса была воинская служба.

На действительную службу он был призван 1 августа 1993 года. Закончив службу, поступил в Омское высшее общевойсковое командное училище имени М.В. Фрунзе. В 1998 году в рамках реформы военного образования оно было расформировано, и в 2000 году Ветчинов завершил учебу в стенах Казанского филиала Челябинского танкового института.

В феврале 2000 года в составе 205-й мотострелковой бригады Денис был отправлен в Чечню, где с 2001-го по 2003 год в составе отдельного мотострелкового батальона участвовал в боевых действиях. С 2004 года проходил службу в 70-м гвардейском мотострелковом полку, с 2008-го служил заместителем командира полка по воспитательной работе 135-го мотострелкового полка.

В ночь с 7 на 8 августа 2008 года грузинские вооруженные формирования вероломно напали на столицу Южной Осетии город Цхинвали (Цхинвал), используя реактивные установки залпового огня «Град», а также минометы, гранатометы, танки и авиацию. Значительная часть города была разрушена, около 1600 осетин убиты.

Обстреляли грузины также и расположение российских миротворцев из артиллерийских орудий, танков и БМП, в результате чего 12 миротворцев были убиты, 150 ранены.

1976 елның 23 июнендә Төньяк Казахстанның Күкчәтау (хәзер Акмулла) өлкәсе Атбасар районы Шантүбә бистәсендә туа. 1993 елны В.М.Комаров исемендәге 1 нче номерлы әтисе физкультура һәм автоэш укыткан мәктәпне тәмамлый. Денис балачактан ук хәрби хезмәт турында хыяллана. Армиягә ул 1993 елның 1 августында чакырыла. Армия хезмәтен тәмамлагач, Омскидагы М.В.Фрунзе исемендәге ике Кызыл Байраклы югары гомумгаскәр командa училищесына укырга керә. 1998 елны хәрби берләшмә бетерелгәч, ул таратыла, ә Ветчинов укуын 2000 елны Чиләбе танк институтының Казан филиалында тәмамлый.

2000 елның февралендә 205 нче мотоукчылар бригадасы составында Денис Чечняга җибәрелә. Анда 2001 елдан 2003 елга кадәр аерым укчылар батальоны составында хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. 2004 елдан башлап 70 нче гвардия мотоукчылар полкында, 2008 елдан 135 нче мотоукчылар полкында полк командирының тәрбия эшләре буенча урынбасары булып хезмәт итә.

2008 елның 7 нче августыннан 8 енә каршы төндә Грузия кораллы формированиеләре, «Град» реактив установкаларын, минометлар, гранотометлар, танклар һәм авиация кулланып, Көньяк Осетия башкаласы Цхинвали (Цхинвал) шәһәренә хыянәтчел рәвештә басып керделәр. Шәһәрнең шактый зур өлеше җимерелде, 1600 гә якын осетин үтерелде.

Грузиннар шулай ук артиллерия орудиеләреннән, танк һәм БМПлардан Россия тынычлык урнаштыручылары урнашкан җиргә дә аттылар. Нәтиҗәдә тынычлык урнаштыру-



Пункт дислокации российского батальона был практически разрушен.

…Противостояние между Тбилиси и Цхинвалом своими корнями уходит в далекое прошлое. Зачатки конфликта проявились еще в 20-х годах XX века, после того, как Южная Осетия волевым путем была передана из РСФСР в состав Грузии.

В конце 1980 годов в Грузии начался подъем националистического движения, ратовавшего за ликвидацию автономных образований в составе Грузинской ССР. В целях защиты прав Южной Осетии и создания конституционных гарантий автономии 10 ноября 1989 года югоосетинские депутаты приняли решение о преобразовании автономной области в автономную республику, с чем категорически не согласилось грузинское руководство.

Вскоре противостояние югоосетинских и грузинских властей переросло в вооруженное противостояние, в ходе которого грузинские власти 8 августа 2008 года открыли уничтожающий огонь по городам и селам Южной Осетии.

Положение осетин и российских миротворцев сложилось критическое, ибо силы были явно не равны, и в этой ситуации Президент РФ принял решение с помощью российских вооруженных сил принудить Грузию к миру…

Колонна из трех десятков машин в составе мотострелкового батальона 135-го мотострелкового полка 19-й мотострелковой дивизии 58-й армии под командованием генерал-лейтенанта Анатолия Хрулева спешила на помощь осажденным в базовом лагере миротворцам. В колонне также находились командир полка Андрей Казаченко,

чыларның 12се үтерелде, 150се яраланды. Россия батальоны урнашкан пункт бөтенләй диярлек җимерелде.

…Тбилиси һәм Цхинвал арасындагы каршылыкның тамырлары тирәнгә китә. Низагның чаткылары XX гасырның 20 нче елларында ук, Көньяк Осетия  көч куллану юлы белән РСФСР составыннан Грузиягә күчерелгәч күренә башлый.

1980 еллар ахырында Грузиядә Грузия ССР составындагы автономияле берләшмәләрне бетерү өчен көрәшүче милләтчелек хәрәкәте башлана. Көньяк Осетиянең хокукларын яклау һәм автономиягә конституциячел гарантияләр тудыру максатында, 1989 елның 10 ноябрендә Көньяк Осетия депутатлары автономияле өлкәне автономияле республикага үзгәртү турында карар кабул итәләр. Моның белән Грузия җитәкчелеге катгый рәвештә килешми.

Тиздән Көньяк Осетия һәм Грузия хакимиятләре каршылыгы кораллы бәрелешкә әверелә. 2008 елның 8 августында Грузия хакимиятләре Көньяк Осетия шәһәрләре һәм авыллары өстенә ут ача.

Осетиннар  һәм Россия тынычлык урнаштыручыларының хәле катлаулана, чөнки көчләр тигез булмый. Шушы вәзгыятьтә РФ Президенты Россия Кораллы Көчләре ярдәмендә Грузияне солыхка мәҗбүр итәргә дигән карар кабул итә…

Генерал-лейтенант Анатолий Хрулев җитәкчелегендәге 58 нче армиянең 19 нчы мотоукчылар дивизиясе 135 нче мотоукчылар полкының мотоукчылар батальоны составындагы өч дистә машинадан торган колонна база лагеренда чолганышта калган тынычлык урнаштыручыларга ярдәмгә



начальник артиллерии полка Николай Багрий, заместитель командира полка по воспитательной работе майор Денис Ветчинов.

Вместе с военными ехали корреспондент «Комсомольской правды» Александр Коц, съемочная группа российского телеканала «Вести» во главе с Александром Сладковым и спецкор газеты «Московский комсомолец» Виктор Сокирко. Все они направлялись в эпицентр вспыхнувших событий по заданию своих редакций.

При въезде в Цхинвал колонну поджидала засада. Грузинские спецназовцы первыми выстрелами подбили две боевые машины пехоты. Колонна остановилась. Солдаты и журналисты в качестве укрытия использовали технику и ближайшие полуразрушенные дома. Генерал-лейтенант Хрулев, получив ранение, находился вместе со съемочной группой Сладкова и отстреливался из табельного пистолета. Майор Ветчинов, не растерявшись, открыл из автомата ответный огонь и уничтожил троих боевиков. Подобрав трофейный пулемет, он продолжал вести огонь по лесу, в котором укрылась группа противника. Машины, возобновив движение, пошли на прорыв. Журналисты Коц и Сокирко устремились за одним из бронетранспортеров, но неожиданно им путь преградил грузинский спецназовец. Он выстрелил из гранатомета. Ранения получили несколько человек, в том числе Коц и подполковник Багрий. В этот момент раненый майор Ветчинов срезал спецназовца очередью. Но и сам получил новое ранение – в голову. В последний момент, истекая кровью, заметил, что с противоположного фланга боевик прицелился в командующего армией Хрулева, и, не раздумывая, резко шагнув к нему, принял огонь на себя…

Майор Ветчинов в этом бою получил восемь огнестрельных ранений, в том числе и тяжелое, несовместимое с жизнью. По дороге в госпиталь он скончался.

Эта засада, как позднее выяснилось, оказалась единственной более или менее успешной операцией грузинских войск за весь период боевых действий. Раненного командарма благополучно эвакуировали во Владикавказ.

Александр Коц так вспоминает о Денисе Ветчинове: «Выцветший горный камуфляж, потертая кепка, прорезиненные берцы, винтовка с оптикой. На замполита он был похож меньше всего. Скорее на матерого спецназовца со спокойным взглядом». А вот что было сказано о майоре Ветчинове в служебной характеристике: «В боевой обстановке проявил себя храбрым, мужественным офицером, способным в любой ситуации выполнить приказ и принять правильное решение».

По словам друзей, Денис оставался хладнокровным в самых опасных ситуациях. И веселым, заводным в компании родных и друзей в свободное от службы время.

«Я впервые в военных действиях участвую, – сказал подполковник Николай Багрий. – Вот майор Денис Ветчинов – герой. Ему и тридцати трех не было, а он уже немало испытал в «горячих точках». Эта война для него, к сожалению, стала последней».

«Денис был настоящим офицером, – вспоминает подполковник Борисенко. – В 2003 году он попросил перевода из Буденновска в Шали, потому что хотел служить там, где выполняются настоящие боевые задачи».

ашыга. Колоннада шулай ук полк командиры Андрей Казаченко, полкның артиллерия начальнигы Николай Багрий, полк командирының тәрбия эшләре буенча урынбасары майор Денис Ветчинов та була.

Хәрбиләр белән бергә «Комсомольская правда» газетасы корреспонденты  Александр Коц, «Вести» Россия телеканалының Александр Сладков җитәкчелегендәге төшерү группасы һәм «Московский комсомолец» газетасы махсус корреспонденты Виктор Сокирко да бара. Алар барысы да үз редакцияләре заданиесе буенча вакыйгалар үзәгенә юл ала.

Цхинвалга кергәндә колонна засадага эләгә. Грузия спецназчылары пехотаның ике хәрби машинасын атып сафтан чыгара. Колонна туктый. Солдатлар һәм журналистлар техника һәм якындагы ярымҗимерек өйләр артына яшеренәләр. Яраланган генерал-лейтенант  Хрулев Сладковның төшерү төркеме белән бергә була. Майор Ветчинов югалып калмый, автоматтан җавап уты ача һәм өч боевикны юк итә. Аларның пулеметын үзенә алып, дошман төркеме яшеренгән урманга таба атуын дәвам иттерә. Машиналар яңадан кузгалып китә. Журналистлар Коц һәм Сокирко бер бронетранспортер артыннан ташлана, ләкин көтмәгәндә, Грузия спецназчысы аларның юлына аркылы төшә. Ул гранатометтан атып җибәрә. Берничә кеше яралана, шул исәптән Коц һәм подполковник Багрий. Шул мизгелдә яралы майор Ветчинов спецназчыга төзәп очередь бирә. Үзе тагын бер яра ала, бу юлы – башына. Иң соңгы мизгелдә каршы флангтагы боевикның армия командующие Хрулевка төзәгәнен күреп ала һәм уйлап та тормыйча аңа таба атлап, утны үзенә ала…

Бу сугышта майор Ветчинов сигез яра ала. Шуларның берсе иң авыры, аның гомерен кисүчесе була. Госпитальгә алып барганда ул юлда үлә.

Соңрак ачыкланганча, бу засада Грузия гаскәрләренең бөтен сугыш хәрәкәтләре вакытында бердәнбер уңышлы операциясе булып чыга. Яраланган командармны Владикавказга эвакуациялиләр.

Александр Коц Денис Ветчинов турында болай дип искә ала: «Төсе уңып беткән тау камуфляжы, кыршылган кепка, резиналы берц, оптикалы винтовка. Замполитка ул бер дә охшамаган иде. Тыныч карашлы чыныккан спецназчы кебек иде ул». Ә хезмәт характеристикасында майор Ветчинов турында менә ниләр язылган: «Сугышта үзен куркусыз, батыр офицер, теләсә нинди очракта да боерыкны үтәргә һәм дөрес карар кабул итәргә сәләтле  итеп күрсәтте».

Дуслары әйтүенчә, иң куркыныч хәлләрдә дә Денис салкын канлы булып кала алган. Ә хезмәттән тыш вакытында туганнары һәм дуслары арасында шат күңелле булган.

«Мин хәрби хәрәкәтләрдә беренче тапкыр катнашам, – дигән подполковник Николай Багрий. – Менә майор Денис Ветчинов – герой ичмасам. «Кайнар нокта»ларда сыналганда, аңа әле утыз өч тә тулмаган иде. Кызганыч, бу сугыш аның өчен соңгысы булды».

«Денис чын офицер иде, – дип искә ала подполковник Борисенко. – Чын сугышчан бурычлар үтәлә торган җирдә хезмәт итәсе килеп, 2003 елны ул Буденновскидан Шәлегә күчерүләрен сорады».

Эренцен Ботаев: «Ул һәрвакыт кылыч йөзеннән йөрде, үз артыннан ияртә белде. Барыбыз өчен дә үрнәк иде. Рос-



Эренцен Ботаев: «Он всегда был на острие, всегда вел за собой. Был для всех нас образцом. Показывал всем, каким должен быть настоящий офицер Российской армии…»

Указом Президента РФ от 15 августа 2008 года за мужество и героизм, проявленные при исполнении воинского долга, Денису Васильевичу Ветчинову посмертно присвоено звание Героя Российской Федерации. При жизни Денис был награжден медалями «За отвагу», «За воинскую доблесть» 1-й степени, «За отличие в военной службе» 3-й степени.

У него остались 25-летняя жена Екатерина и двухлетняя дочь Маша…

Проститься с Героем России в гарнизонный Дом офицеров пришли не только друзья и близкие, но и сотни волгоградцев. Гвардии майора Дениса Ветчинова похоронили на Центральном кладбище Волгограда со всеми воинскими почестями.

В рамках памятных мероприятий, приуроченных к третьей годовщине августовской войны, в Цхинвале был открыт памятник Герою России, кавалеру югоосетинского ордена «Уацамонга» майору Денису Ветчинову. Бронзовый бюст офицера установлен на месте его гибели, на улице Героев.

сия армиясенең чын офицеры нинди булырга тиешлекне аңа карап белә идек…»

Хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен, РФ Президенты Указы нигезендә, 2008 елның 15 августында Денис Васильевич Ветчиновка үлгәннән соң Россия Федерациясе Герое исеме бирелә. Исән чагында Денис «Батырлык өчен», 1 нче дәрәҗә «Сугышчан дан», 3 нче дәрәҗә «Хәрби хезмәттәге уңышлар өчен» медальләре белән бүләкләнгән иде.

Аның 25 яшьлек хатыны Екатерина һәм Маша исемле ике яшьлек кызы калды…

Россия Герое белән хушлашырга горнизонның Офицерлар йортына дуслары һәм якыннары гына түгел, йөзләгән волгоградлылар килде. Гвардия майоры Денис Ветчиновны Волградның Үзәк зиратына хәрби хөрмәт күрсәтеп җирләделәр.

Август сугышының өч еллыгына багышланган истәлек чаралары  кысасында Цхинвалда Россия Герое, Көньяк Осетиянең «Уацамонга» дигән ордены кавалеры майор Денис Ветчиновка һәйкәл ачылды. Офицерның бронзадан эшләнгән бюстын Геройлар урамына ул һәлак булган җиргә куйдылар.







# ГОЛУБЯТНИКОВ Святослав Николевич

Родился 18 июня 1958 года в селе Татарка Шпаковского района Ставропольского края в семье школьных учителей.

В 1975 году окончил Казанское суворовское училище и поступил в Рязанское воздушно-десантное училище. После его окончания служил в Иваново командиром взвода, затем командиром роты в Кировобаде. С 1979 года по 1999-й занимал должности от командира парашютно-десантного взвода до заместителя командира парашютно-десантного полка. В составе российских миротворческих сил выполнял специальные задания в Югославии, а затем в Закавказье.

Особая страница в биографии Станислава Голубятникова – служба в Чеченской Республике. Первая командировка в Чечню состоялась в 1992 году, тогда же произошли первые стычки с дудаевцами. Никто тогда не мог предположить, что через два года на чеченской земле российская армия будет вести полномасштабные боевые действия.

1 декабря 1994 года батальон Голубятникова начал свой боевой путь от Моздока, через Грозный на Аргун. За время наступления воины-десантники подавили все очаги сопротивления противника, уничтожили два танка, три боевых машины пехоты, два автомобиля, одно противотанковое орудие. Внушительны были и боевые трофеи батальона – шесть 122-миллиметровых гаубиц, один танк, противотанковое орудие, сто сорок семь единиц стрелкового оружия…

1958 елның 18 июнендә Ставрополь краеның Шпак районы Татарка авылында укытучылар гаиләсендә туа.

1975 елның Казан Суворов училищесын тәмамлый һәм Рязань һава-десант училищесына укырга керә. Аны тәмамлагач, Ивановода взвод командиры, аннары Кировобадта рота командиры булып хезмәт итә. 1979 елдан 1999 елга кадәр парашютчы-десантчылар взводы командирыннан алып  парашютчы-десантчылар полкы командиры урынбасарына кадәр вазыйфалар башкара. Россия тынычлык урнаштыручы көчләре составында Югославиядә, аннары Кавказ артында махсус заданиеләр үти.

Чечня Республикасында хезмәт итүе Святослав Голубятников биографиясенең аерым бер бите булып тора.  Чечняга беренче командировкасы 1992 елда була, нәкъ шул чакта дудаевчылар белән беренче бәрелешләр килеп чыга. Ул вакытта ике елдан соң чечен җирендә Россия Армиясе чып-чын сугыш хәрәкәтләре алып барыр дип беркем дә фаразлый алмый әле.

1994 елның 1 декабрендә Голубятников батальоны Грозный аша Моздоктан Аргунга таба юл ала. Һөҗүм вакытында десантчы сугышчылар дошманның барлык каршылыкларын бастырып, ике танк, пехотаның өч хәрби машинасын, ике автомобиль, танкка каршы ата торган бер орудиене юк итәләр. Батальон 122 миллиметрлы алты гаубица, бер танк, танкка каршы ата торган орудие, 147 мылтык кулга төшерә.



Наиболее ожесточенные бои разгорелись в ночь с 1 на 2 января в районе железнодорожного вокзала Грозного. Почти в полном окружении батальон отразил 17 атак чеченских боевиков. Командир батальона гвардии подполковник Голубятников был на самых горячих участках, умело расставляя своих подчиненных на боевые позиции.

В ходе боев отважный комбат-десантник был ранен и контужен, но не покинул поле боя, а при отражении атак на командный пункт батальона лично уничтожил несколько боевиков.

Станислав Голубятников участвовал более чем в ста боях и в 24-х боевых операциях. За успешное ведение боевых действий он награжден двумя орденами Красной Звезды.

Гордость и боль звучит в словах Святослава Голубятникова, когда он вспоминает о тех днях: «Почему, спрашиваете, у нас в батальоне больше всех героев? Да потому что мы в Грозном в течение трех суток были одни. Все, кто пришел в Грозный, понесли потери и отошли на исходные рубежи. Мы же единственные, кто зашли и удержались. Поэтому 180 моих солдат и офицеров награждены орденами Мужества».

Указом Президента РФ от 17 апреля 1995 года за мужество и героизм, проявленные при наведении конституционного порядка в Чеченской Республике, гвардии подполковнику Голубятникову Святославу Николаевичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

С 1999 года Святослав Николаевич в запасе. Посвятил себя бизнесу. Живет в Рязани. Благотворительный фонд «Мещера» под его руководством помогает семьям боевых друзей. А сам герой встречается со школьниками и молодежью. Живет он обычной гражданской жизнью, и только Золотая Звезда Героя России напоминает о его славном боевом прошлом.

Аеруча рәхимсез сугышлар гыйнварның 1еннән 2сенә каршы төндә Грозный тимер юл вокзалы тирәсендә башлана. Тулысынча диярлек чолганышта калган килеш батальон чечен боевикларының 17 һөҗүмен кире кайтара. Батальон командиры – гвардия подполковнигы Голубятников иң «кайнар» участокларда булып, үз кул астындагы солдатларны сугышчан позицияләргә урнаштырып йөри.

Бәрелешләр вакытында курку белмәс десантчы-комбат яралана һәм контузия ала, ләкин сугыш кырын ташлап китми, ә батальонның команда пунктына ясалган һөҗүмне кире кайтарганда, шәхсән үзе берничә боевикны юк итә.

Святослав Голубятников йөздән артык сугышта һәм 24 хәрби операциядә катнаша. Хәрби хәрәкәтләрне уңышлы алып барганы өчен ул ике «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә.

Ул көннәрне искә төшергәндә, Святослав Голубятниковның сүзләрендә горурлык та, сызлану да чагыла: «Безнең батальонда геройлар нигә барысыннан да күбрәк, дип сорыйсызмы? Чөнки без өч тәүлек буена Грозныйда үзебез генә идек. Грозныйга килгәннәрнең барысы да күп югалтулар белән артка чигенде. Ә без – анда кергән һәм шунда кала алганнардан бердәнбер батальон. Шуңа күрә минем 180 солдатым һәм офицерым Батырлык орденнары белән бүләкләнде».

Чечня Республикасында конституциячел тәртип урнаштырганда күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен, РФ Президенты Указы нигезендә, 1995 елның 17 апрелендә гвардия подполковнигы Голубятников Святослав Николаевичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

1999 елдан бирле Святослав Николаевич запаста, бизнес белән шөгыльләнә, Рязаньда яши. Армия җитәкчелегендәге «Мещера» хәйрия-фонды сугышчан дусларының гаиләләренә булыша. Ә герой үзе мәктәп укучылары һәм яшьләр белән очрашуларга еш йөри. Ул гап-гади тормыш белән яши, бары тик Россия Герое Алтын Йолдызы гына аның данлы хәрби үткәне турында искәртеп тора.







# ГОРИН Виталий Николаевич

Родился 9 июля 1971 года в селе Крученая Балка Сальского района Ростовской области. В 1988 году окончил среднюю школу в поселке Гигант. С юности мечтал стать офицером и поэтому по направлению военкомата поступил в Казанское высшее танковое командное училище. В 1992 году молодого лейтенанта после окончания училища распределяют командиром танкового взвода во Владикавказ в Северо-Кавказский военный округ. Службу начал в 503-м мотострелковом полку 19-й мотострелковой дивизии. Воевал в составе группировки российских войск «Запад».

В 1992 году старшего лейтенанта Горина направляют в Чечню.

13 декабря 1994 года он получил первое боевое крещение. Первый бой штурмовой отряд, в котором был и Виталий Горин, принял у станицы Асиновская. Танк Горина шел первым, первым вступил в бой, подавив огневые точки боевиков и предотвратив тем самым большие потери наступающих.

24 декабря Горин в составе танковой роты вступил в сражение с боевиками у Алхан-Калы. Боевики сопротивлялись остервенело. Горина дважды контузило, но он продолжал умело командовать подчиненными.

В период штурма Грозного его танковый взвод был придан подразделению десантников, штурмовавших президентский дворец. И здесь старший лейтенант Горин в кровавых боях первых дней января 1995 года проявил себя лучшим образом. В самые критические моменты он сохранял хладнокровие и всегда грамотно выбирал позиции для

1971 елның 9 июлендә Ростов өлкәсенең Сальск районы Крученая Балка авылында туа. 1988 елда Гигант бистәсендә урта мәктәпне тәмамлый. Яшьтән үк офицер булырга хыяллана, һәм шуңа күрә хәрби комиссариат юлламасы белән Казан югары танк команда училищесына укырга керә. 1992 елны училище тәмамлаган яшь лейтенантны Владикавказдагы Төньяк Кавказ хәрби округына танк взводы командиры итеп билгелиләр. Үзенең хезмәтен 19 нчы мотоукчылар дивизиясенең 503 нче мотоукчылар полкында башлап җибәрә. Россия гаскәрләренең «Көнбатыш» төркеме составында сугыша.

1992 елны өлкән лейтенант Горинны Чечняга җибәрәләр.

1994 елның 13 декабрендә беренче тапкыр сугышчан чыныгу ала. Составында Виталий Горин да булган штурм отряды Асиново станицасы янында сугышка керә. Алдан барган Горин танкы сугышка беренче булып ташлана. Боевикларның ут ноктаcostалары сафтан чыгарып, һөҗүм итүчеләрне зур югалтулардан саклап кала.

24 декабрьдә Горин танк ротасы составында боевиклар белән Алхан-Кала янында сугыша. Боевиклар бик нык каршылык күрсәтә. Горин ике тапкыр контузия ала, ләкин командалык итүен туктатмый.

Грозныйны штурмлаган чорда – 1995 елның гыйнвар башында – аның танк взводы Президент сараен штурмлаучы десантчылар подразделениесе белән бергә була. Монда да канлы сугышларда лейтенант Горин үзен иң яхшы яктан күрсәтә. Иң авыр мизгелләрдә дә ул салкын кан-



своей машины. Огнем своего танка Горин уничтожил два танка противника, пять огневых точек и несколько десятков боевиков. Когда казалось, что путь для десантников был расчищен танковым орудийным огнем, в его машину попал очередной снаряд боевиков. Старший лейтенант Горин был ранен в обе ноги, но продолжал командовать экипажем и отражать атаки. Вызвав по рации подмогу, он приказал экипажу покинуть горящую машину, но сделать это успел только наводчик, так как после очередного попадания снаряда сдетонировал боекомплект, и мощный взрыв потряс машину… Так погиб мужественный офицер вместе со своим экипажем.

Указом Президента РФ от 12 марта 1997 года за мужество и героизм при выполнении специального задания старшему лейтенанту Горину Виталию Николаевичу присвоено звание Героя Российской Федерации.

Похоронили его на родине. Земляки помнят и чтят память отважного танкиста. Именем героя названа улица в поселке Гигант, на здании школы, где учился Виталий, установлена мемориальная доска, а на могиле – бюст героя.

лылыгын саклап кала һәм һәрвакыт машинасы өчен позицияләрне дөрес сайлый белә. Горин дошманның ике танкын, биш ун ноктасын һәм берничә дистә боевикны юк итә. Десантчыларга юлны чистартып бетердек дигәндә генә, аның машинасына дошман снаряды тия. Лейтенант Горинның ике аягы да яралана. Ләкин ул экипажга җитәкчелек итүен һәм дошман һөҗүмнәренә каршы торуын дәвам итерә. Рациядән ярдәм чакыргач, ул экипажына ут капкан машинаны ташлап чыгарга боерык бирә. Ләкин бер төзәүче генә чыгып өлгерә, тагын бер снаряд тигәч, танктагы боекомплект бик каты шартлый... Куркусыз офицер үзенең экипажы белән бергә шулай һәлак була.

Махсус задание үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен, РФ Президенты Указы нигезендә, 1997 елның 12 мартында өлкән лейтенант Горин Виталий Николаевичка Россия Федерациясе Герой исеме бирелә.

Аны туган ягында җирлиләр. Якташлары куркусыз танкистны онытмыйлар, истәлеген кадерләп саклыйлар. Гигант бистәсендә бер урам герой исеме белән атала, ул укыган мәктәп бинасына истәлек тактасы, ә каберенә аның бюсты куелган.







# ГРУДНОВ Игорь Сергеевич

Родился 2 декабря 1958 года в Чистополе Татарской АССР. Окончил среднюю школу, был призван и отслужил в армии. Решив стать военным, Игорь поступил в Орджоникидзевское высшее военное командное училище, которое окончил с отличием в 1992 году. После окончания училища занимал различные должности, неоднократно переводился в отстающие подразделения для их укрепления.

По ходу службы Груднов прошел по восходящей такие ступени – начинал командиром взвода, затем роты, был начальником штаба батальона в Управлении Внутренних войск МВД СССР по Украинской и Молдавской ССР. С 1989 года проходил службу в Управлении войск по Дальнему Востоку и Восточной Сибири. В 90-е годы командовал бригадой Внутренних войск на Северном Кавказе, участвовал в первой чеченской войне. С 1997 года – заместитель командира дивизии в Северо-Кавказском округе Внутренних войск МВД.

С октября 1999 года полковник Игорь Груднов участвовал в боях второй чеченской войны в составе Объединенной группировки российских войск на Северном Кавказе. Был начальником штаба группировки Внутренних войск МВД «Север». Принимал активное участие в руководстве боевыми действиями по освобождению от боевиков населенных пунктов Галашек, Аршты и Бамут. В декабре 1999 года был назначен командующим войсками этой группировки, перед которой была поставлена задача штурма Грозного и его блокирования с севера. В состав группировки входили 22-я и 8-я бригады специального назначения внутренних войск.

1958 елның 2 декабрендә Татарстан АССРның Чистай шәһәрендә туа. Урта мәктәпне тәмамлый, армиядә хезмәт итеп кайта. Хәрби кеше булырга карар иткәч, Игорь Орджоникидзе югары хәрби команда училищесына укырга керә, аны «бик яхшы» билгеләренә 1992 елны тәмамлый. Шуннан соң төрле вазыйфалар башкара, берничә тапкыр артта калучы подразделениеләрне ныгыту өчен күчерелә.

Хезмәте барышында Груднов мондый баскычларны үтә: взвод командиры, рота командиры, СССР ЭЭМның Украина ССР һәм Молдавия ССР буенча Эчке гаскәрләр идарәсендә штаб начальнигы. 1989 елдан башлап Ерак Көнчыгыш һәм Көнчыгыш Себер гаскәрләре идарәсендә хезмәт итә. Узган гасырның 90 нчы елларында Төньяк Кавказда Эчке эшләр гаскәрләре бригадасына җитәкчелек итә, беренче чечен сугышында катнаша. 1997 елдан – ЭЭМның эчке эшләр гаскәрләре Төньяк Кавказ дивизиясенең командир урынбасары. 1999 елның октябреннән полковник Игорь Груднов Россия гаскәрләренең Төньяк Кавказдагы Берләшкән төркеме составында икенче чечен сугышында катнаша. ЭЭМның «Төньяк» Эчке эшләр гаскәрләре төркеме штаб начальнигы була. Галашек, Аршты һәм Бамут авылларын боевиклардан азат иткән сугыш хәрәкәтләре белән актив җитәкчелек итә. 1999 елның декабрендә бу төркемнең гаскәр командующие итеп билгеләнә. Төркем алдына Грозныйны штурмлау һәм аны төньяктан чолгап алу бурычы куелган була, төркем составына эчке гаскәрләрнең махсус билгеләнештәге 22 нче һәм 8 нче бригадалары керә.

На долю бойцов этой группировки выпала задача по взятию мощного узла сопротивления боевиков на территории молочного и консервного заводов в Грозном. Это происходило во второй декаде января 2000 года.

На счету полковника Груднова немало ратных свершений. Как известно, авторитет командира определяется его отношением к своим подчиненным. А подчиненные Груднова говорят, что полковник не прятался за спины солдат, всегда был на самых горячих и опасных участках боя. Таких, как Игорь Сергеевич, в войсках зовут «батя». В солдатской среде это высшая степень уважения и почитания командира.

До штурма Грозного полковник Груднов со своими подразделениями участвовал в удержании восемнадцати высот, обеспечивал проход частей Российской армии по горной дороге Галашки – Аршты – Бамут. Организовывал спецоперации по поиску и разоружению террористов в населенных пунктах Урус-Мартан, Чечен-Аул, Пригородный и Гойское. Изымал оружие и боеприпасы, проводил разминирование, работал с местным населением.

В ходе боевой операции в Грозном и его пригороде было уничтожено 20 и ранено 30 боевиков из специального отряда Шамиля Басаева и более двухсот выведено из строя из других бандформирований. Эта операция, проведенная с 7 по 19 января 2000 года, была разработана и подготовлена полковником Грудновым.

Многие командиры и бойцы подразделений оперативного назначения, действуя в составе штурмовых отрядов, не задумываясь, шли на подвиги и поэтому заслуженно удостоены звания Героя России, медали «За отвагу», ордена Мужества.

3 янаря 2000 года удалось отбить от боевиков кирпичный завод. Группа бойцов, закрепившихся в нем, стойко отражала новые и новые атаки боевиков.

Николай Асташкин в своей книге «Подвиг Солдата» приводит такие слова Игоря Сергеевича о тех днях:

«Мы все – и армейские, и наши подразделения – выполняли одну задачу – уничтожали боевиков, засевших в городе. 5 января в районе автохозяйства нам противостояла большая группа ваххабитов – примерно 100-150 человек. Командовал ими Шамиль Басаев. Заблокировав этот объект, я стал размышлять, как же с наименьшей кровью им овладеть. Накануне из Моздока на вертолете мне доставили два специальных карабина, боеприпасы к которым были оснащены спецсредством «Черемуха-1». И вот два наших бойца стали аккуратненько постреливать из них патронами со слезоточивым газом по каждому окошку высотного здания. Ваххабиты подумали, что мы применили неизвестное химическое средство и без боя оставили этот объект. Но это редкий случай солдатской удачи. А так выматывающие бои шли за каждый дом, за каждую улицу. Весь конец декабря и первые дни нового, 2000-го года солдаты и командиры группировки «Север» дрались с боевиками на территории Ленинского района. В конце первой декады января вышли на рубеж: кирпичный завод – СПТУ-12 – левый берег реки Сунжи. В ста метрах стояли корпуса консервного и молочного заводов, превращенные боевиками в неприступные крепости. Здесь и минные поля, и хорошо простреливаемые территории, и окопавшиеся на заводах боевики.

Грозныйдагы сөт һәм консерв заводлары территориясендә боевикларның бик куәтле каршы тору ноктасын яулап алу бурычы шушы төркем сугышчылары өстенә төшә. Бу хәл 2000 елның гыйнвар уртасында була.

Полковник Груднов шактый күп сугышчан батырлыклар күрсәтә. Билгеле булганча, командирның абруе үз кул астындагы кешеләргә карата мөнәсәбәте белән билгеләнә. Ә алар полковникның солдатлар артына яшеренмәвен, һәрвакыт сугышның иң кайнар һәм куркыныч участокларында булуын әйтә. Игорь Сергеевич кебекләрне гадәттә үзара «батя» дип йөртәләр. Солдатлар арасында бу – командирны хөрмәтләүнең иң югары дәрәҗәсе.

Грозныйны штурмлауга кадәр  полковник Груднов үз подразделениеләре белән бергә 18 биеклекне тотып торуда катнаша, Россия Армиясе частьларының  Галашки-Аршты-Бамут тау юлы аша үтүен тәэмин итә. Урус-Мартан, Чечен-Аул, Пригородный һәм Гойск авылларында террорчыларны эзләү һәм коралсызландыру буенча махсус операцияләр оештыра. Аларның коралларын  һәм сугыш кирәк-яракларын тартып ала. Миналарны зарарсызландыра, җирле халык белән эшли.

Хәрби операция барышында Грозныйда һәм аның тирәсендә Шамил Басаев отрядының 20 боевигы үтерелә һәм 30ы яралана, башка бандит төркемнәренең 200дән артык  кешесе сафтан чыгарыла. 2000 елның 7 гыйнварыннан 19 гыйнварына кадәр үткәрелгән бу операция полковник Груднов тарафыннан әзерләнә.

Оператив билгеләнештәге подразделениеләрнең күп командирлары һәм сугышчылары, штурмлау отрядлары составында булып, ике дә уйламый, батырлыклар күрсәтә. Шуңа күрә Россия Герое исеменә, «Батырлык өчен» медальләренә, Батырлык  орденына лаек була.

2000 елның 3 гыйнварында боевиклар кулыннан кирпеч заводын тартып алу мөмкин була. Кереп урнашкан сугышчылар төркеме боевикларның яңадан-яңа һөҗүмнәрен  кире кайтарып тора.

«Солдат батырлыгы» дигән китабында Николай Асташкин Игорь Сергеевичның ул көннәр турындагы мондый сүзләрен китерә:

«Без барыбыз да – армиянекеләр дә, безнең подразделениеләр дә  – бер үк бурычны үтәдек, шәһәрдә урнашкан боевикларны юк иттек. 5 гыйнвар көнне автохуҗалык тирәсендә безгә чама белән 100-150 кешедән торган ваһһабчылар төркеме һөҗүм итте. Аларның җитәкчесе Шамил Басаев иде. Бу объектны әйләндереп алгач, ничек итеп канны азрак коеп, аны үзебезнеке итәргә икән дип уйлый башладым. Алдагы көнне Моздоктан миңа «Черемуха-1» дип аталган матдәле ике махсус карабин, боеприпаслар кайтарганнар иде. Һәм менә безнең ике сугышчы шулардан биек бинаның һәрбер тәрәзәсенә күз яше агыза торган газ тутырылган патроннар белән әйбәтләп кенә ата башладылар. Ваһһабчылар, безне моңарчы булмаган химик матдә кулланды дип уйлап, объектны сугышсыз гына калдырып чыктылар. Ләкин бу – солдат уңышының бик сирәк очрагы гына. Ә башка вакытта хәлне ала торган сугышлар һәр йорт, һәр урам өчен барды. Декабрь азагында һәм яңа 2000 елның беренче көннәрендә «Төньяк» төркеме солдатлары һәм командирлары боевиклар белән Ленин районы территориясендә сугыштылар. Гыйнварның беренче декадасы азагында кирпеч заводы – СПТУ-12 – Сунжа





На совещании с командирами на подготовку штурма заводов я отвел две недели. Сам согласовывал с артиллеристами и армейцами планы взаимодействия. И вот началось. Двое суток шел бой. Огнем артиллерии уничтожили шесть дотов противника, подавили 32 их огневые точки, вывели из строя более двухсот боевиков, еще 23 взяли в плен. Заводы были отбиты у боевиков.

Теперь перед войсками была река Сунжа. В ночь на 26 января личный состав форсировал реку и укрепился в русской и мусульманской школах на правом берегу. Вскоре разведка доложила, что человек пятьдесят боевиков в нашей форме, не скрываясь, «косят» под армейскую разведку.

В семь часов утра части восьмой бригады вступили в бой с диверсионным отрядом Шамиля Басаева. Столкнувшись с войсками, басаевцы пошли напролом. Пулеметчик рядовой Раис Мустафин только успевал менять ленты. Шесть часов шел бой. Солдаты выстояли. Отряд Басаева был уничтожен. Мы потеряли четверых, в том числе и лейтенанта Комарова, у которого незадолго до боя родилась дочь».

Воодушевленные победой, бойцы полковника Груднова вскоре овладели центром города. С боями заняли улицы Богдана Хмельницкого, Жуковского и Первомайскую. 3 февраля вышли на улицу Мира и овладели резиденцией президента самопровозглашенной Ичкерии и соединилась с наступавшими навстречу войсками.

«Во время штурма Грозного были моменты, когда полковник Груднов, находясь на крыше здания, по 10-12 ча-

елгасының сул як яры чигенә чыктылар. Шуннан 100 метр ераклыкта боевиклар тарафыннан якын килеп булмаслык крепостька әйләндерелгән консерв заводы һәм сөт заводы корпуслары тора. Монда мина кырлары да, ачык территорияләр дә, заводларда ныклап урнашкан боевиклар да бар.

Командирлар белән киңәшкәч, заводларны штурмлауга мин ике атна вакыт билгеләдем. Үзем артиллеристлар һәм армиячеләр белән хезмәттәшлек итү планнарын килештереп куйдым. Башланып киткән сугыш ике тәүлек барды. Артиллерия уты ярдәмендә дошманның алты дотын юк иттек, 32 ут ноктасын бастырдык, 200дән артык боевикны сафтан чыгардык, тагын 23ен әсирлеккә алдык. Заводлар боевиклардан тартып алынды.

Хәзер инде гаскәрләр алдында Сунжа елгасы тора иде. 26 гыйнварга каршы төндә солдатлар елганы кичеп чыкты һәм уң як ярдагы рус һәм мөселман мәктәпләренә ныгып урнашты. Бераздан разведка безнең форманы кигән иллеләп боевикның, яшеренеп тә тормыйча, армия разведкасы булып кылануын хәбәр итте.

Иртәнге сәгать җидедә сигезенче бригада частьлары Шамил Басаевның диверсия отрядына каршы сугышка керде. Пулеметчы рядовой Рәис Мостафин ленталарны алмаштырырга көчкә өлгерә иде. Сугыш алты сәгать барды. Солдатлар бирешмәделәр, Басаев отряды юк ителде. Без дүрт кешене, шул исәптән лейтенант Комаровны да (аның сугыш алдыннан гына кызы туган иде) югалттык».

Полковник Грудновның җиңү шатлыгыннан канатланган сугышчылары озак та үтми шәһәр үзәген: Богдан Хмель-

сов управлял огнем своей артиллерии, – пишет в своей книге Николай Асташкин. – Подчиненных прятал в амбразуры, чтобы не было лишних потерь, сам же по рации под пулями бандитов корректировал огонь артиллерийских и минометных батарей своей группировки.

Спрашиваю Игоря Сергеевича:

– Что в боевой обстановке самое опасное для бойца?

– Расслабиться. И особенно после 12 ночи, когда солдат, измотанный дневными боями, буквально спит на ходу и может погибнуть от шальной пули. Помню, после очередного боя, когда над городом опустился туман, я прислонился к стене дома: глаза слипались от усталости. И вдруг вижу: прямо в меня рикошетом летит трассер. Спасла мгновенная реакция – в прошлом ведь я занимался боксом. Сделал нырок – и пуля плюхнулась в стенку.

За проявленное мужество в боях и умелое руководство войсками в борьбе с террористическими формированиями на Северном Кавказе указом Президента РФ от 29 февраля 2000 года полковнику Груднову Игорю Сергеевичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

Летом 2000 года отважный командир бригады был назначен заместителем военного коменданта Чеченской Республики. Во время одной из спецопераций в Ножай-Юртовском районе Чечни в августе 2001 года в составе колонны внутренних войск он попал в засаду боевиков и получил тяжелое огнестрельное ранение в грудь. Несмотря на ранение, полковник продолжал командовать войсками. Организовав оборону, отбивались от боевиков до тех пор, пока не подоспели вертолеты боевой поддержки. Вражеская атака была отбита. Наши потери составили два погибших и несколько раненых. Сам командир несколько месяцев после этого лечился в госпитале.

В 2004 году Игорь Сергеевич окончил Военную академию Генштаба Вооруженных Сил Российской Федерации и был назначен заместителем командующего войсками Сибирского военного округа. Несколько месяцев был помощником командующего Смешанными силами по поддержанию мира в Южной Осетии. С сентября 2005 года генерал-майор И.С. Груднов – первый заместитель командующего войсками Сибирского военного округа Внутренних войск МВД. С 2011 года по настоящее время – первый заместитель командующего войсками Северо-Кавказского регионального командования ВВ МВД РФ.

ницкий, Жуковский һәм Беренче Май урамнарын яулап ала. 3 февральдә Тынычлык урамына чыга һәм Ичкерия Президенты резиденциясен алып, каршы яктан һөҗүм итеп килгән гаскәрләр белән кушылалар.

«Грозныйны штурмлаганда полковник Грудновның, бина түбәсендә торып, 10-12 сәгать буе үз артиллериясе белән идарә иткән чаклары да булды, – дип яза Николай Асташкин үз китабында. – Артык югалтулар булмасын өчен, кул астындагыларны амбразураларга качыра, ә үзе бандитлар пулясы астында рация аша төркеменең артиллерия һәм миномет батареяларының утын кирәк җиргә юнәлтеп тора.

Игорь Сергеевичтан:

– Сугыш вакытында сугышчы өчен иң куркынычы нәрсә? – дип сорыйм.

– Игътибарны йомшарту. Аеруча төнге сәгать 12дән соң. Ул чакта көндезге сугышларда хәлдән тайган солдат аягүрә йоклап йөри һәм очраклы пулядан һәлак булырга мөмкин. Хәтерлим әле: чираттагы сугыштан соң, шәһәр өстенә томан төшкәч, мин йорт стенасына сөялдем, арганлыктан күзләрем йомыла иде. Берзаман карасам, рикошет ясап, туп-туры миңа таба трассер очып килә. Мизгел эчендә уйлап өлгерүем генә коткарды (элек мин бокс белән шөгыльләнгән идем бит). Мин иелеп калдым, ә пуля стенага килеп бәрелде.

Төньяк Кавказда сугышларда күрсәткән батырлыгы һәм террорчы формированиеләр белән көрәштә гаскәрләргә белеп җитәкчелек иткәне өчен, РФ Президенты Указы нигезендә 2000 елның 29 февралендә полковник Груднов Игорь Сергеевичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла. 2000 елның җәендә куркусыз бригада командиры Чечня Республикасы хәрби коменданты урынбасары итеп билгеләнә. 2001 елның августында Чечняның Ножай-Юрт районындагы махсус операция вакытында эчке гаскәрләр колоннасы составында ул боевиклар засадасына очрый һәм күкрәгенә авыр яра ала. Яралануына карамастан, полковник гаскәрләр белән җитәкчелек итүен дәвам иттерә. Оборона оештырып, хәрби ярдәм вертолетлары килеп җиткәнчегә кадәр, боевикларга каршы торалар. Дошман һөҗүме кире кайтарыла. Безнең югалтулар ике һәлак булучыны һәм берничә яралыны тәшкил итә. Командир үзе шуннан соң берничә ай госпитальдә дәвалана.

2004 елны Игорь Сергеевич Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең + Генераль штабының хәрби академиясен тәмамлый һәм Себер хәрби округы гаскәрләре командующие урынбасары итеп билгеләнә. Берничә ай Көньяк Осетиягә тынычлык саклаучы катнаш көчләр командующие ярдәмчесе була. 2005 елның сентябреннән генерал-майор И.С.Груднов – ЭЭМ Эчке гаскәрләренең Себер хәрби округы гаскәрләре командующиенең беренче урынбасары.







# ДАУДИ (САФИН) Ильяс Дильшатович

Родился в 1967 году в Азнакаево. Окончил среднюю школу № 2, запомнившись педагогам своей активностью. Он рано увлекся спортом, а именно боксом, и благодаря своей настойчивости и целеустремленности быстро добился хороших спортивных результатов. Неоднократно с успехом участвовал в республиканских и всероссийских боксерских турнирах, стал кандидатом в мастера спорта СССР.

Рос Ильяс в интеллигентной, трудолюбивой семье. Мама, Раиса Ахмадулловна, – заслуженный врач РСФСР, почетный гражданин города Азнакаево. Отец, Дильшат Мисбахетдинович, – главный инженер одного из местных предприятий. Родители рассказывают, что с 13 лет Ильяс стал сам зарабатывать себе на хлеб, помогая взрослым ремонтировать двигатели «КамАЗов», трудясь разнорабочим в Азнакаевском управлении буровых работ ОАО «Татнефть». После школы поехал в Москву поступать в институт нефти и газа им. И.М. Губкина. Учился легко и успешно.

В те годы шла афганская война, и многие друзья и сверстники Ильяса, будучи призваны в армию, уже понюхали боевого пороха, а иные и головы сложили на поле брани. Ильяс, как истинный патриот, считал, что не вправе оставаться в стороне и понес в военкомат Гагаринского

1967 елда Азнакайда туа. 2 нче номерлы урта мәктәпне тәмамлый, актив булуы белән укытучыларның исендә кала. Ул яшьтән үк спорт белән, бигрәк тә бокс белән мавыга һәм үзенең үҗәтлеге һәм максатка омтылучанлыгы аркасында спортта яхшы нәтиҗәләргә тиз ирешә. Еш кына республика һәм бөтенроссия боксчылар турнирларында уңышлы катнаша, СССРның спорт мастерлыгына кандидат була.

Ильяс зыялы, хезмәт сөючән гаиләдә үсә. Әнисе Рәисә Әхмәдулла кызы – РСФСРның атказанган табибы, Азнакай шәһәренең мактаулы гражданины. Әтисе Дилшат Мисбахетдин улы – бер җирле предприятиедә баш инженер. 13 яшеннән үк Ильяс, «КамАЗ» моторларын ремонтлауда өлкәннәргә булышып, «Татнефть» ААҖнең Азнакай бораулау эшләре идарәсендә төрле эшләрдә эшләп, акча эшли башлады, дип сөйли әти-әнисе. Мәктәпне тәмамлаганнан соң И.М.Губкин исемендәге нефть һәм газ институтына керергә дип Мәскәүгә китә. Җиңел һәм әйбәт укый.

Ул елларда Әфган сугышы бара, Ильясның күп кенә дуслары һәм яшьтәшләре, армиягә алынып, сугышчан дары исен иснәргә өлгерә, ә кайберләре сугыш кырында башларын сала. Чын патриот буларак, Ильяс читтә калырга хоку-

(тогда Черемушкинского) района Москвы заявление с просьбой отправить его в одну из частей в Афганистане.

Известно, что подавляющее большинство советских солдат, воевавших в Афганистане, это были парни с рабочими мозолями на руках, колхозная молодежь, выпускники профессионально-технических училищ, молодые офицеры. Чтобы со студенческой скамьи в звании кандидата в мастера спорта СССР парень добровольцем попросился в Афган – такое было наверняка не так часто!

Вскоре Ильяс попал в Туркестанский военный округ. В Термезском учебном центре войсковой разведки он стал постигать военную науку, а между делом выиграл первенство учебного полка по боксу. Перспективному будущему младшему командиру предложили остаться в учебном полку, но Ильяс был непреклонен. В первых числах августа 1985 года он стал старшим разведчиком взвода наблюдения разведывательной роты 149-го гвардейского полка 201-й мотострелковой дивизии, уже проявившей себя в боях с моджахедами.

Потекли полные тревог и опасностей боевые будни. В октябре 1985 года в провинции Баглан проводилась войсковая операция. Разведчику Сафину и старшему лейтенанту переводчику Халтураеву было поручено раздобыть документы из оставленного моджахедами командного пункта. Спустившись в ущелье, разведчики попали в засаду. Отстреливаясь, они стали отходить назад. В ста метрах от дувалов, где можно было хоть как-то укрыться, старший лейтенант был тяжело ранен. Под непрекращающимся огнем Ильяс взвалил раненого на спину и отполз в укрытие. Там он оказал ему первую помощь и в течение сорока минут, пока не подоспела помощь, в одиночку отбивался от наседавших душманов. За этот неравный бой и спасение раненого офицера разведчик Сафин был награжден орденом Красной Звезды.

О том, как нес свою ратную службу Ильяс Дауди, вот что написал в своих мемуарах командир 149-го мотострелкового полка, впоследствии генерал-полковник Александр Скородумов:

«Спустя много лет, достигнув высоких должностей и воинских званий, я хочу донести до нынешнего российского офицерства очень важную истину. Все эти годы она жила во мне, помогая преодолевать трудности ратной службы, неустроенности гарнизонного быта, всевозможных лишений и последствий смены в стране как жизненных, так и просто общечеловеческих ценностей.

Предо мной всегда безгранично дорогими воспоминаниями предстают лица солдат из 149-го гвардейского мотострелкового полка, которым мне выпала честь командовать в Афганистане. Они прошли со мной сквозь горнило той войны и вынесли на своих юношеских плечах всю тяжесть этого непростого, а порой и неблагодарного труда. На всю оставшуюся жизнь они для меня – особая гордость, эталон высочайшего мужества и героизма.

О подвиге одного из своих гвардейцев я и хочу рассказать…

…Афганистан, август 1986 года. Уже три с половиной месяца, как я, командир полка, переслуживал положенный срок пребывания в ДРА. И замена прибыла, и вещи собрал, но, очевидно, не судьба была тогда вылететь в Союз домой, к семье.

кым юк дип саный һәм Мәскәүнең Гагарин (Черемушки) хәрби комиссариатына үзен Әфганстандагы частьларның берсенә җибәрүне сорап гариза илтә.

Әфганстанда сугышкан совет солдатларының күпчелеге эшче егетләр, колхоз яшьләре, һөнәри техник училищелары тәмамлаучылар, яшь офицерлар булуы билгеле. СССРның спорт мастерлыгына кандидат студент егетнең үзе теләп Әфганстанга китүе – сирәк очракларның берседер, мөгаен.

Тиздән Ильяс Төркестан хәрби округына эләгә. Термез гаскәри разведка уку-укыту үзәгендә ул хәрби фәннәрне өйрәнә башлый, шул арада үзе укыган полкта бокс буенча беренчелекне ала. Булачак кече командирга уку-укыту полкында калырга тәкъдим итәләр. Ләкин ул үз сүзеннән кайтмый. 1985 елның август башларында мөҗәһитләр белән сугышларда үзен күрсәтергә өлгергән 201 нче мотоукчылар дивизиясенең 149 гвардия полкы разведка ротасы күзәтчелек взводының өлкән разведчигына әверелә.

Борчулар һәм куркынычлар тулы сугыш көннәре үтә тора. 1985 елның октябрендә Баглан провинциясендә гаскәри операция уздырыла. Разведчик Сафинга һәм өлкән лейтенант тәрҗемәче Халтураевка мөҗәһитләр ташлап киткән команда пунктыннан документлар алып кайтырга кушыла. Тарлавыкка төшкәч, разведчиклар засадага эләгә. Атыша-атыша, алар артка чигенә башлыйлар. Яшеренергә мөмкин булган дуваллардан сигез метр арада өлкән лейтенант авыр яралана. Берөзлексез явып торган ут астында Ильяс, яралыны үзенең җилкәсенә салып, ышык җиргә шуышып килә. Анда ул егеткә беренче ярдәм күрсәтә. һәм килеп ярдәм килеп җиткәнчегә кадәр 40 минут буе һөҗүм итүче дошманнар белән атыша. Бу тигезсез сугышта катнашуы һәм яралы офицерны коткаруы өчен разведчик Сафин Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

149 нчы мотоукчылар полкы командиры генерал-полковник Александр Скородумов үзенең мемуарларында Ильяс Даудиның хәрби хезмәтен ничек үтәве турында соңыннан болай дип язды:

«Күп еллар үтеп, югары вазыйфаларга һәм хәрби исемнәргә ирешкәч, мин хәзерге Россия офицерларына бик мөһим хакыйкатьне җиткермәкче булам. Шушы еллар буенча хәрби хезмәтнең авырлыкларын, гарнизондагы көнкүрешнең начар шартларын, төрле-төрле чикләүләрне һәм илебездәге тормышның, шулай ук гомумкешелекнең кыйммәтләре үзгәрүне җиңәргә ярдәм итеп, ул минем күңелемдә яшәде.

Әфганстанда үзем командалык иткән 149 нче гвардия мотоукчылар полкы солдатлары һәрвакыт чиксез кадерле хатирәләр булып күз алдымда торалар. Алар минем белән бергә шул сугыш уты аркылы үттеләр һәм бу катлаулы һәм вакыты-вакыты белән кадерсез хезмәтнең бөтен авырлыгын үзләренең яшүсмер иңнәрендә күтәрделәр. Калган бөтен гомеремә алар минем өчен – аеруча зур горурлык, бөек батырлык һәм каһарманлык эталоны.

Үземнең гвардиячеләремнең берсе күрсәткән батырлык турында сөйләргә телим…

…Әфганстан, 1986 елның августы. Полк командиры буларак, ӘДРда булуымның тиешле срогы беткәнгә дә өч ай ярым узып киткән. Алмашка кеше дә килде, әйберләремне



Утром 20 августа меня вызвали в штаб 201-й мотострелковой дивизии, где комдив поставил задачу срочно перебросить полк вертолетными бортами в провинцию Герат, в район ирано-афганской границы. Предстояло участие в войсковой операции под кодовым названием «Западня».

Поздно вечером того же дня мы уже были на аэродроме Герата. Сразу приказал личному составу отдыхать. Едва рассвело, как мотострелков подняли на строевой смотр в целях проверки наличия необходимого количества боеприпасов и провизии. Уже через сорок минут личный состав полка разделили на группы, и мы стали ждать команду грузиться в вертолеты.

Десантировались близ населенного пункта Кокари-Шоршари. Среди «афганцев» это место слыло худым и «славилось» своими оборонными укреплениями. Нам предстояло их уничтожить, а также захватить склады оружия и боеприпасов банды моджахедов под командованием полевого командира Турана Исмаил-шаха.

Приблизительно через тридцать минут мы уже подлетели к месту высадки. Выжженная земля, низкие по афганским меркам горы, сухое русло реки Герируд – место, где по топографической карте проходит граница Афганистана с Ираном.

Не успели «вертушки» уйти от места десантирования, как по нам стали вести прицельный минометный огонь. Появились раненые. Судя по плотности обстрела, было очевидным, что зона высадки десанта пристреляна и в ней

дә җыйган идем, ләкин ул чакта союзга өемә – гаиләмә яныңа кайтып китәргә язмаган булган, күрәсең.

20 август иртәсендә мине 201 нче мотоукчылар дивизиясе штабына чакырып алдылар. Дивизия командиры полкны вертолетларга төяп, ашыгыч рәвештә Иран-Әфганстан чигендәге Герат провинциясенә күчерергә боерык бирде. Код исеме «Тозак» дип аталган гаскәри операциядә катнашырга тиеш идек.

Шул ук кичне без инде Герат аэродромында идек. Килеп җитүгә үк солдатларга ял итәргә боерык бирдем. Таң атар-атмас, мотоукчыларны, боеприпаслар һәм азык-төлекнең җитәрлек булуын тикшерү өчен, строевой смотрга күтәрделәр. Кырык минуттан соң ук полкның солдатларын төркемнәргә бүлделәр һәм без вертолетларга төялү өчен боерык көтә башладык.

Десант Кокари-Шоршари авылы янына төшәргә тиеш иде. «Әфганчы»лар арасында бу урын начар җир дип санала һәм саклану ныгытмалары белән даны чыккан иде. Без аларны юк итәргә, шулай ук кыр командиры Туран Исмәгыйль-шаһ җитәкчелегендәге мөҗәһитләр бандасының корал һәм боеприпаслар складларын яулап алырга тиеш булдык.

Чама белән 30 минут үткәч, без төшеп утыру урынына очып килеп җиттек. Янган-көйгән җир, Әфганстан өчен тәбәнәк таулар, кипкән Герируд елгасы – топографик картада Әфганстанның Иран белән чиге шуннан уза.

Вертолетлар безне төшереп китәргә дә өлгермәделәр, безгә тәбәп минометлар ут ачты. Яралылар да барлыкка

нас, шурави, терпеливо ждали. В этой ситуации, оказавшись фактически на минном поле, сержант Сафин приказал подчиненным оставаться на местах и прикрывать его огнем. А сам, взяв саперный щуп и медикаменты, в одиночку пополз на выручку попавшим в беду товарищам. В лежачем положении, не подымая головы под шквальным обстрелом моджахедов, он перевязал одного за другим троих раненых и по очереди вытащил их на себе с минного поля, имея сам ранение в предплечье.

Конечно, я сразу узнал гвардии старшего сержанта Ильяса Сафина, или, как нарек он себя позже, Дауди, как узнал бы среди тысяч солдат,– он был у нас известной «личностью» по десяткам его "хулиганских подвигов» и выходок в расположении полка. Если где какой-то «междусобойчик» или в столовой у повара либо на продскладе что-то пропало, сразу ищи след Ильяса. Однако, что касается боевых выходов, тут уж Дауди равных не было. Всю службу ходил по горам, всегда в дозоре. Ни одной пропущенной операции!

Отдав все необходимые распоряжения по эвакуации раненых бойцов, я приказал офицерам срочно и на максимально большую дистанцию отвести свои подразделения из пристрелянной зоны минометного огня. А второму батальону поставил боевую задачу – выдвинуться по высотам и в кратчайший срок преодолеть расстояние до позиций душманов.

В ходе продолжительных и ожесточенных боев в течение двух суток запас боеприпасов иссякал. Прицельный огонь душманов из гранатометов и зенитных установок не давал возможности нашим вертолетам выгрузить боеприпасы и эвакуировать раненых. Батальон нес большие потери. Однако в этой тяжелой и нервной ситуации боевой дух бойцов не был сломлен. Несмотря на пятидесятиградусную жару, обезвоживание организма, главное, о чем думали мотострелки, – о боеприпасах. Одна мысль: лишь бы не остаться без патронов! А бой начинался с восходом солнца и заканчивался на закате.

Используя все преимущества своего укрепрайона, одурманенные наркотиками арабские и иранские наемники выпускали из зенитных установок залпы огня по нашим штурмовикам Су-24 – «грачам», обеспечивавшим обескровленному батальону поддержку с воздуха. Один раз при смене очередной тройки штурмовиков моджахед-стрелок зенитной установки на глазах у нас сбил одного «грача»…

Мы вступили в третий день этой страшной бойни. Запасы воды закончились. Все попытки сбросить с «вертушек» емкости с водой терпели неудачу. Ударяясь о каменную твердь, они с грохотом разрывались, и вода уходила в землю.

24 августа в пять часов утра с двух вертолетов Ми-8 на удаленные от места боя высоты удалось-таки сбросить так необходимые батальонам боеприпасы и питьевую воду. Комбат гвардии майор Малолетко поставил ротным задачу: выделить от каждого подразделения по пять человек для доставки груза на боевые позиции.

Командир роты поставил гвардии старшему сержанту Дауди задачу выделить из его подразделения пятерых человек для транспортировки боеприпасов на позиции. Но Ильяс, сославшись на знание горных троп, убедил ротного

килде. Атуның тыгызлыгына караганда, монда безне – шуравиларны – сабыр гына көтеп торганлыклары ачык иде. Мина кырында калган шушы вәзгыятьтә сержант Сафин солдатларга урыннарыннан кузгалмаска һәм үзен ут белән каплап торырга боерды. Ә үзе, сапер көрәге һәм медикаментлар алып, бәлагә тарыган иптәшләрен коткару өчен, бер ялгызы шуышып китте. Яткан көенә, мөҗәһитләрнең бертуктаусыз атып торуы аркасында башын күтәрмичә, үзенең дә кулы яралы килеш, ул бер-бер артлы өч яралыны бәйләде һәм үз җилкәсенә салып, аларны мина кырыннан өстерәп алып чыкты.

Әлбәттә, мин шунда ук гвардия өлкән сержанты Ильяс Сафинны (соңрак ул үзен Дауди дип йөртә башлады) танып алдым. Мин аны мең солдат арасыннан да таныган булыр идем: ул безнең полкта уннарча «хулиган батырлыклары» күрсәтеп, шактый танылган шәхес иде. Берәр җирдә «үзара бәрелеш» килеп чыкса, яки ашханәдән яисә азык-төлек складыннан берәр нәрсә югалса, Ильяс эзен эзлә инде. Ләкин сугыш хәрәкәтләренә килгәндә, монда Даудига тиңнәр юк иде. Хезмәт иткән вакытында һәрчак тауларда дозорда йөрде. Һәм бер генә операцияне дә калдырмады!

Яралы сугышчыларны эвакуацияләү буенча бөтен кирәкле боерыкларны биреп бетергәч, мин офицерларга үз подразделениеләрен миномет уты ява торган зонадан ашыгыч рәвештә һәм мөмкин кадәр еракkарак илтеп урнаштырырга куштым. Ә икенче батальонга, таучыклар буенча хәрәкәт итеп, иң кыска срокта дошманнар позицияләренә кадәрге араны үтү бурычын куйдым.

Ике тәүлек буе барган туктаусыз һәм рәхимсез сугышларда боеприпасларыбыз кимеде. Дошманнарның гранатометлардан һәм зенит җайланмаларыннан төбәп атып торуы безнең вертолетларга боеприпасларны бушатырга һәм яралыларны алып китәргә ирек бирми иде. Батальон зур югалтуларга дучар булды. Ләкин шушы авыр хәлдә дә солдатларның сугышчан рухы сынмады. Илле градус кызуда, үтереп эчәсе килгәндә дә мотоукчылар бары тик боеприпаслар турында гына уйладылар. Башларында бер генә уй: патрон гына бетмәсен! Ә сугыш таң атканда башланып, кояш баегач кына тәмамлана.

Үзләре ныгыткан районның бөтен өстенлекләреннән файдаланып, наркотиклардан тилергән ялланган гарәп һәм иранлылар безнең «Су-24» штурмовикларына («кара карга»ларыбызга) зенит җайланмаларыннан ут залпларын биреп кенә торалар. Бервакыт штурмовикларның чираттагы өчлеге алмашынган чакта, зенит җайланмасыннан атып, үз күз алдыбызда мөҗәһит бер «кара карга»ны бәреп төшерде…

Без бу куркыныч үтерешнең өченче көненә аяк бастык. Су запасларыбыз бетте. Вертолетлардан сулы савытлар ташларга омтылуларның барысы да уңышсызлыкка очрады. Ташка төшеп бәрелгәч, алар шартлап ярылалар һәм су җиргә агып китә.

24 август көнне иртәнге сәгать 5тә, ниһаять, сугыш урыныннан читтәрәк булган җиргә ике «Ми-8» вертолетларыннан батальонга кирәкле боеприпаслар һәм эчәргә яраклы су ыргыту мөмкин булды. Батальон командиры гвардия майоры Малолетко рота командирларына, йөкне сугышчан позицияләргә илтү өчен, һәр подразделениедән бишәр кеше бирергә дигән бурыч куйды.



назначить старшим группы именно его. Ночью душманы опять заминировали все отходные тропы, и 23 августа 1986 года, выполняя поставленную задачу по доставке боеприпасов, гвардии старший сержант Дауди подорвался на противопехотной мине. Получил тяжелое ранение с отрывом левого бедра и обширным осколочным разрывом мягких тканей правой ноги и тяжелую контузию.

Учитывая, что бой идет в горах, а поэтому единственным средством эвакуации раненых остается вертолет, которому вражеские гранатометчики не давали приземлиться, очевиден был лишь один вариант – транспортировка раненого на удаленные от боевых позиций высоты. Однако здесь уже появлялся риск подорваться на вновь заминированных душманами тропах.

За время, в течение которого Ильяса несли к вертолету, сменилось несколько групп из разных рот. Когда через четыре часа его принесли на площадку, где можно было посадить «вертушку», Дауди без сознания вместе с убитыми и ранеными погрузили в вертолет и отправили вначале в Герат, затем в Шинданд.

На третьи сутки после операции Ильяс пришел в сознание. Начальник госпиталя, провожая его в Кабульский госпиталь 40-й армии, пожелал ему выздоровления. Ему предстояло там перенести еще пять операций на другой ноге. Ильяс с благодарностью вспоминает врачей и медицинских сестер, которые не только спасли ему жизнь, но и сумели своим отношением и заботой подготовить не только его, но и многих других солдат и офицеров к иной непростой и тяжелой жизни в будущем».

А между тем там, куда Дауди уже не мог вернуться, бои продолжались. 25 августа 1985 года укрепрайон Исмаилхана в Кокари-Шоршари все-таки взяли. Его банда была

Рота командиры гвардия өлкән сержанты Даудига боеприпаслар илтергә үз подразделениесеннән биш кешене аерып алырга кушты. Ләкин Ильяс, тау сукмакларын яхшы белүен әйтеп, рота командирын төркем җитәкчесе итеп, үзен билгеләргә күндерде. Төнлә дошманнар бөтен сукмакларга яңадан миналар куеп чыккан булганнар, 1986 елның 23 августында үзенә куелган бурычны үтәгәндә, гвардия өлкән сержанты Дауди пехотага каршы минага эләгеп шартлады. Шартлау аның сул ботын алып ташлаган һәм уң аягының йомшак тукымаларына ярчыклар тулган, ә Ильяс үзе авыр контузия алган.

Сугышның тауларда баруын истә тотканда яралыларны эвакуацияләү өчен бердәнбер чара булып вертолет кала. Ә дошман гранатометчылары аңа җиргә төшеп утырырга ирек бирмиләр. Шулай булгач, бер генә юл бар – яралыны сугыш барган позицияләрдән ерактарак торган биеклеккә илтеп кую. Ләкин монда да дошманнар кабат миналаган сукмакларда шартлау куркынычы зур.

Ильясны вертолет янына алып барган вакытта төрле роталардан берничә төркем алмашынды. Вертолетны утыртырга мөмкин булган мәйданчыкка дүрт сәгатьтән соң гына барып җиттеләр. Шуннан соң аңы булмаган Даудины үтерелгән һәм яраланганнар белән бергә вертолетка төяп, башта Герага, аннары Шиндандка алып киттеләр.

Операциядән соң өч тәүлек үткәч, Ильяс аңына килә. Кырыгынчы армиянең Кабулдагы госпиталенә озатканда, госпиталь начальнигы аның тизрәк терелүен теләп кала. Ул әле икенче аягына тагын биш операция кичерергә тиеш була. Гомерен генә саклап калмыйча, авыр һәм катлаулы киләчәк тормышка үзен һәм башка бик күп солдат-офицерларны әзерли алган табиблар һәм шәфкать туташларын Ильяс зур рәхмәт хисләре белән искә ала иде».



разбита. И только незначительная часть уцелевших душманов, бросив оружие и боеприпасы, вместе с Исмаил-ханом ушла в Иран…

«…Прошли годы, – вспоминает генерал Скородумов, – я окончил Военную академию Генерального штаба. Затем участвовал в чеченских кампаниях. Позднее возглавил Главное управление боевой подготовки Вооруженных Сил РФ. Стал генерал-полковником.

И вот спустя двадцать с лишним лет я узнал, что мой дорогой Ильяс Дауди, тот самый гвардии старший сержант, пройдя долгие месяцы скитаний и мытарств по госпиталям сначала в Афганистане, а потом в Ташкенте и других городах страны, буквально шаг за шагом вновь встал на ноги. Он нашел в себе силы окончить институт, устроиться на работу и наладить свой быт в Москве. Сегодня Ильяс, как выражаются ныне, вполне успешен. У него большая семья – жена и шестеро детей!

Ни тяжелое ранение, ни увечье не сломили его дух. Он все тот же воин – гвардии старший сержант 149-го гвардейского мотострелкового полка. И я безмерно горд тем, что был командиром сотен таких боевых парней, как Ильяс. Время не ломает таких людей, оно над ними не властно. И подобные яркие образцы доблести, мужества и героизма наших солдат всегда живут в моей памяти. И не угаснут, что бы ни произошло в моей будущей жизни».

Ә ул арада Дауди инде кире әйләнеп кайта алмаячак җирләрдә сугышлар дәвам итә. 1985 елның 25 августында Исмәгыйль-шаһның Кокари-Шоршаридагы ныгытылган районын барыбер алдык. Аның бандасы тар-мар ителде. Бары тик исән калган дошманнарның бик аз өлеше генә, коралларын һәм боеприпасларын ташлап, Исмәгыйль-шаһ белән бергә Иранга китте...

«...Еллар үтте, – дип искә ала генерал Скородумов, – мин Генераль штабның Хәрби академиясен тәмамладым. Аннары чечен кампанияләрендә катнаштым. Соңрак РФ Кораллы Көчләренең Хәрби хәзерлек баш идарәсен җитәкләдем.

Егерме елдан артык вакыт үткәч кенә мин кадерле Ильяс Даудиемның – гвардия өлкән сержантының – башта Әфганстанда, аннары Ташкентта һәм илнең башка шәһәрләре госпитальләрендә айлар буе җәфаланганнан соң кечкенә-кечкенә адымнар белән булса да, аягына баскалыгын ишеттем. Ул институт тәмамларга, эшкә урнашырга һәм Мәскәүдә тормышын җайлап җибәрергә көч тапкан. Хәзер Ильяс, шактый гына уңышларга ирешкән. Гаиләсе дә зур – хатыны һәм алты баласы бар!

Авыр яралану да, гариплән дә аның рухын сындыра алмаган. Ул һаман шул ук сугышчы – 149 нчы гвардия мотоукчылар полкының гвардия өлкән сержанты. Һәм мин Ильяс кебек йөзләгән егетләрнең командиры булуым белән



Да, после Афгана 1987 года, пройдя многочисленные госпитали и реабилитацию, Ильяс встал на протез, восстановился в институте и с отличием его окончил. Встретил суженую, женился, а когда у него родился сын, назвал его Даудом, да и фамилию взял Дауди. Работает на руководящих должностях в ряде коммерческих структур.

Сам «афганец», он видел бедственное положение многих ветеранов той войны. Поэтому принимал непосредственное участие в учреждении организаций воинов-афганцев, координировал их деятельность и руководил объединенным экспертным советом по подготовке нормативной базы социально-бытовой и медико-психологической реабилитации ветеранов и инвалидов войны в Афганистане. С 1993 года он первый заместитель председателя Союза ветеранов Афганистана, одновременно два года был заместителем председателя Российского фонда инвалидов Афганистана.

С 1992-го по 2005 год Дауди активно участвовал в реализации трех межгосударственных медико-социальных программ охраны здоровья и реабилитации воинов-интернационалистов и членов их семей. В 1997 году из собственных средств финансировал протезирование восьмидесяти двух инвалидов, проживающих в Москве и Московской области. В те же годы неоднократно оказывал материальную помощь тридцати шести матерям и семьям воинов, погибших в Афганистане.

Награжден двумя советскими орденами Красной Звезды, медалями. Командир полка Александр Скородумов представил Дауди к званию Героя Советского Союза больчиксез горурланам. Андый кешеләрне вакыт сындыра алмый, аның аларга көче җитми. Безнең солдатларның батырлыгы һәм каһарманлыгының якты үрнәкләре минем күңелдә һәрвакыт яши. Алга таба минем тормышымда нинди генә хәлләр булуга карамастан, сүнмәсләр дә».

Әйе, Әфганнан соң бик күп госпитальләрдә тернәкләнү узгач, Ильяс протезга баса, институтта укуын дәвам иттерә һәм аны бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Насыйп ярын очрата, өйләнә, ә улы тугач, аңа Даут исеме бирә, үзе Дауди фамилиясе ала. Бернича коммерциячел структурада җитәкче вазыйфаларында эшли.

Үзе дә «әфганчы» буларак, шул сугышның күп ветераннары фәкыйрь яшәгәнне күрә. Шуңа күрә «әфганчы» сугышчылар оешмаларын гамәлгә куюда турыдан-туры катнаша, аларның эшчәнлеген координацияли. Һәм Әфганстан сугышы ветераннары һәм инвалидларын социаль көнкүреш һәм медицина психология ягыннан тернәкләндерү буенча норматив базаны әзерләүче берләшкән экспертлар советы белән җитәкчелек итә. 1993 елдан ул Әфганстан ветераннары берлеге рәисенең беренче урынбасары, бер үк вакытта Әфганстан инвалидларының Россия фонды рәисе урынбасары булып ике ел эшли.

1992 елдан 2005 елга кадәр Дауди сугышчы интернационалистларны һәм аларның гаилә әгъзаларын тернәкләндерү һәм сәламәтлекләрен саклау буенча өч дәүләтара медицина-социаль программаны тормышка ашыруда актив катнаша. 1997 елны үз акчасына Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә яшәүче 82 инвалидка протез ясата. Шул ук елларда Әфганстанда һәлак булган 36 сугышчының





ше двух десятилетий назад. О том, что он представлен к этой награде, Ильяс узнал в кабульскоми госпитале. Однако это известие никто подтвердить не мог, а потом и вовсе о нем забыли. Прошло 23 года. И вот, встретив Ильяса в Москве, командир узнал, что звание Героя его воину так и не присвоено. Чтобы восстановить справедливость, он обратился раз за разом к администрации трех российских президентов. Наконец подключил к решению этого вопроса Минтимера Шаймиева. В результате 27 декабря 2010 года указом Президента России за личное мужество и героизм, проявленные при выполнении воинского долга, Ильясу Дауди было присвоено звание Героя России.

Азнакаевская земля по праву гордится своими отважными сынами, самоотверженными тружениками. За проявленные в боях мужество и героизм в годы Великой Отечественной войны четверо азнакаевцев удостоены звания Героя Советского Союза. За выдающиеся успехи в мирное время восемь человек носят звание Героя Социалистического Труда. В эту плеяду выдающихся сынов района по праву вписано еще одно имя – Ильяса Дильшатовича Дауди. Решением Азнакаевского городского Совета благодарные земляки на аллее Героев в центре города возвели памятник еще одному знаменитому азнакаевцу.

аналарына һәм гаиләләренә даими рәвештә матди ярдәм күрсәтеп тора.

Ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр белән бүләкләнә. Полк командиры Александр Скородумов егерме ел элек Даудины Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим иткән була. Бу бүләккә тәкъдим ителгәнлеген Ильяс Кабул госпиталендә ишетә. Ләкин бу хәбәрне расларга кеше булмый, аннан соң бу хакта бөтенләй оныталар. 23 ел үтә. Ильясны Мәскәүдә очраткач кына командиры аңа Герой исеменең һаман да бирелмәгәнлеген белеп ала. Гаделлекне торгызу өчен, ул кат-кат Россиянең өч Президенты администрацияләренә мөрәҗәгать итә. Ахыр чиктә бу мәсьәләне хәл итүгә Минтимер Шәймиевне җәлеп итә. Нәтиҗәдә Россия Президенты Указы белән хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән шәхси батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен 2010 елның 27 декабрендә Ильяс Даудига Россия Герое исеме бирелә.

Азнакай җире үзенең курку белмәс уллары, фидакарь хезмәтчәннәре белән хаклы рәвештә горурлана. Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән батырлыклары һәм каһарманлыклары өчен дүрт азнакайлы Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган. Тыныч вакыттагы гаять зур уңышлары өчен сигез кеше Социалистик Хезмәт Герое исемен йөртә. Районның бөек улларының шушы плеядасына тагын бер кешенең – Ильяс Дилшат улы Даудиның исеме дә язылган. Азнакай шәһәр советы карары белән якташлары шәһәр үзәгендәге Батырлар аллеясына тагын бер танылган азнакайлыга һәйкәл куйдылар.







# ЕПАНЕШНИКОВ Александр Николаевич

Родился 5 августа 1954 года в Елабуге. Окончил местную среднюю школу № 3 в 1971 году. В Вооруженных Силах с 1971 года. Окончил Балашовское высшее военное авиационное училище в 1975 году. Служил помощником командира воздушного корабля в 708-м авиационном полку Военно-транспортной авиации в Азербайджане и Польше. С 1979 года – командир экипажа корабля Ан-12 в 245-й смешанной авиационной эскадрилье 4-й Воздушной армии на Северном Кавказе.

С 1989 года командовал поисково-спасательным отрядом 250-й авиационной базы специальной группы Военно-воздушных сил в Арктике.

При выполнении полетного задания по перебазированию авиационной техники по маршруту Энгельс – Астрахань 23 августа 1993 года на самолете Ан-12 произошел отказ трех двигателей. Командир экипажа Александр Епанешников повел самолет на запасной аэродром на последнем двигателе. Однако при подходе к Волгограду отказал и последний, четвертый двигатель. Экипаж сумел отвернуть падающий самолет от жилого района, направив его на лесной массив. При падении самолет взорвался, весь экипаж погиб.

За мужество и героизм, проявленные при выполнении воинского долга, указом Президента РФ от 21 июня 1994 года майору Епанешникову Александру Николаевичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).

27 декабря в Казанском Кремле Президент Татарстана Шаймиев М.Ш. вручил семье летчика-майора Александра Епанешникова высшую награду России – Золотую Звезду

1954 елның 5 августында Алабугада туа. 3 нче номерлы урта мәктәпне 1971 елда тәмамлый.

Кораллы Көчләрдә – 1971 елдан бирле. 1975 елда Балашово югары хәрби авиация училищесын тәмамлый. Әзәрбайҗанда һәм Польшада Хәрби-транспорт авиациясенең 708 нче хәрби транспорт авиация полкында һава корабы командиры ярдәмчесе булып хезмәт итә. 1979 елдан – Төньяк Кавказдагы 4 нче Һава армиясенең 245 нче катнаш авиация эскадрильясында «Ан-12» корабле экипажы командиры.

1989 елдан Арктикадагы Хәрби-һава көчләренең махсус төркеме 250 нче авиация базасының эзләү-коткару отрядына җитәкчелек итә.

Авиация техникасын Энгельс–Әстерхан маршруты буенча күчерү заданиесен үтәгәндә, 1993 елның 23 августында, «Ан-12» самолетында өч мотор эшләүдән туктый. Экипаж командиры Александр Епанешников бер генә моторы эшләгән самолетны запас аэродромга таба юнәлтә. Ләкин Волгоградка килеп җитәрәк, соңгы дүртенче мотор да эшләми башлый. Экипаж егылып төшеп баручы самолетны кешеләр яши торган районнан читкәрәк – урман өстенә таба бора ала. Төшкәндә самолет шартлый, бөтен экипаж һәлак була.

Хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен РФ Президенты Указы белән 1994 елның 21 июнендә майор Александр Николаевич Епанешниковка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә (үлгәннән соң).

27 декабрьдә Казан Кремлендә Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев очучы-майор Александр Епанешниковның



Героя России. При этом он подчеркнул, что майор Епанешников – первый Герой России в нашей республике, и надо об этом подвиге хранить память, передавать ее от поколения поколению.

На церемонии вручения семье награды присутствовал первый заместитель командующего войсками Приволжского военного округа генерал-лейтенант Владимир Попов. Он рассказал о подвиге экипажа во время перелета в небе над Волгоградом.

«23 августа 1993 года, – напомнил генерал,– ценой собственной жизни отвели беду от мирных жителей шесть отважных летчиков – членов экипажа самолета Ан-12, командиром которого был ваш земляк из Елабуги.

После отказа трех двигателей, когда до запасного аэродрома оставалось двадцать километров, у самолета отказал и последний, четвертый. Высота стремительно падала, и в последний момент, действуя решительно и хладнокровно, командир отвернул самолет от кварталов города. За этот подвиг командиру корабля присвоено звание Героя России, орденами «За личное мужество» награждены посмертно члены экипажа В.П. Аникин, А.Ф. Важенин, Ю.К. Коновалов, В.А. Шалоник, М.Ю. Щилев. Похоронен Герой на родине, в Елабуге».

На плечах матери героя Анны Алексеевны и вдовы Нелли Николаевны лежит нелегкое бремя по воспитанию троих детей. Администрация города помогает им. Подтверждением тому – ордер на новую трехкомнатную квартиру, который здесь же, в Кремле, вручил глава администрации Елабужского района и города Елабуги.

В память о герое в Елабуге одна из улиц названа его именем. Школа № 3, где учился Александр, также теперь носит его имя.

гаиләсенә Россиянең иң югары бүләген – Россия Герое «Алтын Йолдыз»ын тапшыра. Шул чакта ул майор Епанешниковның безнең республикадагы иң беренче Россия Герое булуын, бу батырлык турындагы истәлекне саклауга, аны буыннан-буынга тапшырырга кирәклеген әйтте.

Бүләкне аның гаиләсенә тапшыру тантанасында Идел буе хәрби округы гаскәрләре командующиеның беренче урынбасары генерал-лейтенант Владимир Попов катнашты. Ул экипажның Волгоград күге өстеннән очкан чактагы батырлыгы турында сөйләде.

«1993 елның 23 августында, – дип искәртте генерал, – командиры сезнең якташыгыз – Алабуга егете булган «АН-12» самолеты экипажының курку белмәс алты очучысы, үз гомерләре бәрабәренә, тыныч халык өстеннән бәлане читкә җибәрделәр.

Өч мотор сафтан чыккач, запас аэродромга кадәр 20 чакрым калганда, самолетның соңгы дүртенче моторы да эшләми башлый. Биеклек бик тиз югала. Соңгы мизгелдә салкын акыл белән уйлап, командир самолетны шәһәр кварталларыннан читкә бора. Бу батырлыгы өчен кораб командирына Россия Герое исеме бирелә, «Шәхси батырлык өчен» орденнары белән, үлгәннән соң, экипаж әгъзалары В.П.Аникин, А.Ф.Важенин, Ю.К.Коновалов, В.А.Шалоник, М.Ю.Щилев бүләкләнә. Герой үзенең туган ягында Алабугада күмелгән».

Өч баланы тәрбияләү мәшәкате Геройның әнисе Анна Алексеевна һәм тол хатыны Нелли Николаевна җилкәсенә төшә. Шәһәр администрациясе аларга булыша. Моның дәлиле – өр-яңа өч бүлмәле фатирга ордер. Анысын да шушында Кремльдә үк Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре администрациясе башлыгы тапшыра.

Герой истәлегенә Алабугада бер урам аның исеме белән атала. Александр укыган 3 нче мәктәп хәзер аның исемен йөртә.







# ЕРИН Виктор Федорович

Родился 17 января 1944 года в Казани. Генерал армии (1993 г.), Герой Российской Федерации (8.10. 1993 г.). Окончил Елабужскую специальную среднюю школу милиции (1967 г.), Высшую школу МВД СССР (Москва, 1973 г.). В 1964-83 гг. в органах внутренних дел ТАССР. В системе уголовного розыска прошел путь от оперативного уполномоченного до начальника Управления уголовного розыска МВД ТАССР. В 1980-81 гг. участвовал в боевых действиях советских войск в Афганистане. В 1983-88 гг. начальник отдела Главного управления по борьбе с хищениями МВД СССР (Москва). В 1988-90 гг. первый заместитель министра внутренних дел Армянской ССР. С 1990 г. первый заместитель министра внутренних дел РСФСР. С декабря 1991 г. первый заместитель министра безопасности и внутренних дел РСФСР. В 1992-95 гг. министр внутренних дел Российской Федерации, одновременно с 1993 г. член Совета Безопасности России. С 1995 г. заместитель директора Службы внешней разведки РФ. Награжден также орденом Красной Звезды, медалями.

1944 елның 17 гыйнварында Казанда туа. Армия генералы (1993 ел), Россия Федерациясе Герое (08.10.1993 ел). Алабуга махсус урта милиция мәктәбен (1967 ел), СССР ЭЭМ Югары мәктәбен (Мәскәү, 1973 ел) тәмамлый. 1964–1983 елларда ТАССР эчке эшләр органнарында эшли. Җинаятьчеләрне эзләү системасында оператив хезмәткәрдән башлап ТАССР ЭЭМ Җинаятьчеләрне эзләү идарәсе начальнигына кадәр юл үтә. 1980–1981 елларда совет гаскәрләренең Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрендә катнаша. 1983–88 елларда СССР ЭЭМ Урлаулар белән көрәш баш идарәсендә (Мәскәү) бүлек начальнигы була. 1988–1990 елларда – Әрмән ССР Эчке эшләр министрлыгының беренче урынбасары. 1990 елдан башлап РСФСР эчке эшләр министрының беренче урынбасары. 1991 елның декабреннән – РСФСР куркынычсызлык һәм эчке эшләр министрының беренче урынбасары. 1992–1995 елларда Россия Федерациясе эчке эшләр министры, бер үк вакытта 1993 елдан бирле Россия Куркынычсызлык Советы әгъзасы. 1995 елдан РФ Тышкы разведка хезмәте директоры урынбасары. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр белән бүләкләнгән.

(Татар энциклопедиясе. 2 т., 359 б.)





# ЗАКИРОВ Игорь Рауфович

Родился 2 января 1945 года в Уфе в семье служащих. В детстве ему часто приходилось наблюдать за полетами самолетов Уфимского аэроклуба. Именно тогда зародилась у мальчишки мечта самому подняться в небо. Детская и юношеская мечта привела юношу после окончания средней школы в Оренбургское высшее военное авиационное училище летчиков имени С.П. Полбина.

После успешного окончания училища в октябре 1967 года лейтенант Игорь Закиров получил распределение в военно-морскую авиацию. До октября 1971 года служил летчиком 240-го гвардейского Севастопольско-Берлинского ракетного авиационного полка военно-воздушных сил Балтийского флота. В этом полку Игорь на деле проверил свои знания, полученные в училище. Оценкой становления молодого летчика стало предложение ему со стороны командования о поступлении в Школу летчиков-испытателей в подмосковном Жуковском. После успешной сдачи экзаменов Игорь стал ее слушателем.

Школа испытателей – особое учебное заведение. Здесь уже состоявшихся профессионально летчиков учат нестандартным методикам, умению выходить из нештатных ситуаций, «выжимать» из машины все возможное, на что она способна. Испытатели – это первопроходцы. Именно они в полетах подтверждают задумки конструктора, доводят машину до совершенства.

После завершения учебы Закиров получил распределение в ОКБ имени Ильюшина.Здесь нелегкой и ответственной работе, часто связанной с риском для жизни, Игорь Рауфович отдал более тридцати лет. За эти годы он освоил 25 видов военно-транспортных самолетов. Неоднократно участвовал в десантировании грузов. Теперь способ десантирования грузов и военной техники находится на повседневном вооружении военно-транспортной авиации и воздушно-десантных войск. Кроме того, МЧС использует десантирование грузов при оказании помощи населению, пострадавшему от стихийных бедствий.

В период 1970-1980-х годов велась интенсивная работа по расширению боевых возможностей самолета Ил-76. Это уникальная машина. Самолет способен перебрасывать десант на расстояние до нескольких тысяч километров. Сегодня с него прыгает пехота на всех учениях. И работа над совершенствованием лайнера не прекращается. Благодаря конструкторской мысли возросли возможности самолета по максимальной взлетной массе. Появились новые модификации Ил-76Т, Ил-76М, Ил-76ТД, Ил-76МД, самолеты-заправщики Ил-78 и Ил-78М, самолеты-лаборатории для подготовки космонавтов Ил-76К и Ил-76МДК, самолет Ил-76ТДП для тушения пожаров, поисково-спасательный самолет Ил-76 МДПС, самолет-лаборатория Ил-76МД.

В новогоднюю ночь 1986 года Игорь Рауфович впервые в истории авиации совершил на Ил-76 беспосадочный перелет из Москвы в Москву через Северный полюс. 28 сентября 1989 года он поднял в небо и провел испытания самолета Ил-76П-1. В том же году участвовал в десантировании грузов с Ил-76МД в районе Северного полюса.

1945 елның 2 гыйнварында Уфада хезмәткәр гаиләсендә туа. Бала чагында аңа Уфа аэроклубы самолетлары очышын еш күзәтергә туры килә. Нәкъ менә шул вакытта малайда күккә күтәрелү хыялы ярала. Балалык һәм үсмерлек хыялы, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, егетне С.П.Полбин исемендәге Оренбург югары хәрби авиация училищесына алып килә.

Училищены уңышлы тәмамлагач, 1962 елның октябрендә лейтенант Игорь Закиров хәрби-диңгез авиациясенә юллама ала. 1971 елның октябренә кадәр Балтика флоты Хәрби-һава көчләренең 240 нчы гвардия Севастополь-Берлин ракета авиация полкында очучы булып хезмәт итә. Бу полкта Игорь училищеда алган белемнәрен эштә сынап карый. Командованиенең аңа Мәскәү астындагы Жуковск шәһәренә Очучы-сынаучылар мәктәбенә укырга керергә тәкъдим итүе яшь очучының хезмәтенә бәя булып тора. Имтиханнарын уңышлы тапшырып, егет шунда укый башлый.

Сынаучылар мәктәбе – үзенчәлекле уку йорты. Инде профессиональ очучы булып җитешкән кешеләрне монда стандарт булмаган методикаларга, катлаулы хәлләрдән чыгарга, машинаның бөтен мөмкинлекләрен «сыгарга» өйрәтәләр. Сынаучылар – юл ярып баручылар алар. Нәкъ менә алар конструктор уйлаганнарны очышлар вакытында раслыйлар, машинаны камиллеккә җиткерәләр.

Укуын тәмамлагач, Закиров Ильюшин исемендәге ОКБга юллама ала. Мондагы авыр һәм җаваплы, еш кына тормышына куркыныч янаган эшенә Игорь Рәүф улы утыз елдан артык гомерен бирә. Бу елларда ул 25 төрдәге хәрби транспорт самолетын үзләштерә. Күп тапкырлар йөкләр десантлауда катнаша. Хәзер йөкләрне һәм хәрби техниканы десантлау ысулы хәрби транспорт авиациясендә һәм һава-десант гаскәрләрендә көн саен кулланыла. Моннан тыш МЧС йөкләрне десантлауны табигать бәла-казаларыннан зыян күргән халыкка ярдәм күрсәткәндә файдалана.

1970–1980 елларда «Ил-76» самолетының хәрби мөмкинлекләрен киңәйтү буенча интенсив эш алып барылды. Бу – уникаль машина. Самолет берничә мең чакрымга кадәр арага десант ташларга сәләтле. Бүген барлык өйрәнүләр вакытында пехота шуннан сикерә. Лайнерны камилләштерү эше дә туктамый. Конструкторлар фикерләве аркасында самолетның иң зур очып китү массасы буенча мөмкинлекләре үсте. «Ил-76Т», «Ил-76М», «Ил-76ТД», «Ил-76МД» яңа модификацияләр, «Ил-78» һәм «Ил-78М» заправка самолетлары, космонавтлар әзерләү өчен «Ил-76К» һәм «Ил-76МДК» самолет-лабораторияләр, янгын сүндерү өчен «Ил-76ТДП» самолеты, «Ил-76МДПС» эзләү-коткару самолеты, «Ил-76МД» самолет-лабораториясе барлыкка килде.

1986 елның яңа ел төнендә авиация тарихында беренче тапкыр Игорь Рәүф улы «Ил-76»да Төньяк полюс аша Мәскәүдән Мәскәүгә тукталышсыз очыш ясады. 1989 елның 28 сентябрендә ул «Ил-76П-1» самолетын күккә күтәрде һәм сынады. Шул ук елны Төньяк полюс тирәсендә «Ил-76МД»дан йөкләр десантлауда катнашты.



Указом Президента СССР от 16 августа 1990 года ему было присвоено звание «Заслуженный летчик-испытатель СССР».

24 декабря 1991 года Закиров провел испытание самолета Ил-114/2. В апреле 1992-го Игорь Рауфович на Ил-76П участвовал в тушении пожара на складе боеприпасов в районе армянского города Балаовит. Благодаря умелым действиям летчика пожар был ликвидирован, предотвращены многочисленные человеческие жертвы и разрушения. Отважному летчику, одному из первых в постсоветской России, был вручен орден «За личное мужество». Сегодня пожарный вариант Ил-76 широко используется авиацией МЧС при тушении крупных очагов лесных пожаров по всей стране.

– Да, есть что вспомнить о том благодатном, с точки зрения творчества и возможности работать, периоде, когда все мы трудились во имя одной цели – усиления могущества нашей Родины, – говорит Игорь Рауфович. – И, поверьте, это не громкие слова. Очень верно написал главнокомандующий ВВС в 1991-1998 годы генерал армии П.С. Дейнекин: «Восьмидесятые годы останутся самым могущественным периодом в истории Военно-воздушных сил страны. Нас тогда во всем мире уважали, а в НАТО – боялись как огня». И очень удачно дополняют эту мысль слова командующего 16-й воздушной армии в 1988-1993 годы генерал-полковника А.Ф. Тарасенко: «Мы никому не угрожали, но и никого не боялись!»

Указом Президента РФ от 14 марта 1994 года за мужество и героизм, проявленные при испытании, доводке и освоении новых образцов авиационной техники, летчику-испытателю Авиационного комплекса имени С.В. Ильюшина Закирову Игорю Рауфовичу присвоено звание Героя России с вручением медали «Золотая Звезда».

Испытатель – профессия особенная. Их немного, их знают всех наперечет. Среди испытателей много замечательных специалистов своего дела. Все они подвергаются риску, испытывая новые машины, почти все попадали в ситуации, когда только мастерство летчика, помноженное на мужество и хладнокровие, спасало и летчика, и машину.

И после получения высокого звания Игорь Рауфович продолжал испытывать технику. 14 сентября 1996 года им был поднят и испытан самолет Ил-114Т. С 15 декабря 1999 года по 31 января 2000-го под руководством полярного исследователя Владимира Чукова состоялась международная антарктическая экспедиция «Навстречу XXI веку», в которой приняли участие 70 исследователей из 18 стран мира. На Антарктический материк впервые был посажен транспортный самолет Ил-76Т. Пилотировали его пилот 1-го класса, военный летчик Рафаил Гирфанов и пилот-инструктор Герой России Игорь Закиров.

Помимо испытательных полетов И.Р. Закиров участвовал в демонстрации аэробусов Ил-76, Ил-86, Ил-114 на международных выставках авиационной техники в Берлине, Париже, Праге, Дели, Пекине, Сингапуре, Сантьяго и в других городах.

СССР Президентының 1990 елның 16 августындагы Указы нигезендә аңа «СССРның атказанган очучы-сынаучысы» исеме бирелде.

1991 елның 24 декабрендә Закиров «Ил-114/2» самолетын сыный. 1992 елның апрелендә Игорь Рәуф улы «Ил-76П» самолетында әрмән шәһәре Балаовит тирәсендәге боеприпаслар складындагы янгынны сүндерүдә катнаша. Очучының белеп ясаган хәрәкәтләре аркасында янгын сүндерелә, күп санлы корбаннар һәм җимерелүләр булмый кала. Курку белмәс очучыга, советтан соңгы Россиядә беренчеләрдән булып, «Шәхси батырлык өчен» орденны тапшырыла. Бүген «Ил-76»ның янгын варианты бөтен ил буйлап бик зур урман янгыннарын сүндергәндә МЧС авиациясе тарафыннан кулланыла.

– Әйе, без бары тик бер максат хакына – Ватаныбызның куәтен арттыру өчен хезмәт иткән чордагы күп нәрсәне искә алып сөйләргә була, – ди Игорь Рәуф улы. – Ышаныгыз: бу буш сүзләр генә түгел. 1991-1998 елларда Хәрби-һава көчләре баш командующие булган генерал П.С.Дейнекин бик дөрес язган: «Илнең Хәрби һава көчләре тарихында сиксәненче еллар иң куәтле чор булып калачак. Ул чакта безне бөтен дөнья хөрмәт итә, ә НАТО уттан курыккандай курка иде». Бу фикерне 1988-1993 елларда 16 нчы һава армиясе командующие булып торган генерал-полковник А.Ф.Тарасенко сүзләре дә уңышлы тулыландыра: «Без беркемгә дә янамадык, ләкин беркемнән курыкмадык та!»

Авиация техникасын сынаганда, камилләштергәндә һәм яңа үрнәкләрен үзләштергәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1994 елның 14 мартындагы Указы нигезенда С.В.Ильюшин исемендәге Авиация комплексы очучы-сынаучысы Закиров Игорь Рәуф улына Россия Герое исеме бирелә һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Сынаучы – үзенчәлекле һөнәр. Алар күп түгел, аларның барысын да исемләп беләләр. Сынаучылар арасында үз эшләрен бик шәп белүчеләр күп. Алар барысы да, яңа машиналар сынаганда, үзләрен куркыныч астына куялар, барысы да диярлек очучыны да, машинаны да очучының батырлык һәм салкын канлылыкка тапкырланган осталыгы гына коткарып калган хәлләргә эләккәне бар.

Югары исемне алганнан соң да Игорь Рәуф улы техниканы сынавын дәвам иттерә. 1996 елның 14 сентябрендә ул «Ил-114Т» самолетын һавага күтәрә һәм сыный. 1999 елның 15 декабреннән 2000 елның 31 гыйнварына кадәр поляр тикшеренүче Владимир Чуков җитәкчелегендә Антарктидага «XXI гасырга каршы» дигән халыкара экспедиция була. Анда дөньяның 18 иленнән 70 тикшеренүче катнаша. Антарктида материгына «Ил-76Т» транспорт самолеты беренче тапкыр төшеп утыра. Аның белән 1 классны пилот, хәрби очучы Рафаил Гыйрфанов һәм пилот-инструктор Россия Герое Игорь Закиров идарә итә.

Сынау очышларыннан тыш И.Р. Закиров Берлинда, Парижда, Прагада, Делида, Пекинда, Сингапурда, Сантьягода һәм башка илләрдә узган халыкара авиация техникасы күргәзмәләрендә «Ил-76», «Ил-86», «Ил-114» аэробусларын күрсәтүдә катнаша.







# ЗАКИРОВ Ильфат Индулисович

Родился 9 февраля 1970 года в Ижевске. Окончил среднюю школу. До призыва на военную службу преподавал самбо в детско-юношеской спортивной школе. В июне 1988 года был призван в ряды Советской Армии, службу проходил в Туркестанском военном округе. После увольнения в запас в 1990 году, будучи кандидатом в мастера спорта по дзюдо, работал тренером-преподавателем в ДЮСШ № 4 Ижевска, инструктором отряда вневедомственной охраны производственного объединения «Ижсталь».

С 1991 года Ильфат – в органах Министерства внутренних дел РФ по Удмуртской Республике, боец отряда спецназа Управления исполнения наказаний. Вскоре он был назначен командиром отделения. В 1995 году был направлен командиром взвода спецназа в свою первую командировку на Северный Кавказ.

С 1998 года Закиров исполняет должность начальника штурмового отделения. Среди товарищей по оружию отличался смелостью и решительностью действий в экстремальных ситуациях. Неоднократно участвовал в спецмероприятиях в исправительных колониях, розыске и задержании вооруженных преступников. Самоотверженность, целеустремленность, добросовестность и исполнительность – эти качества сыграли решающую роль при назначении его командиром штурмового отделения отряда специального назначения «Кречет».

В сентябре 1999 года последовала вторая командировка в «горячую точку». На этот раз в Республику Дагестан. С 27 января по 13 марта 2000 года Ильфат участвовал

1970 елның 9 февралендә Ижевскида туа. Урта мәктәп тәмамлый. Хәрби хезмәткә чакырылганчы балаларүсмерләр спорт мәктәбендә самбо укыта. 1988 елның июнендә Совет Армиясе сафларына чакырыла, Төркестан хәрби округында хезмәт итә. Запаска чыкканнан соң 1990 елны, дзюдо буенча спорт мастерлыгына кандидат булarak, Ижевскиның 4 нче БҮСМндә тренер-укытучы булып, «Ижсталь» җитештерү берләшмәсендә ведомстводан тыш сак отряды инструкторы булып эшли.

1991 елдан Илфат – РФ Эчке эшләр министрлыгының Удмуртия Республикасындагы органнарында, Җәзаларны үтәү идарәсенең спецназ отряды сугышчысы. Озакламый ул отделение командиры итеп билгеләнә. 1995 елда взвод командиры итеп Төньяк Кавказга беренче командировкага җибәрелә.

1998 елдан башлап Закиров штурмлау отделениесе начальнигы вазыйфасын башкара. Коралдаш иптәшләре арасында кыюлыгы һәм экстремаль хәлләрдә тиз карар кабул итә алуы белән аерылып тора. Күп тапкырлар төзәтү колонияләрендә махсус чараларда, кораллы җинаятьчеләрне эзләү һәм тоткарлауда катнаша. Махсус билгеләнештәге «Кречет» отрядының штурмлау отделениесе командиры итеп билгеләнгәндә, аның фидакарьлеге, максатка омтылучанлыгы, намуслылыгы һәм тыңлаучанлыгы хәлиткеч роль уйный.

1999 елның сентябрендә «кайнар нокта»га икенче командировкасы була. Бу юлы Дагстан Республикасына. 2000 елның 27 гыйнварыннан 13 мартына кадәр Илфат



в решении задач по борьбе с незаконными вооруженными бандформированиями, охране общественного порядка и восстановлению конституционного строя в Чеченской Республике, в том числе по уничтожению крупной группировки боевиков в селе Комсомольское Урус-Мартановского района.

Подробности последней операции таковы. 13 марта 2000 года штурмовая группа отряда специального назначения под командованием старшего лейтенанта внутренней службы Закирова получила задачу выбить боевиков из хорошо укрепленного пункта в селе Комсомольское, чтобы обеспечить продвижение основных сил группировки. Начался штурм, и группа сразу попала под ураганный огонь боевиков. Сознавая реальную опасность, рискуя собственной жизнью, Ильфат поднял своих бойцов в атаку и первым ворвался внутрь опорного пункта противника. Штурмовой группе удалось захватить часть пункта, однако плотный огонь боевиков остановил ее продвижение. Умело маневрируя и ведя прицельную стрельбу, Закиров вызвал огонь на себя, давая своим бойцам возможность рассредоточиться и укрыться. Увидев, что один из его товарищей, Валерий Бахарев, ранен, Ильфат бросился к нему на помощь и под огнем противника попытался вынести его из-под обстрела. Осколки разорвавшегося снаряда ранили его в ноги и в голову, но Закиров продолжал командовать своим отрядом. Однако взрыв новой брошенной боевиками гранаты оказался для бесстрашного бойца смертельным. Ценой жизни Ильфат спас жизни своих товарищей.

За мужество и героизм, проявленные в ходе контртеррористической операции в Северо-Кавказском регионе, указом Президента РФ от 1 марта 2001 года старшему лейтенанту внутренней службы Закирову Ильфату Индулисовичу присвоено звание Героя России (посмертно).

В Ижевске его именем названа улица, на ней установлена мемориальная доска. Имя Ильфата Закирова присвоено средней школе № 55, в которой он учился. С 2004 года в Ижевске проводится турнир по дзюдо на приз Героя России Ильфата Закирова.

Чечня Республикасында законсыз кораллы бандформированиеләр белән көрәштә, иҗтимагый тәртипне саклауда һәм Конституция строен тергезүдә бурычлар үтәүдә, шул исәптән Урус-Мартан районы Комсомольское авылында боевикларның зур төркемен юк итүдә катнаша.

Соңгы операция турында тәфсилләбрәк сөйлик. 2000 елның 13 мартында эчке эшләр өлкән лейтенанты Закиров җитәкчелегендәге спецназ отрядының штурмлау төркеме боевикларны Комсомольское авылындагы яхшы итеп ныгытылган пунктларыннан бәреп чыгарып, төркемнең төп көчләренә юл ачу бурычы куела. Штурм башланугa ук төркем боевикларның ут давылы астына эләгә. Куркыныч чынбарлыкны аңлаган хәлдә үз гомерен куркыныч астына куеп, Илфат үз сугышчыларын атакага күтәрә һәм дошманның терәк пунктына беренче булып бәреп керә. Штурмлау төркеменә пунктның бер өлешен алу мөмкин була, ләкин боевикларның туктаусыз уты төркемнең хәрәкәтен туктата. Хәйләле маневрлар ясый-ясый һәм атыша-атыша, Закиров утны үзенә таба ала, шулай итеп сугышчыларына таралып урнашырга һәм яшеренергә мөмкинлек бирә. Иптәшләренең берсе Валерий Бахаревның яраланганын күреп, Илфат аңа ярдәмгә ташлана. һәм дошман бертуктаусыз яудырган ут астында аны читкә алып чыгарга тырыша. Якында шартлаган снаряд ярчыклары аның аякларын һәм башын яралый, ләкин Закиров отряды белән командалык итүеннән туктамый. Әмма боевиклар ыргыткан яңа граната шартлавы куркусыз сугышчыга үлем алып килә. Үз тормышы бәрабәренә Илфат иптәшләренең гомерләрен саклап кала.

Төньяк Кавказ төбәгендә террорчылыкка каршы операция барышында күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2001 елның 1 мартындагы Указы нигезендә эчке хезмәтләр өлкән лейтенанты Закиров Илфат Индулис улына Россия Герое исеме бирелә (үлгәннән соң).

Ижевскида бер урам аның исеме белән атала, анда мемориаль такта куелган. Илфат Закиров исеме ул укыган 55 нче мәктәпкә дә бирелгән. 2004 елдан башлап Ижевскида Россия Герое Илфат Закиров призына дзюдо турниры уздырыла.







# ЗАРИПОВ Альберт Маратович

Родился 8 ноября 1968 года в поселке Бустон Бухарской области Узбекистана в семье военнослужащего. Окончил среднюю школу с золотой медалью. В 1985-1987 годах учился в Рязанском радиотехническом институте.

В 1987 году был призван на срочную службу в воздушно-десантные войска Советской Армии. По окончании учебного подразделения был направлен в одну из воинских частей 40-й армии Туркестанского военного округа.

Боевую службу проходил в шестом батальоне спецназа на должности старшего разведчика-пулеметчика, а потом заместителем командира группы спецназа. Участвовал во многих боевых операциях на территории Афганистана.

Возвратившись с действительной военной службы, Альберт поступил в Рязанское высшее воздушно-десантное командное училище. Окончив его в 1993 году, продолжил службу в Северо-Кавказском военном округе, в той же воинской части, в которой служил в Афганистане.

В качестве офицера спецназа ГРУ в 22-й отдельной бригаде специального назначения Альберт Зарипов участвовал в защите и охране мирного населения Республики Северная Осетия в августе-октябре 1993 года, в спецоперации по освобождению ростовских школьников, взятых чеченскими боевиками в заложники в декабре 1993 года, в спецоперации в Буденновске в июне 1995 года, а также в первой чеченской военной кампании с января 1995 года. Вместе со своим подразделением восемнадцать раз выходил в тыл незаконных вооруженных формирований, в сложной обстановке неоднократно проявлял решитель-

1968 елның 8 ноябрендә Үзбәкстанның Бухара өлкәсе Бустон бистәсендә хәрби хезмәткәр гаиләсендә туа. Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. 1985–1987 елларда Рязань радиотехника институтында укый.

1987 елны Совет Армиясенең хәрби-десант гаскәрләренә хезмәткә алына. Уку подразделениесен тәмамлагач, Төркестан хәрби округы 40 нчы армиясенең бер хәрби частена җибәрелә.

Хәрби хезмәтне спецназның алтынчы батальонында өлкән разведчик-пулеметчы, ә аннары спецназ төркеме командиры урынбасары вазыйфасында уза. Әфганстан территориясендә күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша.

Хәрби хезмәттән әйләнеп кайткач, Альберт Рязань югары һава-десант команда училищесына укырга керә. Аны 1993 елда тәмамлагач, Төньяк Кавказ хәрби округында Әфганстанда хезмәт иткән шул ук хәрби частьта хезмәтен дәвам иттерә.

22 нче махсус спецназ бригадасында ГРУ спецназ офицеры сыйфатында Альберт Зарипов 1993 елның август-октябрендә Төньяк Осетия Республикасының тыныч халкын яклау һәм саклауда, 1993 елның декабрендә чечен боевиклары тотык итеп алган Ростов укучыларын коткару буенча махсус операциядә, 1995 елның июнендә Буденновскидагы махсус операциядә, шулай ук 1995 елның гыйнварыннан беренче чечен хәрби кампаниясендә катнаша. Үз подразделениесе белән бергә законсыз кораллы формированиеләр тылына 18 тапкыр чыга, катлаулы хәлләрдә



ность, отвагу, личное мужество в сочетании с тонким расчетом и хладнокровием.

В январе 1996 года Зарипов участвовал в спецоперации по уничтожению чеченского боевика Салмана Радуева. В те дни банда Радуева захватила дагестанское село Первомайское. Альберт только что вернулся из отпуска в свою воинскую часть, расквартированную в Ханкале в Чеченской Республике. Его подчиненные в это время готовились к выполнению боевой задачи в районе чеченского села Шатой. Зарипов вызвался идти вместе с группой. Но вместо Шатоя спецназовцы оказались под дагестанским Первомайском, захваченным боевиками. Помимо «гражданских» заложников, радуевцы взяли в плен отряд новосибирского ОМОНа. Вместе с личным оружием милиционеров им достались бронетранспортер и станковый автоматический гранатомет.

Разведгруппа старшего лейтенанта Зарипова совместно с другими армейскими подразделениями, участвовавшими в операции, блокировала Первомайское с севера и запада. С востока и юга село осадили спецподразделения МВД и ФСБ.

В ночь с 17 на 18 января старший лейтенант Альберт Зарипов и его боевые товарищи из 22-й отдельной бригады специального назначения ГРУ Генштаба стали стеной на пути прорывавшейся в Чечню банды Радуева. Около четырех часов утра боевики численностью 350 человек

күп тапкыр бөтен нечкәлекләренә кадәр уйланган исәп-хисап һәм салкын канлылык белән кушылган батырлыклар күрсәтә.

1996 елның гыйнварында Зарипов чечен боевигы Сәлмән Радуевны юк итү буенча махсус операциядә катнаша. Ул көннәрдә Радуев бандасы Дагстан авылы Первомайскоены яулап алган була. Альберт яңа гына отпускыдан Чечня Республикасы Ханкала шәһәрендә урнашкан хәрби частена әйләнеп кайткан. Аның кул астындагылар ул вакытта чечен авылы Шатой тирәсендә хәрби бурыч үтәргә әзерләнәләр. Зарипов төркем белән бергә барырга була. Ләкин Шатой урынына спецназчылар боевиклар кулындагы Первомайскоега килеп чыга. «Гражданский» тотыклардан тыш, радуевчылар Новосибирск ОМОНы отрядын да әсирлеккә алалар. Милиционерларның шәхси коралы белән бергә бронетранспортер һәм станоклы автомат гранатомет та алар кулына төшә.

Өлкән лейтенант Зариповның разведка төркеме операциядә катнашучы башка подразделениеләр белән бергә Первомайскоены төньяктан һәм көнбатыштан ябып куя. Авылның көнчыгышында һәм көньягында ЭЭМ һәм ФКХ (ФСБ) махсус подразделениеләре тора.

17 сеннән 18 нче гыйнварга каршы төндә өлкән лейтенант Альберт Зарипов һәм аның Генштабның ГРУ спецназ 22 нче махсус бригадасындагы сугышчан иптәшләре Чечняга омтылган Радуев бандасы юлына стена булып баса.



предприняли попытку прорыва на территорию Чечни, для чего им надо было пройти через кольцо окружения федеральных войск. По некоторым данным, информация о наименее укрепленном участке окружения была «слита» боевикам одним из журналистов, которые в погоне за сенсациями пробирались в село, «сдавались» боевикам и оттуда освещали ход событий. Накануне прорыва некоторых журналистов радуевцы отпустили.

Так получилась, что самые значительные силы боевиков были направлены на большой участок кольца окружения, охраняемый группой спецназа во главе с Альбертом Зариповым. Командование группировки, проводившее операцию, своевременно не позаботилось об усилении охраны этого участка, что и предопределило выбор Радуевым именно этого направления для прорыва.

Рванувшая на прорыв группа боевиков плотным огнем была отброшена. В этом бою Зарипов уничтожил два расчета крупнокалиберных пулеметов, а также несколько боевиков.

В ходе второй атаки боевикам удалось приблизиться к позициям группы Зарипова. В ходе боя противник стал забрасывать спецназовцев гранатами, ведя одновременно ожесточенный огонь из пулеметов и подствольных гранатометов. Появились убитые и раненые, которых старший лейтенант сумел эвакуировать.

Сдерживать превосходящие силы боевиков становилось все труднее, и группа получила приказ отойти от занимаемых позиций. Прикрывать отход своих бойцов остался командир. В бою Альберт получил тяжелое ранение в голову, в результате которого полностью лишился зрения. Усилия врачей госпиталя имени Бурденко оказались тщетны.

Указом Президента РФ от 15 мая 1996 года за мужество и героизм, проявленные при выполнении воинского долга, старшему лейтенанту Зарипову Альберту Маратовичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

Выйдя в отставку по инвалидности, он не стал заложником своего недуга, а вместе с близкими друзьями создал общественную организацию по защите прав таких же, как и он, инвалидов. Взялся за литературный труд, написал книгу «Первомайка», в которой высказал свою точку зрения на действия офицеров-десантников, выполнявших сходные задачи и располагавшихся на соседних позициях. Книга, изданная на личные сбережения автора сначала двухтысячным, затем десятитысячным тиражом, в массе своей была бесплатно роздана солдатам и курсантам училищ, а также офицерам боевых частей.

В настоящее время Альберт Зарипов живет в Москве, активно защищает права инвалидов войны, а также на собственные деньги строит Дом ветеранов имени лейтенанта Александра Винокурова, офицера 22-й бригады, героически погибшего у села Первомайское, но, к сожалению, забытого, как полагает Альберт, командованием.

Иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә 350 кешедән торган боевиклар Чечня территориясенә бәреп керергә омтылып карыйлар. Моның өчен аларга федераль гаскәрләр боҗрасын үтеп чыгарга кирәк була. Кайбер мәгълүматлар буенча боҗраның начаррак ныгытылган участогы турындагы хәбәрне боевикларга, сенсация артыннан куып, авылга кереп боевикларга «бирелгән» һәм шуннан торып вакыйгаларның барышын яктырткан журналистларның берсе әйткән диләр. Бәреп керү барышында радуевчылар берничә журналистны җибәрәләр.

Шулай килеп чыга: боевикларның иң көчле өлеше боҗраның Альберт Зарипов җитәкчелегендәге спецназ төркеме саклаган зур участогына таба юл ала. Операцияне уздырган җитәкчелек бу участоктагы сакны көчәйтү турында үз вакытында уйламаган, шуңа күрә Радуев нәкъ шушы юнәлешне сайлаган да.

Ерып чыгарга омтылган боевиклар төркеме көчле ут белән алып ыргытыла. Бу сугышта Зарипов эре калибрлы пулеметларның ике расчетын, шулай ук берничә боевикны юк итә.

Икенче һөҗүм вакытында боевиклар Зарипов төркеме позициясенә якынлаша төшә. Дошман спецназчыларга гранаталар ыргыта, бер үк вакытта пулеметлардан һәм гранатометлардан атуын да дәвам иттерә. Үтерелгән һәм яраланган сугышчыларны өлкән лейтенант эвакуацияли.

Көчләре өстенрәк булган боевикларны тоткарлап тору кыенлашканнан- кыенлаша бара. Шуңа күрә төркем үзләре торган позициядән китәргә дигән боерык ала. Сугышчыларның чигенүен каплап тору өчен командир кала. Сугышта Альбертның башы каты яралана, нәтиҗәдә ул тулысынча сукырая. Буденко исемендәге госпиталь табибларының тырышуы юкка булып чыга.

Сугышчан бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1996 елның 15 маендагы Указы нигезендә өлкән лейтенант Зарипов Альберт Марат улына Россия Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Инвалидлык буенча отставкага чыкса да, ул үзенең чире коллыгына төшми. Якын дуслары белән бергәләп үзе шикелле үк инвалидларның хокукларын яклау буенча иҗтимагый оешма оештыра. Әдәбиятка кереп китә, «Первомайка» дигән китап яза, анда ул янәшәдәге позицияләргә урнашып, шундый ук бурычларны үтәгән десантчы офицерларның гамәлләренә карата үз фикерен белдерә. Авторның үз акчасына башта ике мең, аннары ун мең тираж белән бастырып чыгарылган китап солдатларга һәм училище курсантларына, шулай ук хәрби частьлар офицерларына бушлай таратыла.

Хәзерге вакытта Альберт Зарипов Мәскәүдә яши, актив рәвештә сугыш инвалидларының хокукларын яклый. Үзенең үз акчасына Первомайское авылы янында геройларча һәлак булган, ләкин кызганычка каршы командование тарафыннан онытылган лейтенант Александр Винокуров (22 нче бригада офицеры) исемендәге Ветераннар йорты төзи.





# ИБРАГИМОВ Тимур Франилович

Родился в 1988 году в поселке Светлые Озера Брединского района Челябинской области. Проявил отвагу еще до армии – спас при пожаре семью из восьми человек. Его семья жила в двухэтажном бараке. Когда Тимур уходил на службу по контракту, пообещал родителям: «Заработаю денег – купим дом, родим вам внуков».

На службе Тимур стал стрелком штурмового отделения 27-го отряда специального назначения «Кузбасс» Сибирского регионального командования Внутренних войск МВД РФ.

14 марта 2009 года Ибрагимов был направлен в очередную командировку в Северо-Кавказский регион. В конце марта в районе села Какашура Карабудахкентского района Дагестана была обнаружена крупная банда боевиков. Подразделения отряда спецназа получили задачу по блокированию местности и проведению разведывательно-поисковых мероприятий. На второй день операции, 20 марта, поисковые группы отряда, в одну из которых входил рядовой Ибрагимов, продолжили уничтожение боевиков. Теснимая разведчиками бандгруппа с боем отходила вверх по горному склону. В бою получил тяжелое ранение начальник разведки Ангарского полка оперативного назначения внутренних войск майор В. Потапов, прибывший в эту командировку вместе с отрядом. Истекая кровью, он продолжал вести огонь.

Рядом с офицером занял позицию Тимур Ибрагимов. Вдвоем они прикрывали перемещение других бойцов группы. Тимуру удалось уничтожить двоих боевиков, после

1988 елны Чиләбе өлкәсенең Бредино районы Якты Күл бистәсендә туа. Армиягә киткәнче үк батырлык күрсәтә – янгын вакытында сигез кешелек гаиләне коткара. Аның гаиләсе ике катлы баракта яши. Контракт буенча хезмәт итәргә киткәндә, Тимур әти-әнисенә: «Акча эшләп кайтам да йорт сатып алырбыз, сезгә оныклар тудырырбыз».

Тимур РФ ЭЭМ Эчке гаскәрләрнең Себер төбәк командованиесендә «Кузбасс» спецназ отрядының 27 нче штурмлау отделениесе укчысы булып хезмәт итә.

2009 елның 14 мартында Ибраһимов Төньяк Кавказ төбәгенә чираттагы командировкага җибәрелә. Март ахырында Дагстанның Карабудахкент районы Какашура авылы тирәсендә боевикларның шактый зур бандасы барлыгы ачыклана. Спецназ отряды подразделениеләре җирлекне камап алу һәм разведка-эзләү эшләре уздыру боерыгы ала. Операциянең икенче көнендә, 20 мартта, составында рядовой Ибраһимов та булган эзләү төркемнәре боевикларны юкка чыгаруны дәвам иттерәләр. Разведчиклар тарафыннан кысрыкланган бандитлар төркеме, сугыша-сугыша, тау итәге буйлап өскә таба чигенә. Сугыш вакытында бу командировкага отряд белән бергә килгән эчке гаскәрләрнең оператив билгеләнештәге Ангар полкы разведка начальнигы майор В.Потапов авыр яралана. Каны агып торса да, ул ут яудыруын дәвам иттерә.

Тимур Ибраһимов офицер белән янәшә позициягә урнаша. Алар икәүләп төркемнең башка сугышчылары күче-





чего огонь противника на какое-то время ослаб. В этот момент боец увидел, что майор получил второе ранение и не может вести огонь. Ибрагимов попытался вынести командира из-под огня, но буквально в шаге от спасительного укрытия был сражен насмерть пулей снайпера. Второй пулей был убит майор Потапов.

В результате проведения спецоперации в течение трех суток было уничтожено двадцать боевиков, в том числе главарь бандформирования. Захвачены девять автоматов Калашникова, два ручных пулемета, снайперская винтовка, большое количество ручных гранат и боеприпасов к стрелковому оружию. Потери федеральных сил составили пять человек погибшими (четыре спецназовца и один член экипажа вертолета), двое спецназовцев были ранены.

Указом Президента РФ от 7 июля 2009 года рядовому Ибрагимову Тимуру Франиловичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).

Похоронен герой в селе Боровое Челябинской области. 30 сентября 2009 года медаль «Золотая Звезда» была вручена родителям погибшего Героя России.

шен каплап торалар. Тимурга ике боевикны юк итү насыйп була. Шуннан соң дошман уты күпмедер вакытка көчсезләнеп тора. Шул мизгелдә сугышчы майорның икенче яра алганын һәм ата алмый башлаганын күрә. Ибраһимов командирны ут астыннан алып чыгарга омтыла, ләкин яшеренү урынына бер адым гына калганда, снайпер пулясы тиеп һәлак була. Икенче пуля майор Потаповны үтерә.

Махсус операция нәтиҗәсендә өч тәүлек эчендә 20 боевик, шул исәптән бандформированиенең башлыгы да үтерелә. Тугыз Калашников автоматы, ике кул пулеметы, снайпер винтовкасы, күп кенә кул гранаталары һәм ату коралына кирәкле боеприпаслар кулга төшерелә. Федераль көчләрнең югалтулары һәлак булган биш кешедән тора (дүрт спецназчы һәм бер вертолет экипажы әгъзасы), ике спецназчы яралана.

РФ Президентының 2009 елның 7 июлендәге Указы нигезендә рядовой Ибраһимов Тимур Франил улына Россия Федерациясе Герое исеме бирелә (үлгәннән соң).

Герой Чиләбе өлкәсенең Боровое авылында күмелә. 2009 елның 30 сентябрендә «Алтын Йолдыз» медале һәлак булган Россия Героеның әти-әниләренә тапшырыла.





# ИГОШИН Роман Викторович

Родился 2 октября 1974 года в городе Дзержинске Нижегородской области. Учился в местной школе № 1. В 1992 году окончил Казанское суворовское военное училище, после которого поступил в Рязанское высшее воздушно-десантное училище, которое окончил с отличием.

16 августа 1999 года был направлен на службу в Северо-Кавказский военный округ для выполнения специального задания в Дагестане.

10 сентября ночью, при освобождении от боевиков населенного пункта Анди, старший лейтенант Роман Игошин выдвинул взвод вплотную к позициям боевиков, вскрыл их систему огня и обороны, что позволило командованию спланировать ведение боя.

Утром во время боя замаскировавшийся в непосредственной близости от позиций боевиков взвод Игошина по его приказу открыл внезапный огонь. Воспользовавшись замешательством мятежников, Игошин поднял взвод в атаку и захватил два дома на окраине населенного пункта, которые составляли основу обороны боевиков. Это позволило основным силам батальона войти в населенный пункт без потерь.

В ночь с 16 на 17 ноября 1999 года во время боев в районе населенного пункта Анди группа старшего лейтенанта Игошина попала в засаду и была окружена группой боевиков. Отвергнув предложение сдаться, старший лейтенант организовал круговую оборону и руководил боем до последней минуты своей жизни.

1974 елның 2 октябрендә Түбән Новгород өлкәсе Дзержинск шәһәрендә туа. Шәһәрдәге 1 нче мәктәптә укый. 1992 елда Казан Суворов хәрби училищесын тәмамлый, шуннан соң Рязань югары һава-десант училищесына керә. Аны бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый.

1999 елның 16 августында, Дагстанда махсус задание үтәү өчен, Төньяк Кавказ хәрби округына хезмәт итәргә җибәрелә.

10 сентябрь төнендә, Анди авылын боевиклардан азат иткәндә, өлкән лейтенант Роман Игошин взводын боевиклар позицияләренә бик якын китерә, аларның ут һәм саклану системасын эштән чыгара. Бу командованиегә сугыш барышын планлаштырырга мөмкинлек бирә.

Иртән Игошинның боевиклар позицияләре янәшәсендә үк маскировкаланган взводы аның боерыгы буенча көтмәгәндә ут ача. Дошманнарның аптырап калуыннан файдаланып, Игошин взводны һөҗүмгә күтәрә һәм боевикларның төп саклану урыны булган авыл кырыендагы ике өйне яулап ала. Шуның аркасында батальонның төп көчләре авылга югалтуларсыз керү мөмкинлеге ала.

1999 елның 16сыннан 17 сенә каршы төндә Анди авылы тирәсендәге сугышлар вакытында өлкән лейтенант Игошин бер көнне засадага эләгә һәм боевиклар төркеме чолганышында кала. «Бирелергә» дигән тәкъдимне кире кагып, өлкән лейтенант түгәрәк оборона оештыра һәм гомеренең соңгы минутына кадәр сугыш белән җитәкчелек итә.





Указом Президента РФ от 23 марта 2000 года за мужество и героизм, проявленные при исполнении воинского долга в Республике Дагестан, старшему лейтенанту Игошину Роману Викторовичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно). При жизни он был награжден орденом Мужества и золотыми часами.

Похоронен отважный офицер на Заволжском кладбище в Ульяновске. В Дзержинске на здании школы №1, в которой учился герой, установлена мемориальная доска.

Дагстан Республикасында хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2000 елның 23 мартындагы Указы нигезендә өлкән лейтенант Игошин Роман Викторовичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә (үлгәннән соң). Исән вакытында ул Батырлык ордены һәм алтын сәгать белән бүләкләнгән була.

Куркусыз офицер Ульяновскидагы Идел аръягы зиратына күмелгән. Дзержинскида герой укыган 1 нче мәктәп бинасына мемориаль такта куелган.





Родился 14 января 1964 года в деревне Средний Кушкет Балтасинского района ТАССР. Каждый год в день его рождения жители Балтасинского района вспоминают своего земляка – летчика-истребителя Олега Исаева, ставшего Героем России. В этот день педагоги и учащиеся на встречу в школу, где он учился, приглашают его родителей Николая Степановича и Веру Петровну.

Неторопливо осматривают они обновленные стенды, посвященные их сыну. С фотографий на стендах смотрит обычный парень: физически крепкий, с открытым, приветливым лицом. Для всех он остался в памяти молодым, активным, добрым.

На одном из них стихи:

Герой не гибнет умирая:
Вторая жизнь ему дана.
И эта жизнь его вторая
Бессмертной славою полна.

– Олег у нас хорошо учился, мы хлопот не знали, – говорит отец. – После школы он поступил в Арское педучилище, а когда окончил, преподавал в начальных классах Иштуганской восьмилетней школы в Сабинском районе. Оттуда его призвали в армию. Присягу Олег принимал в воинской части в Краснодаре, я к нему ездил. Вот тогда-то он мне сообщил, что хочет стать летчиком, поступить в Высшее военное авиационное училище им. В. Чкалова, что в Борисоглебске. Я благословил его. Олег с детства мечтал летать. Как-то еще мальчишкой хотел полетать на планере, который случайно приземлился около деревни.

# ИСАЕВ Олег Николаевич

ТАССРның Балтач районы Урта Кушкет авылында 1964 елның 14 гыйнварында туа. Балтач районында яшәүчеләр үзләренең якташлары – очучы-истребитель, Россия Герое Олег Исаевны һәр елны да аның туган көнендә зурлап искә алалар. Бу көнне ул укыган мәктәп укытучылары һәм укучылары аның әтисе Николай Степановичны һәм әнисе Вера Петровнаны үзләре белән очрашуга чакыралар.

...Менә алар, ашыкмый гына, үзләренең улларына багышланган яңартылган стендны карыйлар. Андагы фоторәсемнән физик яктан чынык, мөлаем, ачык йөзле, гапгади егет карап тора. Һәркемнең дә хәтерендә ул яшь, актив, мәрхәмәтле булып кереп калган.

Мондагы стендларның берсенә язып куелган шигырьдә мондый юллар бар:

Герой үлгәч тә юкка чыкмый,
Аңа икенче гомер бирелгән...

– Безнең Олег мәктәптә яхшы укыды, без аннан бернинди дә борчу күрмәдек, – ди Николай Степанович. – Мәктәпне тәмамлаганнан соң ул Арча педагогия училищесына укырга керде, кулына диплом алганнан соң Саба районының Иштуган сигезьеллык мәктәбенең башлангыч классларында укытучы булып эшләде. Аннан ул армия сафларына хәрби хезмәткә китте. Олег присяганы Краснодарда бер хәрби частьта кабул итте. Мин аның янына барган идем. Менә шул чагында мин аңардан В.Чкалов исемендәге югары хәрби авиация училищесына укырга кереп, очучы булырга теләвен белдем һәм мин аның бу теләген шатланып кабул иттем. Чөнки Олег бала чагыннан ук очучы булырга хыяллана иде. Авылыбыз янына очраклы рәвештә генә җиргә очып төшкән планерны күргәч, ул аеруча канатланды.

После четырех лет учебы Олег Исаев в звании лейтенанта получил назначение в Северо-Кавказский военный округ. Служил в Азербайджане, затем его переводят в Группу советских войск в Германии. Закончив там службу, перевелся в Воронеж.

13 июня 1984 года на аэродроме Жовтнево в Западной Украине был сформирован полк, который через полтора года перебросили в Афганистан. Основной задачей этого полка было прикрытие автоколонн, высадка десанта и нанесение ракетно-бомбовых ударов по скоплениям душманов.

С 1993 по 1996 год служил в Буденновске Ставропольского края, в 368-м отдельном штурмовом авиаполку 4-й Воздушной армии. В декабре 1994 года началось выполнение специальных задач по наведению конституционного порядка на территории Чечни. Летал на Су-25УБ. Совершил свыше 100 боевых вылетов, уничтожив 3 танка, 15 единиц автомобильной и боевой техники, 3 зенитных ракетных установки с расчетами.

4 апреля 1996 года при выполнении боевой задачи был сбит самолет летчика полка. Маневрируя и ведя огонь, майор Исаев не дал боевикам захватить покинувшего самолет летчика майора А.В. Матвиенко. Прикрывая огнем бортового оружия, дал возможность спасательному вертолету забрать летчика.

За боевые заслуги его награждают медалью «За отвагу», а министр обороны – именными наручными часами.

Боевой вылет 5 мая 1996 года оказался роковым. По данным разведки, в Урус-Мартановском районе была обнаружено большое скопление боевиков. Экипаж в составе полковника И.В. Свиридова и О.Н. Исаева нанес ракетно-бомбовый удар, в результате которого были уничтожены 2 БТР, 2 автомашины и до 30 дудаевцев. При очередном заходе выпущенная из ПЗРК ракета угодила в штурмовик. Объятый пламенем самолет летчики направили на скопление боевиков. Так погибли Герои.

За мужество и героизм, проявленные при выполнении специального задания, указом Президента Российской Федерации от 13 июня 1996 года майору Исаеву Олегу Николаевичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно). Похоронили его в Воронеже на Аллее Героев. У него остались жена и сын.

На малой родине, в деревне Средний Кушкет, на доме установлена мемориальная доска, на которой написано: «В этом доме родился и вырос Герой России Олег Исаев». При въезде в деревню встречает приезжих вывеска «Средний Кушкет – родная деревня Героя России Олега Исаева».

Виктор Камалов учитель школы вспоминает: «Герой России Олег Исаев – мой друг с детства. Мы учились в одном классе, в Арском педучилище жили в одной комнате общежития. Так сложилось, что я теперь преподаю в нашей родной школе. Именно поэтому стараюсь сделать все, чтобы увековечить память Героя России. Каждый год 14 января, в день рождения Олега, мы проводим не только торжественную линейку, но и спортивные соревнования на приз Олега Исаева».

Хәрби очучылар хәзерләү училищесында дүрт ел укыганнан соң лейтенант Олег Исаев Төньяк-Кавказ хәрби округына билгеләнә. Әзербайҗанда хезмәт итә, аннан соң ул Германиядәге совет сугышчылары группасына күчерелә. Анда хәрби хезмәт срогын тәмамлаганнан соң Воронеж шәһәренә җибәрелә.

1984 елның 13 июнендә Көнбатыш Украинадагы Жовтнево аэродромында полк оештырыла һәм аны ел ярымнан соң Афганистанга күчерәләр. Бу полкка автоколонналар юлын «бикләү», десант төшерү һәм дошманнар тупланган урыннарга ракета-бомбалар белән һөҗүм итү бурычы куела.

1993 елдан 1996 елга кадәр Олег Исаев Ставрополь краеның Буденновск шәһәрендә 368 нче авиаполкта хезмәт итә. 1994 елның декабрендә исә ул Чечен республикасында конституцион тәртип урнаштыру буенча махсус бурычларны үтәүгә керешә. Олег СУ-25УБ самолетында очышлар ясый, 3 танкны, 15 берәмлек автомобиль һәм сугышчан техниканы, 3 ракеталар җайланмасын юк итә.

1996 елның 4 апрелендә һавада майор Олег Исаевның полкташы очучы А.В. Матвиенко җитди уңышсызлыкка очрый. Ләкин кыю очучы О.Исаев, көчле һөҗүм ясап, полкташы боевиклар кулына эләгүдән коткарып кала.

Сугышчан казанышлары өчен олег Исаев «Кыюлы өчен» медале белән бүләкләнә, оборона министры аны исемле кул сәгате белән бүләкли.

Кызганычка каршы, Олег Николаевич Исаевның 1996 елның май көннендәге хәрби очышы фаҗигале тәмамлана. Разведка мәгълүматларына караганда Чечен республикасының Урус-Мартан районында боевикларның зур бер группасы тупланганлыгы билгеле була. Полковник И.В. Свиридов һәм майор О.Н. Исаев составындагы экипаж аларга һавадан ракета-бомба һөҗүме ясаганнан соң боевикларның 2 БТРы, 2 автомашинасы һәм 30га якын дудаевчылары тар-мар ителә. Шул урынга чираттагы очыш ясаганда штурмовик ракета һөҗүменә эләгә. Очучылар ялкын белән чорнап алынган самолетны җирдә боевиклар тупланган урынга юнәлтәләр... Геройлар шулай һәлак була.

Махсус заданиене үтәүдә күрсәткән кыюлыгы һәм батырлыгы өчен, РФ Президентының 1996 елның 13 июнь Указы белән, майор Олег Николаевич Исаевка, үлеменнән соң, Россия Федерациясе Герое дигән югары исем бирелә. Ул Воронеж шәһәрендә Геройлар Аллеясында җирләнә. Аның хатыны һәм улы кала.

Урта Кушкет авылында О.Исаев туган йортка мемориаль такта урнаштырылган. Анда болай диелгән: «Бу йортта Россия Герое Олег Исаев туды». Авылга кергәндә: «Урта Кушкет – Россия Герое Олег Исаевның туган авылы», – дип язылган махсус такта куелган. Мәктәп укытучысы Виктор Камалов болай дип искә ала: «Россия Герое Олег Исаев – минем яшьлек дустым. Без аның белән бер класста укыдык, Арча педагогик училищесы тулай торагында бер бүлмәдә яшәдек. Шулай килеп чыкты, мин хәзер үзебезнең туган мәктәбебездә укытам. Шуның өчен дә барысын да эшләргә тырышам. Һәр елның 14 гыйнварында, Олегның туган көнендә, без тантаналы линейкалар үткәрү белән беррәттән, Герой призына спорт ярышлары да оештырабыз.





# ИХСАНОВ Рафик Рашитович

Родился 27 сентября 1965 года в деревне Нижнее Аврюзово Альшеевского района Башкортостана в крестьянской семье. Аул, в котором рос Рафик, интернациональный: в нем исстари в дружбе и согласии живут башкиры, татары, русские.

В семье Ихсановых было четверо сыновей. Родители воспитывали их по неписаным законам крестьянской педагогики, в основе которой лежит труд. Учился Рафик в средней школе, расположенной в соседнем селе за три километра. Особой популярностью среди учеников пользовались уроки начальной военной подготовки. Ребята увлеченно занимались стрелковым делом в тире, который построили сами под началом военрука, строевой подготовкой, различными видами спорта.

После получение школьного аттестата Рафику особо задумываться о своем будущем не пришлось. «Мне, – вспоминает он, – как и многим одноклассникам, выбрать профессию помог любимый учитель по начальной военной подготовке – Сиухин Анатолий Петрович, офицер запаса. Он буквально заворожил нас, мальчишек, военным делом. Еще в восьмом классе я твердо решил для себя, что стану военным летчиком.

После строгой медицинской комиссии и успешной сдачи экзаменов я стал курсантом Саратовского высшего военного авиационного (вертолетного) училища. О том, что оказался в семье вертолетчиков, узнал только в училище и был немного разочарован: я ведь, как и многие пацаны, мечтал стать летчиком-истребителем. Но в последующие годы никогда не пожалел, что стал вертолетчиком.

1965 елның 27 сентябрендә Башкортстанның Әлши районы Түбән Әүрүз авылында крестьян гаиләсендә туа. Рафик үскән авыл интернациональ: анда элек-электән башкортлар, татарлар, руслар тату гомер кичерә.

Ихсановлар гаиләсендә дүрт малай үсә. Әти-әниләре аларны крестьян педагогикасының нигезендә хезмәт яткан язылмаган законнары буенча тәрбияли.

Рафик өч чакрым ераклыкта урнашкан күрше авыл мәктәбендә укый. Укучылар башлангыч хәрби әзерлек дәресләрен аеруча ярата. Егетләр военрук җитәкчелегендә үзләре төзегән тирда ату белән, строевой әзерлек, спортның төрле төрләре белән шөгыльләнә.

Мәктәп аттестатын алганнан соң Рафик үзенең киләчәге турында әллә ни уйлап та тормый. «Күп сыйныфташларым кебек үк миңа да һөнәр сайларга башлангыч хәрби әзерлек буенча яраткан укытучым – запастагы офицер Сиухин Анатолий Петрович ярдәм итте, – дип искә ала ул. – Без малайларны ул хәрби эш белән чын мәгънәсендә сихерләде. Сигезенче сыйныфта укыганда ук хәрби очучы булачагымны хәл иткән идем инде.

Катгый медицина комиссиясе үткәннән һәм имтиханнар тапшырганнан соң, мин Саратов югары хәрби авиация (вертолет) училищесы курсанты булдым. Вертолетчылар гаиләсенә эләгүемне училищеда укый башлагач кына белдем һәм азрак кәефем дә кырылды. Бик күп егетләр кебек үк мин дә очучы-истребитель булырга хыялланган идем бит. Ләкин соңыннан вертолетчы булуыма бер дә үкен-мәдем.






Вертолет – это машина более широких по сравнению с самолетом-истребителем или штурмовиком возможностей. Он может совершать посадки на неподготовленные площадки, выполнять непосредственно огневую поддержку, перевозку грузов, спасательные работы и другие спецоперации».

Училище Рафик окончил в двадцать один год. После налета определенного количества часов подал рапорт с просьбой о добровольном направлении в Афганистан. «Когда меня спрашивали, не испытывал ли чувства страха, намереваясь оказаться в воюющей стране, отвечал откровенно: «Да, испытывал», – вспоминает Ихсанов. – Но такое было воспитание. К тому же мы, военные люди, понимали, что исполняли интернациональный долг».

За год службы в Афганистане молодой летчик совершил 280 боевых вылетов. Смерть не раз глядела ему в глаза, не однажды он оказывался под огнем. Из афганской командировки Рафик вернулся с орденом «За службу Родине в Вооруженныхь силах СССР» 3-й степени и в звании старшего лейтенанта.

Вертолет ул – самолет-истребитель яки штурмлаучы самолет белән чагыштырганда зуррак мөмкинлекләргә ия машина. Ул алдан әзерләп куелмаган мәйданчыкларга төшеп утыра, турыдан-туры ут ача, йөкләр күчерә, коткару эшләре һәм башка махсус операцияләр башкара ала».

Училищены Рафик 21 яшьтә тәмамлый. Билгеле бер сандагы сәгатьләрен очканнан соң, Әфганстанга җибәрүләрен үтенеп, үз ирке белән рапорт яза. «Сугыш бара торган илгә китәргә җыенганда курку хисе тойдыңмы, дип сораучыларга ачыктан-ачык: «Әйе, тойдым», – дип җавап бирә идем, – дип искә ала Ихсанов. – Ләкин минем тәрбиям шундый иде. Өстәвенә без, хәрби кешеләр, интернациональ бурыч үтәгәнебезне аңлый идек».

Әфганстанда хезмәт иткән елларында яшь очучы 280 хәрби очыш ясый. Ул берничә тапкыр үлем белән күзгә-күз очраша, ут астында кала. Әфган командировкасыннан Рафик 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены белән һәм өлкән лейтенант званиесендә кайта.

За годы последующей службы в ряде военных округов Ихсанов сложился как опытный военный летчик, прошедший ряд ступеней летной карьеры от летчика вертолета Ми-24 до командира эскадрильи.

Шел 1988 год – начальный этап так называемой перестройки, а по сути, распада великой державы – Советского Союза. «Мы дислоцировались на Украине, – вспоминает Рафик Рашитович. – Местные власти предложили нам принять присягу Украине. Однако мы заявили им, что военные два раза не присягают. Испокон веков в русской армии отказ от уже принесенной однажды присяги считался предательством. У меня в это время все складывалось благополучно: я в 1992 году стал слушателем Военно-воздушной академии имени Гагарина, а после ее окончания в 1995 году меня направили в Буденновск заместителем командира вертолетной эскадрильи».

В 1995-96 годы и затем в 1999-2000-е подполковник Рафик Ихсанов выполнял боевые задачи в Северо-Кавказском регионе. В частности, в январе 1996-го участвовал в освобождении заложников в Кизляре и Первомайском.

На новом месте службы Ихсанов сразу взялся за организацию боевой и летной подготовки. Как ни скудно было с горючим и с запасными частями, Рафик Рашитович сумел в сжатые сроки «поднять на крыло» молодых вертолетчиков. Проверку на боеспособность и летное мастерство подчиненные Ихсанова проходили не на учебном полигоне, а в небе Дагестана и Чечни. Вертолетчики наносили огневые удары по скоплениям боевиков, вели воздушную разведку, высаживали и эвакуировали разведгруппы.

13 декабря 1999 года в районе Аргунского ущелья, на территории Чеченской Республики, контролируемой в то время боевиками, катапультировался летчик сбитого штурмовика Су-25. Ему на выручку вылетел вертолет поисково-спасательного обеспечения с десантниками на борту. Однако и эту машину при подходе к месту происшествия боевики подбили, и она совершила вынужденную посадку. Для спасения подбитого экипажа и десантников отправилась группа вертолетов, в состав которой входил и вертолет Ихсанова. Под ураганным огнем боевиков они сделали все возможное для спасения людей.

18 февраля 2000 года Рафик Рашитович командовал парой вертолетов огневой поддержки, прикрывавших высадку воздушного десанта в районе населенного пункта Дай. При попытке боевиков контратаковать десант Ихсанов уничтожил три огневые точки. Благодаря смелым и решительным действиям вертолетчиков десант занял высоту с минимальными потерями. После высадки десанта командир эскадрильи заметил шлейф черного дыма за ведомой машиной. Он приказал летчикам срочно покинуть горящий вертолет, а сам под шквальным огнем бандитов совершил посадку и принял на свой борт экипаж ведомой машины. За успешное выполнение боевой задачи и за блестящий маневр по спасению пилотов командование представило Ихсанова Р.Р. к званию Героя.

Указом Президента РФ от 21 апреля 2000 года заместителю командира вертолетного полка подполковнику Ихсанову Рафику Рашитовичу за мужество и героизм, проявленные при исполнении воинского долга в Северо-Кавказском регионе, присвоено звание Героя России с вручением медали «Золотая Звезда».

Шуннан соң төрле хәрби округларда хезмәт итү елларында Ихсанов очучылык карьерасының «Ми-24» вертолеты очучысыннан башлап эскадрилья командирына кадәр баскычларын үткән тәҗрибәле хәрби очучы булып җитешә.

Үзгәртеп коруның, чынлыкта Советлар Союзы дигән бөек держава таркалуның башлангыч этабы булган 1988 ел бара. «Без Украинада дислокацияләндек, – дип искә ала Рафик Рәшит улы. – Җирле хакимиятләр безгә Украинага присяга кабул итәргә тәкъдим иттеләр. Ләкин без аларга, хәрбиләр ике тапкыр присяга кабул итми, дип әйттек. Борын-борыннан рус армиясендә бер тапкыр кабул ителгән присягадан баш тарту хыянәт дип саналган. Ул вакытта минем бөтен эшем җайлы бара иде: 1992 елда Гагарин исемендәге Хәрби һава академиясе тыңлаучысы булдым, аны тәмамлагач, 1995 елда мине вертолет эскадрильясы командиры урынбасары итеп Буденновскига җибәрделәр».

1995–1996 елларда, аннары 1999–2000 елларда подполковник Рафик Ихсанов Төньяк Кавказ төбәгендә сугышчан бурычлар үти. Мәсәлән, 1996 елның гыйнварында Кизлярда һәм Первомайскоеда тотыкларны азат итүдә катнаша.

Яңа хезмәт урынына килүгә үк Ихсанов сугышчан һәм очу әзерлеген оештырып җибәрә. Ягулык һәм запас частьлар җитешмәсә дә, Рафик Рәшит улы кыска срокларда яшь вертолетчыларга «канат куя» ала. Ихсанов кул астындагылар сугышка сәләтлелекне һәм очу осталыгын тикшерүне уку полигонында түгел, ә Дагстан һәм Чечня күгендә үтәләр. Вертолетчылар боевиклар тупланган урыннарга ут ача, һавада разведка алып бара, разведка төркемнәрен төшерә һәм эвакуацияли.

1999 елның 13 декабрендә Чечня Республикасының ул чакта боевиклар контрольлегендә булган территориясендә – Аргун тарлавыгы тирәсендә бәреп төшерелгән штурмлаучы «Су-25» очучысы парашют белән сикерә. Аңа ярдәмгә бортында десантчылар булган эзләү-коткаручы тәэмин итүче вертолет оча. Ләкин вакыйга булган урынга килеп җитәрәк бу машинаны да боевиклар атып сафтан чыгаралар, һәм ул төшеп утырырга мәҗбүр була. Бәреп төшерелгән экипажны һәм десантчыларны коткару өчен вертолетлар төркеме китә, алар арасында Ихсанов вертолеты да була. Боевикларның давылдай уты астында алар кешеләрне коткару өчен мөмкин булганның барысын да эшлиләр.

2000 елның 18 февралендә Рафик Рәшит улы Дай авылы тирәсенә төшүче һава десантын каплап тора торган ике вертолет белән командалык итә. Боевиклар десантка һөҗүм ясарга тырышканда, Ихсанов өч ут ноктасын юкка чыгара. Вертолетчыларның кыю һәм тәвәккәл гамәлләре аркасында, десант биеклекне аз югалтулар белән генә ала. Десантны төшергәннән соң эскадрилья командиры иекнче машина артында кара төтен күреп ала. Ул очучыларга януы вертолетны тиз арада ташлап китәргә боера, ә үзе бандитларның көчле уты астында төшеп утыра һәм икенче машина экипажын үз бортына ала. Сугышчан бурычны уңышлы үтәгән һәм пилотларны коткарганда шәп маневр ясаганы өчен командований Р.Р.Ихсановны Герой исеменә тәкъдим итә.

Төньяк Кавказ төбәгендә сугышчан бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2000 елның 21 апрелендәге Указы нигезендә вертолет полкы командиры урынбасары подполковник Ихсанов Рафик Рәшит улына Россия Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.





Когда командир полка перед строем объявил о присвоении Ихсанову звания Героя России, он в ответном слове сказал, что эту награду считает общей для всей его эскадрильи вертолетов Ми-8 и Ми-24.

С 2001 года Ихсанов Р.Р.– командир вертолетного полка в Забайкалье, в Сибирском военном округе. Ему было поручено передислоцировать полк с одной базы на другую. Потребовалось немало усилий, чтобы в установленные сроки осуществить перебазирование, а затем обеспечить все условия для боевой учебы, а также нормальной жизни личного состава полка и членов их семей.

После Забайкалья Рифкат Рашитович несколько лет служил в системе главного командования ВВС на должности начальника группы. С 2004 года живет с семьей в Москве, работает заместителем генерального директора федерального агентства по правовой защите результатов интеллектуальной деятельности военного, специального и двойного назначения при Минюсте России. На общественных началах является вице-президентом Фонда поддержки Героев Советского Союза и Героев России. С 2006 года полковник Ихсанов Рафик Рашитович находится в запасе.

Полк командиры Ихсановка Россия Герое исеме бирелү турында строй алдында игълан иткәч, җавап сүзендә ул бу бүләкне «Ми-8» һәм «Ми-24» вертолетлары эскадрильясыныке дип санавын әйтә.

2001 елдан Р.Р.Ихсанов – Байкал артында, Себер хәрби округында вертолет полкы командиры. Аңа полкын бер базадан икенчесенә күчереп урнаштырырга кушылган була. Күченүне куелган срокларда башкару, ә аннары хәрби өйрәнүләр өчен, полктагы солдат һәм офицерларның, аларның гаилә әгъзаларының нормаль яшәве өчен бөтен шартларны тудыруга шактый көч түгәргә туры килә.

Байкал артыннан соң Рафик Рәшит улы берничә ел төркем начальнигы вазыйфасында ХҺК баш командованиесе системасында хезмәт итә. 2004 елдан башлап гаиләсе белән Мәскәүдә яши, Россия Юстиция министрлыгы каршындагы хәрби, махсус билгеләнештәге интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен хокукый яклау федераль агентлыгының генераль директоры урынбасары булып эшли. Советлар Союзы Геройларына һәм Россия Геройларына ярдәм фонды вице-президенты да булып тора. 2006 елдан полковник Ихсанов Рафик Рәшит улы запаска чыга.





# КАЧКОВСКИЙ Сергей Владиславович

Родился 5 октября 1968 года в селе Молога Белгород-Днестровского района Одесской области Украинской ССР в семье рабочих. Окончил Затишанскую среднюю школу в 1985 году и в том же году поступил в Казанское высшее командное танковое училище, которое окончил в 1989 году.

Воинскую службу молодой офицер начал в Ленинградском военном округе в должности командира танкового взвода. Вскоре его назначили командиром танковой роты, а затем заместителем командира – начальником штаба отдельного танкового батальона.

С декабря 1994 года Сергей в составе 133-го отдельного танкового батальона 45-й гвардейской мотострелковой дивизии Ленинградского военного округа участвовал в боевых действиях в Чеченской Республике. С 31 декабря 1994 года принимал участие в штурме Грозного. В самых тяжелых боях в первых числах января 1995 года рота капитана Качковского была на острие атак. Его танковые экипажи наносили тяжелые потери дудаевским боевикам, находясь на самых опасных участках, поддерживая подразделения мотострелков. В одном из боев капитан Качковский был тяжело ранен.

За мужество и героизм, проявленные при выполнении специального задания, указом Президента РФ от 6 марта 1995 года капитану Качковскому Сергею Владиславовичу присвоено звание Героя Российской Федерации.

После излечения Сергей Владиславович продолжил службу. Он поступил в Военную академию бронетанковых

1968 елның 5 октябрендә Украина ССРның Одесса өлкәсе Белгород-Днестр районы Молога авылында эшчеләр гаиләсендә туа. 1985 елда Затишан урта мәктәбен тәмамлый һәм шул ук елны Казан югары командa танк училищесына укырга керә. Аны 1989 елда тәмамлый.

Яшь офицер хәрби хезмәтен Ленинград хәрби округында танк взводы командиры вазыйфасында башлап җибәрә. Тиздән аны танк ротасы командиры, ә аннары махсус танк батальоны командиры урынбасары – штаб начальнигы итеп билгелиләр.

1994 елның декабреннән Сергей Ленинград хәрби округының 45 нче гвардия мотоукчылар дивизиясе 133 нче махсус танк батальоны составында Чечня Республикасындагы хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. 1994 елның 31 декабреннән Грозныйны штурмлауда катнаша. 1995 елның гыйнвар башларындагы иң авыр сугышларда капитан Качковский ротасы һөҗүмнең үзәгендә була. Аның танк экипажлары, иң куркыныч участокларда торган килеш, мотоукчылар подразделениеләренә булышып, дудаевчы боевикларны авыр югалтуларга дучар итәләр. Сугышларның берсендә капитан Качковский каты яралана.

Махсус заданиены үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1995 елның 6 мартындагы Указы нигезендә капитан Качковский Сергей Владиславовичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә.





войск имени Малиновского в 1998 году, а когда пришло время уйти в запас, ему предложили возглавить военкомат города Санкт-Петербурга.

Но вернемся к сослуживцам Качковского. В 1994 году 133-й танковый батальон и 129-й гвардейский мотострелковый полк были направлены на Кавказ в качестве миротворческих сил. Никто не мог тогда предполагать, чем обернется эта командировка. У многих из боевых друзей и сослуживцев Сергея Качковского оборвались там молодые жизни. С тех пор те, кто остался жив, свято хранят память об ушедших. 13 декабря для них – день особый: ежегодно в этот день они встречаются, вспоминают поименно безвременно ушедших из жизни.

Среди собравшихся обязательно присутствует и Герой России полковник Сергей Качковский, который был командиром танковой роты в 133-м отдельном танковом батальоне.

– Когда встречаюсь 13 декабря с сослуживцами, испытываю смешанные чувства, – говорит Сергей Владиславович. – С одной стороны, чувство скорби по тем, кого с нами сегодня нет, с другой – чувство огромной радости от встречи с оставшимися в живых, от возможности обнять их, обменяться крепкими рукопожатиями…

– Я безмерно горжусь тем, что мне довелось оказаться рядом с такими стойкими ребятами в неимоверно тяжелые минуты боевой жизни, – добавляет к этим словам нынешний командир 138-й мотострелковой бригады гвардии полковник Алибек Асланбеков, бывший в ту пору командиром мотострелкового батальона.

Терелгәннән соң Сергей Владиславович хезмәтен дәвам иттерә. Ул Малиновский исемендәге Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясенә 1998 елда керә, ә запаска чыгар вакыты җиткәч, аңа Санкт-Петербург шәһәренең хәрби комиссариатын җитәкләргә тәкъдим итәләр.

Качковскийның хезмәттәшләренә әйләнеп кайтсак, 1994 елда 133 нче танк батальоны һәм 129 нчы гвардия мотоукчылар полкы тынычлык урнаштыручы көчләр сыйфатында Кавказга җибәреләләр. Бу командировканың ахыры ничек буласын ул чакта беркем дә фаразлый алмый. Сергей Качковскийның сугышчан дуслары һәм хезмәттәшләреннән күбесенең анда яшь гомерләре өзелә. Шуннан бирле исән калганнары үлгәннәр истәлеген изге итеп саклый. Алар өчен 13 декабрь – аерым көн: ел саен шушы көнне алар очрашалар, деньядан вакытсыз киткәннәрнең һәрберсен исемләп искә төшерәләр.

Җыелганнар арасында 133 нче махсус танк батальонында танк ротасы командиры булган Россия Герое полковник Сергей Качковский булмый калмый.

– 13 декабрьдә хезмәттәшләрем белән очрашканда, катнаш хисләр кичерәм, – дип сөйли Сергей Владиславович. – Бер яктан, бүген безнең янәшәбездә булмаган кешеләр өчен хәсрәтләнү, икенче яктан исән калганнар белән очрашу, аларны кочаклау мөмкинлеге, нык итеп кул кысышудан туган бик зур шатлык хисе…

– Сугыштагы тормышның гаять авыр минутларында шундый нык егетләр белән янәшәдә булырга туры килүгә чиксез горурланам, – дип өсти ул чакта мотоукчылар батальоны командиры булган, хәзер 138 нче мотоукчылар бригадасы командиры – гвардия полковнигы Алибәк Асланбәков.





# КЛУПОВ
## Рустем Максович

Родился в 27 октября 1963 года в Баку, в семье военнослужащего. Окончив среднюю школу, поступил в Ташкентское высшее общевойсковое командное училище, которое окончил в 1985 году. Военную службу Рустем начинал в разведывательном батальоне прославленной Кантемировской дивизии Московского военного округа, в дальнейшем служил в Туркестанском военном округе, откуда направлялся командованием для выполнения боевых задач на территорию Афганистана. После начала вывода Ограниченного контингента советских войск из ДРА продолжил службу в 70-м мотострелковом полку в Грозном, затем в 245-м мотострелковом полку в городе Магдебурге ГДР.

В октябре 1992 года Клупов был назначен командиром мотострелковой роты 131-й отдельной мотострелковой бригады Северо-Кавказского военного округа в Майкопе. В период с ноября 1992 года по май 1993-го капитан Клупов в составе своей части участвовал в прекращении Осетино-Ингушского вооруженного конфликта. С декабря 1994 года участвовал в контртеррористической операции (первой военной кампании) на территории Чеченской Республики. В многочисленных боевых столкновениях с бандформированиями не раз проявил мужество и отвагу.

При вступлении российских войск в Грозный 31 декабря 1994 года капитан Клупов во главе головной походной заставы обеспечивал продвижение мотострелковой бригады к железнодорожному вокзалу. Его подразделение стремительным броском захватило мост через реку Нефтянку и тем самым обеспечило выдвижение бригады в центр Грозного. Поначалу все шло достаточно успешно. При подходе к вокзалу удалось уничтожить группу боевиков из 8 человек, а при разведке местности вокруг вокзала еще две группы из 20 дудаевцев.

Никто из федералов не ожидал тогда, что боевики окажут столь яростное сопротивление. Хорошо вооруженные и обученные дудаевские бандформирования, основательно укрепившись на заранее подготовленных позициях, часто контратаковали федеральные войска.

Вечером 31 декабря капитан Клупов получил приказ возглавить 1-й мотострелковый батальон вместо выбывшего по ранению его командира. В ходе ожесточенного боя в окружении он организовал круговую оборону, был контужен, но оставался в строю. Теснимая боевиками бригада несла потери личного состава и боевой техники. С группой прикрытия Рустем прорвался в район товарной станции. Там оборонялись разрозненные группы солдат 81-го мотострелкового полка из Самары. Собрав под свое командование все эти группы, капитан направил их вторично на прорыв из окружения, а сам с двумя бойцами остался прикрывать отход. В ночь на 2 января 1995 года, выполнив задачу, вышел в расположение своих частей.

В центре Грозного, по сути дела попавшие в ловушку, оборонялись мотострелковые части. Как знающему обстановку капитану Клупову было вновь приказано вывести из западни сражающихся бойцов. Вернувшись в зону наиболее тяжелых боев, Рустем собрал боевую группу из бойцов 131-й мотострелковой бригады и 81-го мотострелкового полка с остатками техники и с боем, прорвав заслон боевиков, вывел их из окружения. Сам при этом получил ранения, вследствие чего был отправлен в военный госпиталь Ростова-на-Дону.

В ходе тяжелых и кровопролитных боев на территории Чечни с 31 декабря 1994-го по 2 января 1995 года силами и средствами своего подразделения Рустем Клупов уничтожил 3 танка, несколько орудий, 2 БТР, 12 огневых точек и около 60 боевиков, при этом лично уничтожил 1 танк, 5 огневых точек и 9 боевиков.

В 1995 году Рустема Максовича назначили начальником разведки 131-й отдельной мотострелковой бригады Северо-Кавказского военного округа. А с февраля 1996 года подразделения 131-й Майкопской бригады вновь в зоне боевых действий в составе войсковой маневренной группы Объединенного командования федеральных войск в Чечне. Руководя разведкой бригады, Клупов лично командовал одним из разведывательных дозоров. Практически постоянно действуя на территории, контролируемой бандами боевиков, разведывательные подразделения под руководством майора Клупова провели немало разведывательных операций и специальных мероприятий. Наиболее значимыми из них стали:

– разгром крупной международной банды иностранных наемников с позывным «Горец» и уничтожение большей части ее членов, способствовавшее общему разгрому группировки сепаратистов в Ножай-Юртовском районе;

– дерзкий и внезапный захват господствующих высот над населенным пунктом Ведено;

1963 елның 27 октябрендә Бакуда хәрби хезмәткәр гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Ташкент югары гомуми гаскәрләр команда училищесына укырга керәп, аны 1985 елда тәмамлый. Хәрби хезмәтен Рөстәм Мәскәү хәрби округының танылган Кантемир дивизиясендәге разведка батальонында башлап җибәрә. Аннан соң Төркестан хәрби округында хезмәт итә. Шуннан хәрби бурычларны үтәү өчен командование тарафыннан Әфганстан территориясенә җибәрелә. Совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты ӘДРдан чыгарыла башлагач, хезмәтен Грозныйдагы 70 нче мотоукчылар полкында, аннары ГДРдагы Магдебург шәһәрендә 245 нче мотоукчылар полкында дәвам иттерә.

1992 елның октябрендә Клупов Майкоптагы Төньяк Кавказ хәрби округының 131 нче махсус мотоукчылар бригадасы мотоукчылар ротасы командиры итеп билгеләнә. 1992 елның ноябреннән 1993 елның маена кадәрге чорда капитан Клупов үз часте составында Осетин-Ингуш коралы бәрелешен туктатуда катнаша. 1994 елдан башлап Чечня Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы операциядә (беренче хәрби кампания) катнаша. Күп тапкырлар бандформированиеләр белән бәрелешләрдә батырлыклар күрсәтә.

1994 елның 31 декабрендә Россия гаскәрләре Грозныйга кергәндә, баш поход заставасын җитәкләп, капитан Клупов мотоукчылар бригадасының тимер юл вокзалына таба хәрәкәтен тәэмин итә. Аның подразделениесе җитез генә ыргылыш ясап, Нефтянка елгасы аша салынган күперне ала һәм бригаданың Грозный уртасына барып чыгуын тәэмин итә. Баштарак эшләре ярыйсы гына уңышлы бара. Вокзалга килеп җитәрәк сигез кешелек боевиклар төркемен, ә вокзал тирәсендәге урыннарга разведка ясаганда, егерме дудаевчыдан торган тагын ике төркемне юк итү насыйб була.

Боевиклар шулкадәр көчле каршылык күрсәтер дип федералларның берсе дә көтмәгән була. Әйбәт коралланган һәм өйрәтелгән бандформированиеләр, алдан ук әзерләп куелган позицияләренә ныклап урнашып, федераль гаскәрләргә еш һөҗүм итәләр.

31 декабрь кичендә капитан Клупов 1 нче мотоукчылар батальонын җитәкләргә диган боерык ала (аның командиры яраланган була). Чолганышта килеш рәхимсез сугыш барышында ул түгәрәк оборона оештыра, контузия ала, ләкин стройда кала. Боевиклар кысрыклап килгән бригада личный составын һәм сугышчан техникасын күп югалта. Каплау төркеме белән бергә Рөстәм товар станциясе районына бәреп чыга. Анда Самарадан килгән 81 нче мотоукчылар полкының таркалган төркемнәре оборона тота. Ул төркемнәрнең барысын да үз командалыгына җыеп, капитан икенче мәртәбә аларны камалышны өзәргә җибәрә, ә үзе ике сугышчы белән чигенүне капларга кала. 1995 елның 2 гыйнварына каршы төндә, бурычны үтәп, үз частьлары урнашкан җиргә килеп чыга.

Грозный уртасында тозакка эләккән мотоукчылар частьлары оборона тота. Вәзгыятьне белгән капитан Клуповка тагын сугышучы солдатларны капкыннан алып чыгарга боерык бирелә. Аеруча авыр сугышлар зонасына әйләнеп килгәч, Рөстәм 131 нче мотоукчылар бригадасы һәм 81 нче мотоукчылар полкы сугышчыларыннан төркем оештырып, калган техника белән сугыша-сугыша боевиклар киртәсен ерып, төркемне камалыштан алып чыга. Шул чакта үзе яралана, шуның аркасында Ростов-Дон хәрби госпитальенә җибәрелә.

1994 елның 31 декабреннән алып 1995 елның 2 гыйнварына кадәр Чечня территориясендәге авыр һәм канкойгыч сугышларда үз подразделениесе көче белән Рөстәм Клупов өч танк, берничә орудие, ике БТР, 12 ут ноктасы һәм 60ка якын боевикны юк итә, шул исәптән шәхсән үзе бер танкны, биш ут ноктасын һәм 9 боевикны сафтан чыгара.

1995 елда Рөстәм Макс улын Төньяк Кавказ хәрби округының 131 нче махсус мотоукчылар бригадасына разведка начальнигы итеп билгелиләр. Ә 1996 елның февраленнән 131 Майкоп бригадасы подразделениеләре – Чечнядагы Федераль гаскәрләрнең берләшкән командованиесе маневр группасы составында кабат сугыш хәрәкәтләре зонасында бригаданың разведкасына җитәкчелек итеп, Клупов разведка ясаучы дозорларның берсенә шәхсән үзе командалык итә. Даими рәвештә боевиклар бандалары кулындагы территориядә хәрәкәт итеп, майор Клупов җитәкчелегендәге разведка подразделениеләре шактый операцияләр һәм махсус чаралар үткәрә. Аларның аеруча әһәмиятлеләре:

- чит ил наемникларының «Горец» позывнойлы бик зур халыкара бандасын тар-мар итү һәм аның күп әгъзаларын юкка чыгару (бу Ножай-Юрт районындагы сепаратистлар төркемен тар-мар итәргә булыша);

– уничтожение большого склада (перевалочного схрона) с материально-техническим имуществом на границе с Грузией;

– вскрытие оборонительных рубежей в укрепленных районах Гойское, Старый Ачхой, Бамут.

В итоге за 1996 год разведкой бригады было захвачено восемь «языков», проведено большое количество успешных засад и налетов, в которых разведчики уничтожили несколько автомобилей противника, захватили танк и БМП, уничтожили большое количество боевиков, в том числе много наемников из Афганистана и арабских стран. При этом потери разведподразделений бригады до перемирия в сентябре 1996 года составили 16 раненых солдат и офицеров.

За проявленное мужество и героизм при выполнении специального задания указом Президента РФ от 12 сентября 1996 года майору Клупову Рустему Максовичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

В 2000 году Рустем Максович окончил 2-й факультет (факультет родов войск и специальных войск) Общевойсковой академии Вооруженных Сил РФ и продолжил службу на Северном Кавказе. В этот период он участвовал в миротворческих операциях по поддержанию мира на территории Абхазии и Южной Осетии.

Не обошла Клупова стороной и вторая чеченская война. Будучи заместителем начальника разведки 58-й армии, он лично руководил проведением нескольких самостоятельных разведывательно-боевых операций против боевиков на чеченско-грузинской границе и в юго-западной части Чечни.

С 2002 по 2003 год Рустем Максович служил в Воронеже начальником разведки 20-й гвардейской общевойсковой армии, а с 2003 года – заместителем начальника разведки штаба Московского военного округа.

В 2006 году он окончил Академию Генштаба и был назначен на должность начальника кафедры Общевойсковой академии ВС РФ. С середины 2007-го по май 2009 года он начальник службы разведки Главного штаба Сухопутных войск. В августе 2008 года участвовал в операции российских войск по принуждению Грузии к миру на территории Южной Осетии.

В период с 2009-го по 2011 год работал советником-консультантом по оперативно-стратегической разведке Вооруженных сил Алжира.

В настоящее время Рустем Максович Клупов живет в Москве.

– Ведено авылы өстендәге биеклекләрне кыю һәм котмәгәндә басып алу;

– Грузия белән чиктә матди-техник мөлкәтле зур склады юк иту;

– яхшы ныгытылган Гойское, Иске Ачхой, Бамут районнарында саклану чикләрен ачу.

Нәтиҗәдә 1996 ел эчендә бригада разведкасы сигез «тел» ала, күп санлы уңышлы засадалар һәм һөҗүмнәр оештыра. Бу вакытта разведчиклар дошманның берничә автомобилен юк итә, танк һәм БМПны үзләренә ала, күп боевикларны, шул исәптән Әфганстаннан һәм гарәп илләреннән килгән наемникларны да үтерә. Ә бригаданың разведка подразделениеләрендә 1996 елның сентябрендәге солыхка кадәр югалтулары – 16 яралы солдат һәм офицерлар.

Махсус заданиене үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1996 елның 12 сентябрендәге Указы нигезендә майор Клупов Рөстәм Макс улына Россия Федерациясе Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

2000 елда Рөстәм Макс улы РФ Кораллы Көчләренең Гомуми гаскәрләр академиясе 2 нче факультетын (гаскәрләр төрләре һәм махсус гаскәрләр факультеты) тәмамлый һәм хезмәтен Төньяк Кавказда дәвам иттерә. Бу чорда ул Абхазия һәм Төньяк Осетия территорияләрендә тынычлык саклау буенча операцияләрдә катнаша.

Клуповны икенче чечен сугышы да читләтеп үтми. 58 нче армиянең разведка начальнигы урынбасары булarak, чечен-грузин чигендә һәм Чечняның көньяк-көнчыгыш өлешендә боевикларга каршы берничә мөстәкыйль разведка-тикшеру операциясенә шәхсән үзе җитәкчелек итә.

2002 елдан 2003 елга кадәр Рөстәм Макс улы Воронежда 20 нче гвардия гомуми гаскәрләр армиясендә разведка начальнигы, ә 2003 елдан Мәскәү хәрби округы штабының разведка начальнигы урынбасары булып хезмәт итә.

2006 елда ул Генштаб академиясен тәмамлый һәм РФ Эчке көчләр Гомуми гаскәрләр академиясе кафедрасы начальнигы вазыйфасына билгеләнә. 2007 ел уртасыннан алып 2009 елның маена кадәр ул – Коры җир гаскәрләренең Баш штабы разведка хезмәте начальнигы. 2008 елның августында Көньяк Осетия территориясендә Грузияне солыхка мәҗбүр итү буенча Россия гаскәрләре операциясендә катнаша.

2009 елдан 2011 елга кадәрге чорда Алжир Кораллы көчләрендә оператив-стратегик разведка буенча киңәшче-консультант булып эшли.

Хәзерге вакытта Рөстәм Макс улы Клупов Мәскәүдә яши.







# КОЗИН Алексей Владимирович

Очерк о нем написан при непосредственном участии его мамы Ларисы Александровны и его преподавателя по училищу полковника Уткина Василия Евгеньевича.

...Двадцать лет уже как нет Советского Союза, а боль, страдания, горечь в сердцах миллионов простых людей, вызванные его развалом-распадом, до сих пор дают о себе знать. В силу многих причин, исследовать которые будет еще не одно поколение историков, распалась великая держава, и с ее распадом прокатилась волна этнических конфликтов – карабахский, осетино-ингушский, грузино-осетинский, грузино-абхазский... С 1994 года началось наведение федеральной властью конституционного порядка в мятежной Чечне, где к власти пришли сепаратисты.

Две чеченские войны пополнили ряды ветеранов боевых действий, состоявших из «афганцев», уже «чеченцами». Между этими войнами – афганской и чеченскими – много общего: моджахеды, их финансирование арабскими ваххабитами, горный и партизанский характер войн, торговля оружием и наркотиками... В чеченских дополнительно замешены бизнес на нефти, массовое похищение и торговля людьми.

Наш рассказ – о молодом парне, погибшем в далеком Дагестане...

Аның турында очерк әнисе Лариса Александровна һәм училищедагы укытучысы полковник Уткин Василий Евгеньевич катнашында язылды.

...Советлар Союзы беткәнгә инде егерме ел, шулай да аның таркалуына бәйле сызланулар, газаплар миллионлаган гади кешеләрнең йөрәкләрендә һаман да үзен сиздерер тора. Бөек держава күп төрле сәбәпләр аркасында җимерелде (ул сәбәпләрне әллә ничә буын тарихчылары тикшерер әле). Җимерелү белән этник конфликтлар дулкыны башланып китте: карабах, осетин-ингуш, грузин-осетин, грузин-абхаз... 1994 елдан федераль хакимиятләр тарафыннан властька сепаратистлар килгән Чечняда конституциячел тәртип урнаштыру башланды.

Ике чечен сугышы «әфганчы»лардан торган сугыш ветераннары рәтен «чечен»нар белән тулыландырды. Бу ике – әфган һәм чечен сугышлары арасында уртаклыклар күп: мөҗәһитләр, аларны гарәп ваһһабчылары финанслау, сугышларның тауларда һәм партизанлы булуы, корал һәм наркотиклар белән сәүдә итү өчен чечен сугышларында нефть бизнесы, кешеләрне урлау һәм сату да бар әле.

Хикәябез ерак Дагстанда һәлак булган яшь егет турында...

Гаиләдә ул бик көтеп алынган бала була. Алланың рәхмәте белән бик авыр туган һәм шуның аркасында чир-



Ребенок в семье был долгожданный, выстраданный. Бог сжалился над родителями, и сын, трудно родившийся и слабый оттого, благодаря врачам ГИДУВа выжил.

Родился Алеша 28 мая 1976 года в Казани. С первого его крика мама посвятила ему всю себя. Едва начал ходить и говорить, научила его читать. Малыш не пропускал ни одной сказки, а когда подрос и стал подростком, увлекся документалистикой Андре Моруа, философскими трактатами и наконец военно-мемуарной литературой. Алексея преимущественно интересовали почему-то книги и фильмы про военных.

Впрочем, объяснить это можно тем, что защитниками Родины были дед Алексея по матери, Иван Трофимович, который дрался с японцами за Порт-Артур, участвовал в Первой мировой и Гражданской войнах и даже в белофинской. Другой дед, по отцу, Александр Захарович, прошел всю Великую Отечественную войну, вернулся с фронта в звании старшего лейтенанта с боевыми орденами и медалями.

В семейном архиве, бережно хранимом Ларисой Александровной, есть сочинение второклассника Алеши Козина. Учительница раздала ребятам адреса солдат-срочников и попросила их написать им поздравления по случаю Дня Советской Армии и Военно-Морского Флота. Вот строки этого незатейливого, но искреннего мальчишечьего поздравления:

«Здравствуй, мой старший друг-солдат! Я поздравляю тебя с Днем Советской Армии и Военно-Морского Флота. Желаю тебе хорошей службы. Кто ты – летчик, танкист или просто солдат? Это не столь важно. Важно, что ты защитник нашей Родины – большой страны. Пишет тебе Алеша Козин, ученик 2-го класса школы № 7 Казани. Дорогой друг, я буду ждать от тебя ответа».

...ле булган бала, ГИДУВ табиблары тырышлыгы аркасында гына исән калган.

Алеша 1976 елның 28 маенда Казанда туа. Беренче тавыш биргән мизгеленнән үк әнисе аңа үзен тулысынча багышлый. Йөри һәм сөйләшә генә башлаганда ук аны укырга өйрәтә. Сабый бер генә әкиятне дә калдырмыйча укып бара. Яшүсмер булып җитешкәч, Андре Моруа документалистикасы, фәлсәфи трактатлар һәм хәрби мемуарлар белән мавыгып китә. Хәрбиләр турындагы китаплар һәм фильмнарга Алексей аеруча өстенлек бирә.

Хәер, моны шуның белән аңлатып буладыр: Алексейның әнисе ягыннан бабасы Иван Трофимович, японнар белән Порт-Артур шәһәре өчен сугышкан, Беренче Бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында һәм хәтта акфиннарга каршы сугышта да катнашкан. Икенче бабасы, әтисе ягыннан – Александр Захарович Бөек Ватан сугышын башыннан ахырына кадәр узган, фронттан өлкән лейтенант булып, сугышчан орденнар һәм медальләр алып кайткан.

Лариса Александровна кадерләп саклаган гаилә архивында икенче сыйныф укучысы Алеша Козинның иншасы бар. Укытучы апалары балаларга армиядә хезмәт итүче солдатларның адресларын бирә һәм Совет Армиясе һәм Хәрби-диңгез флоты көне уңаеннан аларга котлау язарга куша. Гади генә, ләкин ихластан язылган котлауда мәнә шундый юллар бар:

«Исәнме, өлкән дустым-солдат! Мин сине Совет Армиясе һәм Хәрби-диңгез флоты көне белән котлыйм. Синең яхшы хезмәт итүеңне телим. Кем син – очучымы, танкистмы, гади солдатмы? Бу ул кадәр үк мөһим түгел. Безнең Ватаныбызның – зур илебезнең яклаучысы булуың мөһим. Сиңа хатны Казанның 7 нче мәктәбе 2 нче сыйныф укучысы Алеша Козин яза. Кадерле дустым, мин синнән җавап көтәм».



Алеше было десять лет, когда родители развелись. Он как мог переживал за маму, но лишь с возрастом понял во всей полноте, как нелегко пришлось матери, пока он прочно не встал на ноги. После девятого класса юноша поступил в авиационный техникум. Мама, окончившая в свое время Казанский авиационный институт, не могла нарадоваться тому, что сын пошел по ее стопам и свяжет свою судьбу с инженерной профессией. Но по окончании техникума в 1994 году Алексей объявил матери, что твердо решил стать военным, и подал заявление в Казанское высшее танковое командное училище.

Учился он хорошо. У Алексея было много увлечений: книги, спорт, музыка. Много времени проводил в спортзале, стал кандидатом в мастера спорта по рукопашному бою. По характеру Козин был лидером: энергичным, трудолюбивым. К его мнению прислушивались многие сослуживцы. Как одному из активных курсантов ему присвоили звание сержанта и назначили заместителем командира взвода.

В день выпуска из училища Лариса Александровна чувствовала себя самой счастливой мамой на свете. Сын – высокий, стройный, широкоплечий офицер-красавец. Она приучила его не пасовать перед трудностями, помогала закалять волю, воспитывала в нем трудолюбие, чувство ответственности за слова и поступки. Надев офицерские погоны, Алексей дал себе слово, что у матери не будет причин краснеть за него.

О лейтенанте Козине рассказывает его однокашник по училищу Павел Харитонов: « Алексей не пил, не курил, был романтиком. Характер имел твердый, уровновешенный. Техникой владел уверенно, изучал танк с увлечением. На него всегда можно было положиться. Если даст обещание – обязательно выполнит».

Была возможность у Алексея остаться в Казани, но он наотрез отказался от нее, сказал, что свою дорогу настоящий мужчина выбирает сам. И выбрал, подав вместе с группой сослуживцев рапорт о назначении его во Внутренние войска МВД, в Северо-Кавказский округ.

В пути следования к месту назначения в поезде говорили о предстоящей службе, прикидывали, кто с кем хотел вместе служить в одной роте. А потом Алексей пел под гитару полюбившиеся друзьям песни.

Встретили молодых офицеров командир полка полковник Владимир Докторевич и командир роты Эдуард Панев. Последний тоже окончил Казанское танковое, так что в коллективе сразу же сложились нормальные рабочие отношения.

Командир роты расставил танки по заставам. Утром 5 сентября подразделение под командованием лейтенанта Козина ушло на боевое задание в Новолакском районе. Во время выдвижения у села Дучи колонна была обстреляна боевиками и приняла бой.

Танк капитана Панева занял оборону в сотне метров от населенного пункта и открыл огонь по местам скопления боевиков. Козин объехал Новолакское с другой стороны и тоже открыл огонь. Боевиков было гораздо больше, чем предполагалось. Вскоре танк Панева был подбит, а его экипаж пополнил число раненых. В этой ситуации надежда была только на Козина.



Алешага 10 яшь вакытта әти-әнисе аерылыша. Ул әнисе өчен бик борчыла, ләкин үсә төшкәч кенә, аны аякка бастыруның әнисенә ничек авыр булганлыгын тулысынча аңлый. Тугызынчы сыйныфтан соң яшүсмер авиация техникумына укырга керә. Үзе дә кайчандыр Казан авиация институтын тәмамлаган әнисе улының аның эзеннән китүенә һәм язмышын инженер һөнәре белән бәйләвенә сөенеп туя алмый. Ләкин 1994 елда техникумны тәмамлагач, Алексей хәрби кеше булырга карар итүе турында әйтә, һәм Казан югары танк команда училищесына гариза бирә.

Ул яхшы укый. Алексейның мавыгулары күп була: китаплар, спорт, музыка. Күп вакытын спортзалда үткәрә, кул сугышы буенча спорт мастерлыгына кандидат була. Энергияле, хезмәт сөючән Козинда әйдәман холкы була. Аның фикеренә күп иптәшләре колак сала. Актив курсантларның берсе буларак, аңа сержант званиесе бирел, взвод командиры урынбасары итеп билгеләп куялар.

Алексей училищены тәмамлаган көнне Лариса Александровна үзен дөньядагы иң бәхетле ана итеп хис итә. Улы – чибәр, озын буйлы, зифа гәүдәле, киң җилкәле офицер. Ул аны авырлыклар алдында каушап калмаска, ихтыяр көчен чыныктырырга өйрәткән, аңарда хезмәт сөючәнлек, үз сүзләре һәм гамәлләре өчен җаваплылык хисе тәрбияләгән иде бит. Офицер погоннары таккач, Алексей үз-үзенә әнисе йөзенә кызыллык китермәскә сүз бирә.

Лейтенант Козин турында училищеда бергә укыган иптәше Павел Харитонов сөйли: «Алексей аракы эчмәде, тәмәке тартмады, романтик иде. Холкы нык, тотрыклы. Техниканы яхшы белә, танкны бик тырышып өйрәнде. Аңа һәрвакыт таянырга мөмкин иде. Вәгъдә бирдеме – һичшиксез үтәде».

Алексейның Казанда калу мөмкинлеге дә була, ләкин ул аннан кискен рәвештә баш тарта, чын ир кеше үз юлын үзе сайлый, дип әйтә. һәм сайлый да: бер төркем хезмәттәшләре белән бергә Төньяк Кавказ округына ЭЭМ Эчке гаскәрләренә билгеләүләрен сорап рапорт яза.



Умело используя складки местности, меняя огневые позиции, экипаж Т-72 наносил ощутимый урон противнику. Огнем пушки наводчик орудия рядовой Сергей Герасимов и заряжающий рядовой Константин Герасименко уничтожили группу боевиков, укрывавшихся в лесном массиве. В сторону машины Козина летели РПГешные гранаты, но экипажу удавалось спасти машину от прямых попаданий. И только когда боевики произвели пуск противотанковой управляемой ракеты (ПТУР), танк Козина содрогнулся от прямого попадания. По словам механика-водителя танка рядового Александра Калугина, ракета попала в башню. В это время Герасименко вел огонь из зенитного пулемета, взрывной волной ему обожгло лицо, Сергей Герасимов был ранен в обе ноги. Козин остался невредим.

Он приказал экипажу покинуть горящий танк. Взяв автомат, Алексей велел раненным солдатам отходить, а рядового Калугина отправил доложить о ситуации. Сам же остался прикрывать отход своих подчиненных. Когда закончились патроны, он взобрался на башню и открыл огонь из зенитного пулемета, давая возможность подоспевшим солдатам эвакуировать на БТРе раненых.

Из-за шквального огня боевиков подобраться к горящему танку бойцы не смогли. Однополчане лишь слышали, что стрельба зенитного пулемета прекратилась только тогда, когда то ли от огня, то ли от очередного попадания гранаты под броней стали рваться снаряды...

В течение пяти дней бандиты снайперским огнем срывали все попытки российских бойцов вынести лейтенанта с поля боя. Тело погибшего офицера-танкиста отыскали

Билгеләнгән урынына барганда, поездда киләчәк хезмәтләре турында фаразлыйлар, кемнең кем белән бер ротада хезмәт итәргә теләвен сөйләшәләр. Аннары Алексей иптәшләренә гитарада уйнап җырлар җырлый.

Яшь офицерларны полк командиры полковник Владимир Докторевич һәм рота командиры Эдуард Панев каршы ала. Рота командиры үзе дә Казан танк училищесын тәмамлаган, шуңа күрә коллективта баштан ук яхшы мөнәсәбәтләр урнаша.

Рота командиры танкларны заставаларга бүлә. 5 сентябрь иртәсендә лейтенант Козин командалыгындагы подразделение Новолак районына сугышчан заданиегә китә. Юлда барганда Дучи авылы янында колоннага боевиклар ут ача.

Капитан Панев танкы авылдан йөз метрлар читтәрәк оборонага урнаша. Боевиклар тупланган урыннарга төбәп ут ача. Козин Новолакны икенче яктан әйләнеп уза һәм шулай ук ата башлый. Боевиклар алар уйлаганга караганда күбрәк булып чыга. Озакламый Панев танкы сафтан чыгарыла, ә аның экипажы яралылар санын тулыландыра. Бу вәзгыятьтә өмет бары тик Козинда гына була.

Җирлектәге сырларны белеп файдаланып, ут позицияләрен алыштыра-алыштыра, «Т-72» экипажы дошманны шактый зур югалтуларга дучар итә. Пушка уты белән орудие төзәүчесе рядовой Сергей Герасимов һәм коручы рядовой Константин Герасименко урман эченә яшеренгән боевиклар төркемен юк итә. Козин машинасы ягына таба РПГ гранаталары оча, ләкин экипаж машинаны турыдан-туры тиюләрдән саклап кала ала. Боевиклар танкка каршы



после освобождения Новолака. Он лежал в траве неподалеку от места последнего боя. Рядом стоял его подбитый танк, склонив ствол пушки до земли, будто отдавая последние почести своему командиру. Танк отважного экипажа, как определили специалисты, восстановлению не подлежал.

«Герой России из Казани», – прощаясь с Алексеем, написали сослуживцы на цинке гроба. Хотя президентского указа еще не было. А потом, 12 ноября 1999 года, указ появился, в нем было сказано: «За мужество и героизм при исполнении воинского долга лейтенанту Козину Алексею Владимировичу присвоить звание Герой Российской Федерации (посмертно)».

...Как драгоценную реликвию хранит Лариса Александровна маленький томик Мусы Джалиля, любимого поэта сына. Она помнит: еще будучи курсантом, он никогда не расставался с этой книжкой в красном переплете. Не забыл положить ее Алексей в полевую сумку и перед своим последним боем.

Между зачитанными страничками со следами от материнских слез – закладка. Стихотворение «Другу»:

Не время меж рождением<br>
и смертью –<br>
Одно определяет<br>
жизни срок.<br>
Быть может, наша кровь,<br>
что здесь прольется,<br>
Прекрасного бессмертия<br>
исток.<br>
Мой друг, ведь наша жизнь –<br>
одна лишь искра<br>
Всей жизни Родины,<br>
страны побед.<br>
Пусть мы погаснем –<br>
от бесстрашной смерти,<br>
В отчизне нашей ярче вспыхнет свет.<br>
И этой смертью<br>
подтвердим мы верность,<br>
О смелости узнает<br>
вся страна.<br>
Не этими ли чувствами<br>
большими,<br>
О друг мой,<br>
наша молодость сильна?!

Часто перечитывает эти строки мама Героя. Чтобы утолить боль невосполнимой утраты. Сердцем постичь смысл героического поступка сына, который погиб рядом с горящим танком, прикрывая огнем боевых товарищей.

17 января 1999 года в кабинете министра внутренних дел Республики Татарстан Асгата Сафарова, в присутствии генералов из штаба округа и из Москвы, ей была вручена «Золотая Звезда» сына.

На городском доме, в школе № 7, в Казанском авиационном техникуме, в танковом училище и в воинской части близ Казачьего лагеря установлены мемориальные доски, открыты уголки и музеи, посвященные подвигу Алексея Козина. Он навечно зачислен в список воинской части.

идарә ителүче ракета (ПТУР) җибәргәч кенә Козинның танкы ракета тиюгә дерелдәп куя. Танкның механик-йөртүчесе рядовой Александр Калугин әйтүенчә, ракета башняга тия. Бу вакытта Герасименко зенит пулеметыннан атып торган була. Шартлау дулкыны аның битен яндыра, ике аягын яралый. Козин әлегә яраланмый кала.

Ул экипажына ут әлгән танктан чыгарга боера. Автоматын кулына алып, Алексей яралы солдатларга чигенергә куша, ә рядовой Калугинны вәзгыять турында хәбәр итәргә җибәрә. Ә үзе солдатларының чигенүен каплап торырга кала. Патроннары беткәч, ул башняга менә һәм зенит пулеметыннан ут ача, килеп өлгергән солдатларга яралыларны БТРга төяп алып китәргә мөмкинлек бирә.

Боевикларның көчле уты аркасында сугышчылар янып торган танк янына килеп җитә алмыйлар. Полкташлары, зенит пулеметының броня астында снарядлар шартлый башлагач кына атудан туктаганлыгын әйтәләр...

Биш көн буена бандитларның снайперлары, бертуктаусыз атып, лейтенантны сугыш кырыннан алып чыгарга ирек бирмиләр. Һәлак булган офицер-танкистның гәүдәсе Новолак азат ителгәннән соң гына эзләп табыла. Ул соңгы сугыш урыныннан ерак түгел генә ята. Янында пушкасының көпшәсен аска игән җимерек танк тора, гүя ул үз командирына соңгы хөрмәтен күрсәтә. Тикшергәннән соң, белгечләр курку белмәс экипаж танкының төзәтеп булмастайлыгын әйтә.

Алексей белән хушлашканда, хезмәттәшләре аның табутына «Россия Герое – Казаннан» дип язып куялар. Әле бу вакытта Президент Указы булмый. 1999 елның 12 ноябрендә чыгарылган Указда: «Хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен лейтенант Козин Алексей Владимировичка Россия Федерациясе Герое исемен бирергә (үлгәннән соң)», – дип язылган.

...Лариса Александровна улының яраткан шагыйре Муса Җәлилнең кечкенә генә томын кадерле истәлек итеп саклый. Курсант вакытында аның кызыл тышлы бу китапны беркайчан да үзеннән калдырмаганлыгын хәтерли ул. Соңгы сугышы алдыннан да Алексей китапны кыр сумкасына салырга онытмаган була.

Әнисе күз яшьләрен түгә-түгә кат-кат укыган битләр арасына тасма кыстырып куелган. «Дуска» дигән шигырьнең юлларын Геройның әнисе еш укый. Кире кайтарып алып булмый торган югалту газабын басу өчен укый ул аны. Сугышчан дусларын ут белән каплап янып торган танк янәшәсендә һәлак булган улының каһарманлык адымы мәгънәсен йөрәге белән аңларга тели.

1999 елның 17 гыйнварында Татарстан Республикасы эчке эшләр министры Әсгать Сафәров кабинетында округ штабыннан һәм Мәскәүдән килгән генераллар катнашында Лариса Александровнага улының «Алтын Йолдыз»ы тапшырыла.

Ул яшәгән йортта, 7 нче мәктәптә, Казан авиация техникумында, танк училищесында һәм Казаклар лагере янындагы хәрби частьта Алексей Козин батырлыгына багышланган мемориаль такталар куелган, почмаклар һәм музейлар ачылган. Ул мәңгелеккә үз хәрби частеның исемлегенә кертелгән.





# КОРАБЛЕВ Алексей Михайлович

Родился 21 марта 1979 года в селе Галактионово Чистопольского района Татарстана. В 1995 году окончил среднюю школу в селе Донауровка и поступил работать слесарем на Чистопольский часовой завод. 19 декабря 1998 года был призван на срочную службу в Вооруженные Силы России.

«Преемственность. Она стала доброй традицией земли чистопольской. От отца к сыну передается боевой дух героев. В годы Великой Отечественной войны тысячи наших парней сложили головы, показывая примеры мужества и отваги. Пятнадцать Героев Советского Союза. Не каждый город может гордиться таким количеством Героев», – писала одна из чистопольских газет.

Но и сегодня не оскудела на батыров Чистопольская земля. В «горячих» точках парни Чистополя честно выполняют свой воинский долг. Одним из таких парней стал Алексей Кораблев.

Уходя в армию, конечно, не думал простой деревенский парень Алеша Кораблев, что его подвиг станет известен всей стране, а он вернется Героем России.

В декабре 1998 года мать его, Капитолина Ивановна, напутствуя сына в дальнюю дорогу, говорила: «Верь в лучшее, опирайся на товарищей». Этому пожеланию парень и старался следовать.

Служить довелось в 160-м гвардейском танковом полку, который дислоцировался в то время в городе Гусиноозерске, что в Бурятии. Служил под началом командира полка гвардии полковника Юрия Буданова.

1979 елның 21 мартында Татарстанның Чистай районы Галактионово авылында туа. 1995 елны Донауровка авылындагы урта мәктәпне тәмамлый һәм Чистай сәгать заводына слесарь булып эшкә урнаша. 1998 елның 19 декабрендә Россиянең Кораллы Көчләренә армия хезмәтенә чакырыла.

«Буыннан-буынга күчүчәнлек. Ул Чистай җирендә яхшы традициягә әйләнде. Геройларның сугышчан рухы атадан улга күчә. Бөек Ватан сугышы елларында меңләгән егетләребез, батырлык һәм куркусызлык үрнәкләре күрсәтеп, башларын салдылар. Унбиш Советлар Союзы Герое. Шулкадәр күп Геройлары белән һәрбер шәһәр мактана алмый әле», – дип яза Чистай газеталарының берсе.

Чистай җирендә хәзер дә батырлар кимемәгән әле. Чистай егетләре «кайнар» нокталарда үзләренең хәрби вазыйфаларын намус белән үтиләр. Шундый егетләрнең берсе – Алексей Кораблев.

Армиягә киткәндә, гап-гади авыл егете Алеша Кораблев, батырлыгы бөтен илгә таралыр, ә үзе Россия Герое булып әйләнеп кайтыр дип уйламаган, әлбәттә.

1998 елның декабрендә, улын ерак юлга озатканда, әнисе Капитолина Ивановна аңа: «Яхшылыкка ышан, иптәшләреңә таян», – дип әйтә. Егет бу теләктән читкә тайпылмаска тырыша.

Бурятиянең Гусиноозерск шәһәрендә урнашкан 160 нчы гвардия танк полкында хезмәт итә ул. Полк командиры гвардия полковнигы Юрий Буданов була.

В октябре в составе своего подразделения Алексей прибыл в Чеченскую Республику для участия в боевых действиях. Принимал участие в многочисленных боевых операциях по взятию Бамута, Шали, Урус-Мартана.

15 января 2000 года разведгруппа полка была отсечена от главных сил и заблокирована на укрепленной боевиками высоте 950,8 в районе села Дуба-Юрт Шалинского района Чечни. Несколько часов 36 бойцов при поддержке артиллерии полка вели неравный бой со 170 боевиками. Кончались патроны, положение становилось критическим. От взвода в живых осталось пять человек. Боевики приблизились вплотную. Все попытки основных сил полка прорваться на помощь были тщетны. Боевики держали под плотным обстрелом единственный подход к высоте. Командир приказал отходить, но путь отхода был один – через отвесный каменный многометровый склон, к которому была прижата группа.

В этой ситуации рядовой Кораблев остался один прикрывать отход товарищей. Пока боевые товарищи отходили, Алексей огнем из пулемета отсекал атаки боевиков. А когда кончились патроны, прыгнул вниз в пропасть, получил сильные ушибы, но уцелел.

Пробираясь к своим, нашел тяжелораненого бойца из своей разведгруппы. Оказал ему первую помощь и в течение суток тащил на себе боевого товарища. Смертельно уставший он принес-таки его в расположение федеральных войск.

За мужество и героизм, проявленные, при проведении контртеррористической операции на территории Северо-Кавказского региона, указом Президента РФ от 28 июня 2000 года гвардии рядовому Кораблеву Алексею Михайловичу присвоено звание Героя России.

Уволился он с воинской службы в 2000 году. Живет в родном Чистополе, занимается общественной работой: он член общественной организации «Герои Татарстана», а также президент общественной организации «Патриот», объединяющей ветеранов афганской и чеченской войн Чистопольского района. Алексей желанный гость в школах города и района.

Десятиклассница Елена Протасова посвятила Алексею чуть ли не поэму. Вот фрагмент ее незамысловатого, но проникновенного стихотворения:

Он проявил себя достойным гражданином,  
И, честь отдав ему, ты голову склони,  
О подвиге его скажи ты сыну,  
Пусть знает сын, кто Родину хранит!  
И я горда, что на родной земле  
Еще есть люди вроде Алексея!  
Пусть наша жизнь становится сложнее,  
Герои, защищая жизнь, порядок сеют!

Октябрьдә үз подразделениесе составында Алексей, сугыш хәрәкәтләрендә катнашу өчен, Чечня Республикасына килеп төшә. Бамут, Шәле, Урус-Мартанны алганда күп кенә хәрби операцияләрдә катнаша.

2000 елның 15 гыйнварында полкның разведка төркеме төп көчләрдән аерыла һәм Чечняның Шәле районы Дуба-Юрт авылы тирәсендәге 950,8 биеклегендә ныгып урнашкан боевиклар чолганышында кала. Полк артиллериясе ярдәме белән 36 сугышчы берничә сәгать буе 170 боевикка каршы тигезсез сугыш алып бара. Патроннар бетә, хәлләре бик авырлаша. Взводның биш кешесе генә исән кала. Боевиклар якынга ук килеп җитә. Полкның төп көчләренең ярдәм итәргә омтылуы файдасыз була. Биеклеккә менә торган бердәнбер юлга боевиклар бертуктаусыз атып торалар. Командир чигенергә боера. Ләкин чигенү юлы бер генә – төркем китереп кысылган асылынып торучы озын таш сөзәклек.

Рядовой Кораблев иптәшләренең чигенүен каплап торыр өчен берүзе кала. Сугышчан иптәшләре чигенгәндә, Алексей пулеметтан атып, боевиклар һөҗүмнәрен кире кайтарып тора. Ә патроннары беткәч, тота да упкынга сикерә, гәүдәсе бик каты авыртса да, исән кала.

Үзенекеләр янына юл тоткач, үз разведка төркеменең авыр яралы сугышчысын табып ала. Аңа беренче ярдәм күрсәтә. Һәм тәүлек буе иптәшен күтәреп алып бара. Үләргә җитәрлек булып арыса да, ул аны федераль гаскәрләр урнашкан җиргә китереп җиткерә.

Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операция уздырганда күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2000 елның 28 июнендәге Указы нигезендә гвардия рядовое Кораблев Алексей Михайловичка Россия Герое исеме бирелә.

Ул хәрби хезмәттән 2000 елда китә. Туган җире Чистайда яши, иҗтимагый эш белән шөгыльләнә: ул – «Татарстан Геройлары» иҗтимагый оешмасы әгъзасы, Чистай районыннан чыккан әфган һәм чечен сугышлары ветераннарын берләштерүче «Патриот» иҗтимагый оешмасының президенты. Алексей – шәһәр һәм район мәктәпләрендә көтеп алынган кунак.

Унынчы сыйныф укучысы Елена Протасова Алексейга багышлап поэма язган. Менә аның күңелгә үтеп керә торган шигыреннән бер өзек:

Он проявил себя достойным гражданином,  
И, честь отдав ему, ты голову склони,  
О подвиге его скажи ты сыну,  
Пусть знает сын, кто Родину хранит!  
И я горда, что на родной земле  
Есть еще люди вроде Алексея!  
Пусть наша жизнь становится сложнее,  
Герои, защищая жизнь, порядок сеют!





# Кузьмин Сергей Викторович

Хотя и родился 3 июня 1955 года в Киеве, однако корни его исходят из земли Татарстана. Здесь жил его отец, здесь он и похоронен.

С 1972 года – в Военно-Морском флоте СССР. В 1977 году окончил Каспийское высшее военно-морское училище им. С.М. Кирова.

Службу проходил на атомных подводных лодках Краснознаменного Северного флота в должностях командира электронавигационной группы БЧ-1 ПЛ «К-387», командира БЧ-1 534-го экипажа, помощника командира подводных лодок «К-517», «К-502», старшего помощника командира ПЛ «К-298». В 1987 году окончил Высшие специальные офицерские классы ВМФ.

В августе 1988 года капитан 2-го ранга Кузьмин получил назначение на должность командира атомной подводной лодки «Б-414». С 18 сентября 1996 года она стала называться «Святой Даниил Московский». Он был первым командиром, который ее строил, принимал участие в ее испытаниях.

Первый самостоятельный выход в море экипаж в полном составе совершил с 28 мая по 2 сентября 1990 года. 31 декаюря 1990 года на корабле был поднят Военно-морской флаг, а в марте 1991 года лодка была включена в состав Краснознаменного Северного флота.

В 1993 году была первая боевая служба этой противолодочной многоцелевой лодки «Б-414». Базировалась она в Веденяеве.

С 15 июля по 12 августа 1994 года под командованием В.С. Кузьмина атомная подводная лодка совместно с подводным крейсером «К-18» (командир капитан 1 ранга Ю.И. Юрченко) совершила групповой арктический поход, посвященный 300-летию Российского флота. Руководил походом контр-адмирал А.А. Берзин.

Когда перед командованием соединения атомоходов встал вопрос, кто же пойдет «под лед», решение по словам контр-адмирала Кузнецова пришло сразу: экипаж капитана 1 ранга Сергея Кузьмина. Коллектив сплаванный, с успехом прошедший не одну автономку. Опыта и мастерства его офицеров, мичманов – другие могут лишь позавидовать. Из тридцати матросов двадцать – контрактники. По сравнению с другими, атомная подводная лодка этого проекта наиболее приспособлена для действий в арктическом бассейне.

Поход на полюс, всплытие на «макушке» Земли и подъем флагов, возвращение на базу стали достойным триумфом российских подводников, отличного экипажа Сергея Кузьмина.

Родина по достоинству оценила работу экипажа «Б-414». Командиру атомохода капитану 1 ранга Сергею Викторовичу Кузьмину было присвоено высокое звание Героя Российской Федерации. Многие члены экипажа были награждены орденами и медалями.

В наградном листе Кузьмина сказано: «При прохождении ПЛ в арктических широтах С. Кузьмин умело и грамот-

1955 елның 3 июнендә Киев шәһәрендә туа. Ләкин Кузьминнар гаиләсенең тарихи тамырлары Татарстан белән тоташкан. Сергей Викторовичның әти-әнисе Балык Бистәсе районында җирләнгән.

1972 елдан башлап Сергей Викторович СССР Хәрби-Диңгез флотында хезмәт итә башлый. 1977 елда ул С.М. Киров исемендәге Каспий югары Хәрби-Диңгез флоты училищесын тәмамлый.

Хәрби хезмәт еллары дәвамында ул Кызыл Байраклы Төньяк флотта БЧ-1 «К-387» электронавигация группасы командиры, 534 нче экипажның БЧ-1 командиры, «К-517», «К-502» су асты көймәләренең командир ярдәмчесе, ПЛ «К-298» су асты көймәсе командирының өлкән ярдәмчесе була.1988 елда Хәрби-Диңгез флотының югары махсус офицерлар классын тәмамлый.

1988 елның августында 2-ранг капитаны Сергей Кузьмин «Б-414» (1996 елның 18 сентябреннән «Изге Даниил Московский») атом су асты көймәсе командиры итеп билгеләнә. Бу көмә Ленинград Адмиралтея берләшмәсендә җитештерелеп, суга 1990 елның 31 августында төшерелә, аны төзүдә һәм сынаулар вакытында Сергей Викторович үзе дә катнаша.

Корабль тулы составта беренче тапкыр диңгезгә 1990 елда чыга. Шушы ук елның 31 декабрендә анда Хәрби-диңгез байрагы күтәрелә һәм ул 1991 елның мартыннан Кызыл Байраклы Төньяк флоты составына кабул ителә. 1993 елда күпмаксатлы «Б-414» су асты көймәсе хәрби бурычларны үтәү өчен кабул ителә.



1994 елның 15 июленнән 12 августка кадәр командиры Сергей Кузьмин булган су асты көймәсе «К-18» су асты крейсеры белән берлектә (командиры 1-ранг капитаны Юрий Юрченко), Россия флотының 300 еллыгына багышлап, арктик походка чыга. Бу походка контр-адмирал Александр Берзин җитәкчелек итә. Сергей Кузьмин экипажы «боз астына» беренче булып төшә. Андагы офицерларның, матросларның, мичманнарның бердәмлеге, кыюлыгы һәм осталыгы күпләрне сокландыра. Әлеге프ект белән эшләгән атом су асты көймәсе арктик бассейнда йөзү өчен аеруча яраклы икәнлеген күрсәтә.

Менә, ниһаять, тантаналы минутлар башлана.

Без Хәрби-диңгез флотының Баш командующие приказын үтәдек. Ул Россия флоты су асты диңгезчеләренең югары профессиональ осталыгын бик ачык раслый. Сездәге батырлык һәм героизм нәтиҗәсендә без планетаның иң югары төньяк полюс ноктасын яуладык, – ди вице-адмирал Анатолий Шевченко сафта горур басып торучы матросларга мөрәҗәгать итеп. һәм ул Россия флотының 300 еллыгы уңаеннан, дәүләт гимнының тантаналы аккордлары астында, илебезнең Дәүләт һәм Хәрби-Диңгез флотының Андреевский флагларын күтәрергә боерык бирә...

Ватаныбыз «Б-414» атом су астыкөймәсе экипажы батырлыгын югары бәяли; 1-ранг капитаны Сергей Викторович Кузьминга Россия Федерациясе Герое дигән югары



но управлял кораблем, ежедневно и ежечасно добиваясь слаженности в действиях экипажа, направленных на безопасность подледного плавания. За время нахождения подо льдами командир в совершенстве отработал действия экипажа для плавания и ведения боевых действий в арктических районах, произвел 14 всплытий в полыньях и разводьях. Подо льдами Арктики было сделано два круга вокруг земной оси.

Экипаж субмарины такого типа 102 человека. Автономность плавания 80 суток. На борту находятся два реактора. Скорость АПЛ в надводном положении 12 узлов, в подводном – 30.

Вооружение – комплекс крылатых ракет РК– 55 «Гранат», а также комплекс минно-торпедного вооружения, включая ракеты-торпеды «Шквал» и «Водопад».

В июне 1995 года С.В. Кузьмин назначен заместителем командира, затем командиром 7-й дивизии атомных подводных лодок Краснознаменного Северного флота. В 1997 году он окончил с отличием Военно-морскую академию имени Н.Г. Кузнецова. В июне 2001 года Сергею Викторовичу присвоено воинское звание контр-адмирал.

С сентября 2002 года он назначается начальником штаба – заместителем командира 11-й эскадры подводных лодок Краснознаменного Северного флота. В июне 2006 года он назначается на должность начальника Управления боевой подготовки Военно-Морского флота Российской Федерации.

В ноябре 2010 года вице-адмирал Сергей Викторович Кузьмин увольняется с военной службы.

исем бирелә. Экипажның күпчелек әгъзалары орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Командование Сергей Викторович Кузьминнныңкыюлык, батырлык, профессиональ осталык кебек сыйфатларын һәм матрослар арасында зур абруй казанган булуын аеруча билгеләп үтә.

1995 елның июнендә С.В. Кузьмин командир урынбасары, аннан соң инде Кызыл Байраклы Төньяк флотның 7 нче атом су асты көймәләре дивизиясе командиры итеп билгеләнә. 1997 елда ул бик яхшы билгеләренә Н.Г. Кузнецов исемендәге Хәрби-диңгез академиясен тәмамлый. 2001 елның июнендә аңа контр-адмирал званиесе бирелә. 2002 елның сентябреннән ул штаб началҗнигы – Кызыл Байраклы Төньяк флоты су асты көймәләренең 11 эскадрасы командиры. 2006 елның июнь аенда ул Россия Федерациясе Хәрби-диңгез флотының  сугышчан хәзерлек Идарәсе начальнигы итеп билгеләнә. 2010 елның ноябрендә вице-адмирал Сергей Викторович Кузьмин хәрби хезмәттән азат ителә.







# КУРБАНГАЛЕЕВ
## Артур Ришатович

Родился 14 декабря 1980 года в Уфе. Детские и юношеские годы провел в городе Усть-Катаве Челябинской области, куда с родителями переехал в 1984 году. Там же окончил среднюю школу № 7.

В Вооруженные Силы РФ его призвали в декабре 1998 года. Служить попал в воздушно-десантные войска.

Когда в августе 1999 года началась антитеррористическая операция на территории Республики Дагестан, а затем в Чеченской Республике так называемая вторая чеченская война, заместитель командира взвода 4-й парашютно-десантной роты 119-го парашютно-десантного гвардейского полка гвардии сержант Артур Курбангалеев в составе своего подразделения принял активное участие в боевых действиях.

В начале сентября через горные перевалы в Дагестан вместе с чеченскими боевиками стали прорываться арабские и другие наемники. У подножья горы Экитебе – на военных картах она обозначена как высота 323,1 – расположились десантники Нарофоминского сводного батальона. На рассвете батальон подвергся из-за гор мощному минометному обстрелу боевиков. Рота, в состав которой входило отделение Артура, пошла на штурм. «Умело командовал отделением, проявил хладнокровие, трезвый расчет... в ходе боя заменил раненного командира взвода»– это строки из письма командования части его родителям.

В тот роковой день 9 сентября 1999 года гвардии сержант Курбангалеев вывел своих солдат из-под обстрела. Но на поле боя оставались раненые десантники. Вернувшись за ними, чтобы вытащить из-под огня, Артур погиб.

1980 елның 14 декабрендә Уфада туа. Балалык һәм үсмерлек елларын 1984 елда әти-әниләре белән бергә күченгән Чиләбе өлкәсе Усть-Катав шәһәрендә үткәрә. Шунда ук 7 нче урта мәктәпне тәмамлый.

РФ Коралды Көчләренә аны 1998 елда чакыралар. Ул һава-десант гаскәрләренә эләгә.

1999 елның августында Дагстан Республикасында террорчылыкка каршы операция, ә аннары Чечня Республикасында икенче чечен сугышы башлангач, 119 нчы парашютчы-десантчылар гвардия полкы 4 нче парашютчы-десантчылар ротасының взвод командиры урынбасары гвардия сержанты Артур Корбангалиев үз подразделениесе составында сугыш хәрәкәтләрендә актив катнаша.

Сентябрь башында тау кичүләре аша Дагстанга чечен боевиклары белән бергә гарәп һәм башка ил наемниклары үтеп керә башлый. Әкитүбә тавы (сугыш карталарында ул 323,1 биеклеге буларак тамгаланган) итәгенә Нарофомин җыелма батальоны десантчылары урнаша. Таң атканда батальонга таулар артыннан боевиклар минометтан ата. Артур отделениесе дә кергән рота штурмга китә. «Отделениесе белән яхшы җитәкчелек итте, салкын канлылык, аек акыл күрсәтте... Сугыш барышында яраланган взвод командирын  алмаштырды».  Бу юллар командованиедә аның әти-әнисенә килгән хаттан.

1999 елның хәтәр 9 сентябрендә гвардия сержанты Корбангалиев үз солдатларын атыш астыннан алып чыга. Ләкин сугыш кырында яралы десантчылар калган була. Аларны алып чыгарга дип әйләнеп килгәч, Артур һәлак була.




Похоронили его с воинскими почестями в городе Усть-Катаве. Указом Президента РФ от 30 декабря 1999 года за мужество, героизм, проявленные при выполнении воинского долга, гвардии сержанту Курбангалееву Артуру Ришатовичу посмертно присвоено звание Героя России.

В память о славном уроженце Башкортостана в Уфе на фасаде дома № 14 по Лесному проезду установлена мемориальная доска, на которую золотыми буквами нанесено имя Героя России Артура Курбангалеева.

И в родной школе не забывают Артура. У входа в нее установлена мемориальная доска, а в школьном музее выставлены фотографии героя и его родителей.

– Ездили мы с мужем в Дагестан,– говорит мама Героя, Зульфия Расуловна Курбангалеева, – там нам показали запечатленные на фото и высотку, и поле с осколками мин, где только на третий год начали, как раньше, сеять пшеницу.

В июне я уже письма от сына перестала получать, а до этого каждую неделю в почтовом ящике весточка была. Стала обзванивать все места, где он служил, сама искала. А в сентябре по телевизору уже вижу: идет война в Дагестане. Почувствовала что-то неладное – сын должен был в августе в отпуск приехать, а его, оказывается, отправили на войну. В начале сентября в ответ на мой звонок на «горячую линию» сообщили: «Ваш сын пропал без вести». А через день из Ростова-на-Дону пришла теллеграма: «Ваш сын погиб».

Он знал куда шел, на проводах так и сказал: «Иду, мама, Родину защищать, тебя защищать». Была у него здесь девушка, фотографию ее носил, сейчас эта фотография у меня, как посмотрю на нее, так плачу.

Думаю, мой сын не зря так поступил. Войны всегда были, а если таких, как Артур, не будет– значит, будем в кабале у завоевателей. Мы, конечно, привыкли к мирной жизни, у каждого свои житейские проблемы, и кажется: какие бандиты, какой враг к нам может прийти? Но это может случиться, и сейчас, мне кажется, не так уж много людей, особенно среди молодежи, которые смогли бы нас защитить, как это сделал мой сын.

Хәрби хөрмәтләр күрсәтеп, аны Усть-Катав шәһәрендә җирлиләр. Хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы, каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1999 елның 30 декабрьдәге Указы нигезендә гвардия сержанты Корбангалиев Артур Ришат улына үлгәннән соң Россия Герое исеме бирелә.

Данлыклы Башкортстан егете истәлегенә Уфада Лесной проезд урамының 14 нче йорты фасадына Россия Герое Артур Корбангалиев исеме Алтын хәрефләр белән язылган мемориаль такта урнаштырылган.

Артурны үзе укыган мәктәптә дә онытмыйлар. Мәктәп ишегә янына мемориаль такта, ә мәктәп музеена Геройның һәм аның әти-әнисенең фотосурәтләре куелган.

– Без ирем белән Дагстанга барган идек, – дип сөйли Геройның әнисе Зөлфия Рәсул кызы Корбангалиева, – анда безгә биеклекнең һәм мина ярчыклары тулган кырның фотосурәтен күрсәттеләр. Ул кырга бары өч елдан соң гына элеккечә бодай чәчә башлаганнар икән.

Июньдә мин улымнан хатлар алмый башладым, ә аңа кадәр атна саен почта әрҗәсендә хат була торган иде. Ул хезмәт иткән бөтен җирләргә шалтыратып, үзем аны эзләргә тотындым. Ә сентябрьдә телевизордан күрәм: Дагстанда сугыш бара. Күңелем борчыла башлады – улым августта отпускыга кайтырга тиеш иде, ә аны сугышка җибәргәннәр икән. Сентябрь башында «кайнар линия»гә шалтыраткач, миңа: «Улыгыз хәбәрсез югалды», – дип әйттеләр. Ә икенче көнне Ростов-Доннан: «Сезнең улыгыз һәлак булды», – дигән телеграмма килде.

Ул үзенең кая барыын белә иде, озатканда шулай дип әйтте дә: «Әни, Ватанны сакларга, сине сакларга барам». Монда аның йөргән кызы бар иде, аның фотосурәтен һәрвакыт үзе белән йөртте. Хәзер ул фото миндә, аңа карагач саен елыйм.

Минем улым юкка гына алай эшләмәгәндер. Сугышлар һаман булып торган, ә Артур кебекләр булмаса, басып алучылар тоткынлыгында калыр идек. Әлбәттә, без тыныч тормышка ияләштек, бернинди бандитлар, дошман да безгә килмәс кебек. Ләкин ул хәл булырга мөмкин. һәм, миңемчә, хәзер яшьләр арасында минем улым кебек безне якларлык кешеләр күп түгел.







# КУСТОВ Сергей Викторович

Родился 11 октября 1971 года в селе Грабово ныне Бессоновского района Пензенской области. По окончании средней школы поступил в Казанское высшее танковое командное училище. В 1992 году молодого лейтенанта-выпускника распределили на службу во Внутренние войска МВД России.

Преподаватели, которые помнят своего курсанта, говорили, что он уже во время учебы мечтал попасть в разведку. И Сергей попал-таки в разведывательную роту оперативного назначения. Общительный характер, знание дела и храбрость выделяли молодого офицера в общей среде, и он быстро завоевал авторитет среди своих сослуживцев.

Как и многие выпускники Казанского танкового училища, Кустов направляется в командировку в Северо-Кавказский военный округ, где он участвует в урегулировании возникшего там осетино-ингушского военного конфликта.

А затем была Чечня, где Сергей провел в общей сложности более года. За отвагу и самоотверженность, проявленные в ходе контртеррористической операции, он был награжден медалью ордена «За заслуги перед Отечеством « 2-й степени.

В январе 2000 года, в перид второй чеченской кампании, в районе села Мескер-Юрт Шалинского района одно из подразделений федеральных войск попало в засаду, и лишь хладнокровие и решительность начальника разведки Кустова спасло многих военнослужащих от неминуемой

1971 елның 11 октябрендә Пенза өлкәсенең хәзерге Бессонов районы Грабово авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан югары танк команда училищесына укырга керә. 1992 елны аны тәмамлаган яшь лейтенантны Россия ЭЭМның Эчке гаскәрләренә хезмәткә билгелиләр.

Курсантларын яхшы хәтерләгән укытучылар, ул укыганда ук инде разведкага эләгергә хыяллана иде, диләр. Сергей, чыннан да, оператив билгеләнештәге разведка ротасына эләгә. Яшь офицер аралашучанлыгы, эш белүе һәм куркусызлыгы белән аерылып тора. Хезмәттәшләре арасында ул тиз абруй казана.

Казан танк училищесын тәмамлаганнарның күбесе кебек үк Кустов Төньяк Кавказ хәрби округына командировкага җибәрелә. Анда ул осетин-ингуш хәрби низагын җайга салуда катнаша.

Аннары Сергейның өч елы Чечняда уза. Террорчылыкка каршы операция барышында күрсәткән батырлыгы һәм фидакарьлеге өчен ул 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнә.

2000 елның гыйнварында, икенче чечен кампаниясе чорында Шәле районының Мескер-Юрт авылы тирәсендә федераль гаскәрләрнең бер подразделениесе засадага эләгә. Бары тик разведка начальнигы Кустовның салкын канлылыгы һәм тәвәккәллеге генә күп хәрби хезмәт-

гибели. Сам он был ранен в ногу, но остался в строю и прдолжал руководить боем. За проявленное мужество боевой офицер вновь был представлен к награде.

В октябре 2001 года контракт майора Кустова с воинской частью подходил к концу. Поскольку он решил продолжить контракт, ему предложили должность заместителя командира Пензенского специального отряда быстрого реагирования (СОБР). Уже в декабре он должен был приступить к выполнению служебных обязанностей на новом месте после очередной командировки в Чеченскую Республику. Это была на редкость напряженная командировка, в ходе которой Сергей организовал восемь засад и тринадцать разведывательных и оперативно-поисковых мероприятий. Его подразделением было уничтожено 19 вооруженных боевиков, захвачено 17 единиц автоматического оружия, карабин, 4 пистолета, 8 гранатометов, большое количество боеприпасов и взрывчатых веществ.

В ночь с 22 на 23 ноября 2001 года группа майора Кустова совместно с сотрудниками временного отдела внутренних дел Шалинского района проводила проверку в населенном пункте Автуры. По данным разведки, в этом селе были замечены боевики. Сведения оказались достоверными. Заметив сотрудников внутренних дел, боевики приготовились к вооруженному сопротивлению. Однако благодаря решительным действиям российских бойцов большая часть боевиков была уничтожена, остальные сумели скрыться. В ходе операции майор лично взял в плен несколько боевиков.

Покончив с бандитами, группа отправилась на свою базу, но на окраине села Шали попала в засаду. В ходе боя майор Кустов получил тяжелое ранение, но продолжал руководить боем до прихода подкрепления. Ранение оказалось смертельным.

Похоронили Сергея Кустова в родном селе Грабово Бессоновского района Пензенской области. За мужество и отвагу, проявленные при исполнении воинского долга в условиях, сопряженных с риском для жизни, майор Кустов посмертно был представлен к званию Героя России. Однако в связи с реорганизацией воинской части, где он служил, и тем обстоятельством, что его документы уже были переданы на перевод в СОБР, представление не дошло до нужного адреса. Лишь спустя 11 лет его подвиг был по достоинству оценен. Указом Президента РФ от 12 июля 2012 года майору Кустову Сергею Викторовичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).

Память о Сергее Кустове свято чтут его боевые друзья, родные и близкие. В школе, которую окончил Сергей, установлена мемориальная доска. Среди старшеклассников проводятся спортивные соревнования на кубок Героя России Сергея Кустова, учрежденный районной администрацией.

кәрләрне үлемнән коткарып кала. Үзенең аягы яралана. Ләкин ул, стройда калып, сугыш белән җитәкчелек итә. Хәрби офицер батырлык күрсәткәне өчен кабат бүләккәргә тәкъдим ителә.

2001 елның октябрендә майор Кустовның хәрби часть белән контракты ахырына якынлаша. Ул контрактын озынайтырга карар иткәч, Пензаның тиз хәрәкәтләнүче махсус отрядына (СОБР) командир урынбасары вазыйфасын тәкъдим итәләр. Чечня Республикасына командировкага барып кайткач, декабрь аенда ул инде яңа урынында хезмәт вазыйфаларына керешергә тиеш була. Бу бик киеренке командировка булып чыга, аның барышында 8 засада һәм 13 разведка һәм оператив тикшерү чаралары оештыра. Аның подразделениесе коралы 19 боевикны юк итә, 17 автомат, карабин, 4 пистолет, 8 гранатомет, күп боеприпаслар һәм шартлаткыч матдәләр кулга төшерә.

2001 елның 23 ноябренә каршы төндә майор Кустов төркеме Шәле районы эчке эшләр вакытлы бүлеге хезмәткәрләре белән берлектә Автуры авылында тикшерү эшләре башкара. Разведка мәгълүматларына караганда, бу авылда боевиклар күренгәләгән була. Мәгълүматлар дөрес булып чыга. Эчке эшләр хезмәткәрләрен күргәч, боевиклар коралы каршылык күрсәтергә җыена. Ләкин Россия сугышчыларының тәвәккәл гамәлләре аркасында, боевикларның күп өлеше үтерелә, калганнары качып котыла. Операция барышында майор берничә боевикны шәхсән үзе әсирлеккә ала.

Бандитлар белән эшне бетергәч, төркем үз базасына таба юнәлә. Ләкин Шәле авылы читендә засадага очрый. Сугыш барышында майор Кустов авыр яралана, ләкин ярдәм килеп җиткәнче сугышка җитәкчелек итүеннән туктамый. Аның ярасы үлем ярасы булып чыга.

Сергей Кустовны туган ягында – Пенза өлкәсенең Бессонов районының Грабово авылында җирлиләр. Гомеренә куркыныч янаган шартларда хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы өчен майор Кустов, үлгәннән соң, Россия Герое исеменә тәкъдим ителә. Ләкин ул хезмәт иткән хәрби частьны үзгәртеп оештыралар. Шул сәбәпле аның документлары инде СОБРга күчерү өчен тапшырылган була, һәм тәкъдим тиешле адресына барып җитми. Унбер ел узгач кына аның батырлыгы лаеклы бәяләнә. РФ Президентының 2012 елның 12 июлендәге Указы нигезендә майор Кустов Сергей Викторовичка Россия Герое исеме бирелә (үлгәннән соң).

Сергей Кустов турындагы истәлекне аның сугышчан дуслары изге итеп саклый. Сергей тәмамлаган мәктәптә мемориаль такта урнаштырыла. Югары сыйныф укучылары арасында Россия Герое Сергей Кустов кубогына ярышлар уздырыла. Кубокны район хакимияте гамәлгә куйган.







# МАКАРОВ Вадим Вильевич

Родился 27 августа 1976 года в Самарканде Узбекистана. По окончании Казанского суворовского военного училища поступил в Ульяновское гвардейское высшее танковое командное училище. Окончив его, проходил службу а частях ГСВГ – Группы советских войск в Германии. Командовал танковыми подразделениями в Северо-Кавказском и Ленинградском военных округах. Ратная судьба забрасывала его в Афганистан, где он участвовал в боевых действиях. Позже пришлось заниматься примирением конфликта в Нагорном Карабахе.

Особая страница биографии офицера – участие в чеченских событиях. В боях первой чеченской войны 1994-1996 годов капитан Макаров участвовал в должности командира 83-го отдельного танкового батальона с 20 апреля по 23 мая 1996 года. Его подразделение постоянно участвовало в рейдовых операциях совместно с частями армейского спецназа и ВДВ практически по всей территории Чечни. Батальон получил в Чечне прозвище «Черное крыло». Он вел бои в районах населенных пунктов Гойское, Орехово, Бамут. Макаров лично находился на самых опасных участках, четко управлял огнем. Проявлял мужество и отвагу в боях. О мастерстве его управления говорит тот факт, что за весь период боевых действий он не потерял ни одного танка и ни одного танкиста. В условиях тяжелых потерь российской бронетехники в Чечне в первой войне этот факт является весьма незаурядным. За месяц боев батальон капитана Макарова уничтожил 5 дотов, 3 склада с боеприпасами, подземную казарму боевиков, захватил пулемет ДКШ и 3 станковых гранатомета. На боевом счету комбата – один уничтоженный бронетранспортер дудаев-

1976 елның 27 августында Үзбәкстанның Сәмәрканд шәһәрендә туа. Казан Суворов исемендәге хәрби училищены тәмамлагач, ул Ульян гвардия югары танк команда училищесына укырга керә. Аны тәмамлагач, ГСВГ (совет гаскәрләренең Германиядәге төркеме) частьларында хезмәт итә. Төньяк Кавказ һәм Ленинград хәрби округларында танк подразделениеләре белән командалык итә. Хәрби язмышы аны Әфганстанга да илтеп ташлый. Анда ул сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Соңрак Таулы Карабахтагы низагны җайларга туры килә.

Чечен вакыйгаларында катнашуы – офицер биографиясенең үзенчәлекле бер бите. 1994–1996 еллардагы беренче чечен сугышы вакытында капитан Макаров 83 нче махсус танк батальоны командиры вазыйфасында була. Аның подразделениесе һәрвакыт бөтен Чечня территориясендә диярлек һава–десант гаскәрләре һәм армия спецназы частьлары белән берлектә рейд операцияләрендә катнаша. Чечняда батальонга «Кара канат» дигән кушамат тагыла. Алар Гойское, Орехово, Бамут авыллары тирәсендә сугышлар алып баралар. Макаров иң куркыныч участокларда ут белән шәхсән үзе идарә итә. Сугышларда батырлыклар күрсәтә. Сугыш хәрәкәтләренең буеннан-буена бер генә танкны да, бер генә танкистны да югалтмавы аның идарә итү осталыгы турында сөйли. Чечняда Россия бронетехникасы авыр югалтуларга дучар булган шартларда бу факт гадәттән тыш була. Бер ай сугышканда, капитан Макаров батальоны 5 дот, 3 боеприпас склады, боевикларның җир асты казармасын юк итә, ДКШ пулеметын һәм 3 станоклы гранатометны кулга төшерә. Комбатның сугыш-



цев. В одном из боев он получил осколочное ранение, но остался в строю до окончания операции.

За мужество и героизм, проявленные при выполнении специального задания, указом Президента РФ от 14 июня 1997 года капитану Макарову Вадиму Вильевичу присвоено звание Героя России с вручением медали «Золотая Звезда».

Вадим Вильевич продолжил службу в армии. С 1997 года служил в частях Воздушно-десантных войск в Ульяновске. В 2001 году окончил Общевойсковую академию Вооруженных Сил. Служил в Генеральном штабе Вооруженных Сил Российской Федерации.

Сегодня генерал-майор Макаров В.В.– успешный ученый, доктор философских наук, профессор, академик Академии безопасности, обороны и правопорядка.

чан исәбендә – дудаевчыларның юкка чыгарылган бер бронетранспортеры. Сугышларның берсендә ул ярчыклар белән яралана, ләкин операция беткәнчегә кадәр стройда кала.

Махсус задание үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1997 елның 14 июлендәге Указы нигезендә капитан Макаров Вадим Вильевичка Россия Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Вадим Вильевич армиядә хезмәтен дәвам иттерә. 1997 елдан Ульяновскидагы һава-десант гаскәрләре частьларында хезмәт итә. 2001 елда Кораллы Көчләрнең Гомумгаскәрләр академиясен тәмамлый. Россия Федерациясенең Кораллы Көчләре Генераль штабында хезмәт итә.

Генерал-майор Макаров В.В. – бүген танылган галим, фәлсәфи фәннәр докторы, профессор, Куркынычсызлык, сак һәм хокук тәртибе академиясе академигы.







# МУСТАФИН Раис Рауфович

Родился 23 октября 1980 года в селе Алмала Переволоцкого района Оренбургской области. В 1995 году окончил 9 классов средней школы. Как многие мальчишки, он не особо любил корпеть над тетрадками, выполняя домашние задания. Зато устные предметы давались ему легко. По отзывам учителей, Раис был спокойным, уравновешенным, добросовестным и искренним подростком. Он не умел обманывать, если что – все было написано у него на лице. Продолжить образование он решил, не уезжая далеко от дома, в соседнем поселке Кичкас, в профессионально-техническое училище, где получил профессию фермера с правом управлять трактором, комбайном и автомобилем.

В ноябре 1998 года Раиса призвали на срочную службу во Внутренние войска МВД Российской Федерации. После прохождения учебного пункта в Нальчике он был направлен с подразделением для выполнения специальной задачи в Черкесск Карачаево-Черкесской Республики. Подразделение там несло боевую службу по охране резиденции возглавлявшего республику генерала Семенова с 29 июля по ноябрь 1999 года.

После непродолжительного отдыха по возвращении личного состава на место постоянной дислокации часть получила новое задание. С 15 января по 31 мая 2000 года рядовой Мустафин находился в районе Грозного и его пригородах, активно участвуя в выполнении служебно-боевых задач в условиях, сопряженных с риском для жизни.

Первое боевое крещение Раис получил в ходе боя с чеченскими боевиками за промбазу в январе 2000 года.

1980 елның 23 октябрендә Оренбург өлкәсенең Переволоцк районы Алмалы авылында туа. 1995 елда урта мәктәпнең 9 сыйныфын тәмамлый. Малайларның күбесе шикелле үк, өй эшләрен эшләп, дәфтәрләр белән утырырга яратмый. Аның каравы тел предметлары аңа җиңел бирелә. Укытучылары әйтүенчә, Рәис тыныч, сабыр, намуслы һәм ихлас үсмер була. Ул алдаша белми, ялганлый башласа, шунда ук йөзенә чыга. Укуын өеннән бик ерак китмичә, күрше Кичкас авылындагы һөнәри техник училищеда дәвам иттерә. Анда фермер һөнәре һәм трактор, комбайн, автомобиль белән идарә итү хокукы алып чыга.

1998 елның ноябрендә Рәисне Россия Федерациясе ЭЭМның эчке гаскәрләренә хезмәткә алалар. Нальчикта өйрәнүләр узганнан соң подразделениесе белән бергә ул, махсус задание үтәү өчен, Карачай-Черкес Республикасының Черкас шәһәренә җибәрелә. 1999 елның 29 июленнән ноябрьгә кадәр анда подразделение республика башлыгы генерал Семенов резиденциясен саклау хезмәтен үти.

Личный состав үзенең даими урнашкан урынына әйләнеп кайтып, бер аз ял иткәннән соң, часть яңа задание ала. 2000 елның 15 гыйнварыннан 31 маена кадәр рядовой Мостафин Грозный шәһәре тирәсендә гомеренә куркыныч янаган шартларда хәрби бурычлар үтәүдә актив катнаша.

Беренче сугышчан чыныгуны Рәис 2000 елның гыйнварында чечен боевиклары белән промбаза өчен сугышларда ала. Нальчик бригадасының берничә дистә солдаты һәм



Несколько десятков солдат и офицеров из Нальчикской бригады выдвинулись для обороны зданий русской и мусульманской школ в чеченской столице. В этом бою российскими бойцами был уничтожен разведывательно-диверсионный батальон Басаева.

Еще до темноты наши бойцы закрепились в здании русской школы на правом берегу Сунжи – в полуразрушенном трехэтажном строении П– образной формы. Ночь прошла спокойно, отдельные выстрелы неподалеку – не в счет. Бойцы, четко выполняя приказ командира, сменяли друг друга на постах, следили за подступами к школе и соседним улицам, без надобности не показывались в оконных проемах.

Все началось на рассвете. В предутренних сумерках бандиты подкрались к зданию школы с трех сторон, прикрываясь туманом, стелившимся по самой земле. Им помогли и белые маскировочные халаты, делавшие боевиков в тот час практически незаметными для глаза. Нападение враги осуществили по всем правилам военного дела, попытались сразу подавить сопротивление всей огневой мощью, которая имелась в их распоряжении. Но буквально за несколько минут до нападения командир подразделения произвел смену на постах, так что бойцы встретили противника в полной боевой готовности.

Когда ставка на внезапность себя не оправдала, боевики попытались воспользоваться своим численным превосходством – их было не меньше сотни. И это им в какой-

офицеры чечен башкаласындагы рус һәм мөселман мәктәпләре биналарын сакларга дип кузгала. Бу сугышта Россия сугышчылары тарафыннан Басаевның разведка-диверсия батальоны юк ителә.

Караңгы төшкәнчегә үк безнең сугышчылар Сунжа елгасының уң як ярында урнашкан рус мәктәбе бинасына – П хәрефенә охшаган ярымҗимерек өч катлы корылмага урнашалар. Төн тыныч уза, сирәк-мирәк ату тавышлары исәпкә керми. Командир боерыгын төгәл үтәп, сугышчылар постларда берсен-берсе алмаштырып торалар, мәктәпкә һәм күрше урамнарга килү юлларын күзәткәндә, тәрәзә уемнарында бик күренмәскә тырышалар.

Сугыш таң алдыннан башлана. Иртәнге эңгер-меңгердә, җиргә кадәр төшкән куе томаннан файдаланып, бандитлар мәктәп бинасына өч яктан якын киләләр. Аларга кеше күзенә күренмәс иткән ак халатлары да булыша. Дошманнар хәрби эшнең бөтен кагыйдәләрен кулланып һөҗүм итә, үзләрендә булган барлык ут көчләре белән безнекеләрнең каршылыгын бастырырга омтыла. Әмма һөҗүм башланырга берничә генә минут калганда подразделение командиры постлардагы солдатларны алмаштырып өлгерә, шулай итеп, алар дошманны тулы сугышчан хәзерлек белән каршы ала.

Көтмәгәндә һөҗүм итү нияте үзен акламагач, йөзгә якын боевик үзләренең күп санлы булуы белән өстенлеккә ирешмәкче булалар. Башта алар безнең солдатларны беренче каттагы бүлмәләрдән бәреп чыгаралар, ә аннары



то мере удалось: поначалу наших солдат они выбили из отдельных комнат на первом этаже, а потом заняли все правое крыло школы. К тому же им удалось взять в плен сержантов Алексея Морокова и Федора Кандибулу, а так же рядового Виктора Шилова. Прикрываясь заложниками, бандиты решили продвинуться по коридорам к центру школы. Рядовой Шилов, оценив ситуацию, крикнул своим сослуживцам, чтобы они стреляли на поражение. Разрядило ситуацию то обстоятельство, что узкие коридоры здания не позволяли постоянно прикрываться пленными и их куда-то увели. Наступило короткое затишье. Казалось, что боевики растерялись и не знали, что предпринять. Попытались надавить на психику.

– Сдавайтесь,– кричали они,– все равно живыми никого не выпустим, если не прекратите сопротивление. Своих не успеете дождаться. Лучше бросайте оружие и выходите, если хотите остаться живыми.

На уговоры никто не поддался. Боевики, понимая, что инициатива ускользает из рук и вскоре может подоспеть федералам подкрепление, обрушили на солдат новый шквал огня.

80 метр биеклектә катапульта ясарга мәҗбүр була. Шунысы истәлекле, 15 елдан соң, 20 сентябрьдә, Россия Президенты Леонид Степанович Поповка Россия Герое дигән югары исем бирү турындагы Указга кул куя.

Леонид Степанович гореф-гадәтләргә ышана торган кеше түгел. Тик шулай да ул очышлар алдыннан фотосурәткә төшүне хуп күрми...

Үзенең буш вакытларында сынаучы-очучы балалар өчен әкиятләр иҗат итә, фильмнар төшерә, телевидениедә авторлык программалары алып бара, тау чаңгыларында йөрергә ярата, китаплар яза.

Үзенең бер китабында ул, мәсәлән, очышлар вакытында һәлак булган дуслары турында сөйли, аларны хөрмәтләп, күңел җылысы белән искә ала. Леонид Сергеевич үзенең «Минем һөнәремнең өч мәктәбе» дип исемләнгән хикәясендә канатлы профессия кешеләренә булган соклануын дулкынландыргыч итеп сурәтли. Ул шулай ук «80 ел сафта», «Фарнбородан язмалар» дигән һ.б. телевизион фильмнарның авторы да.

Леонид Степанович үзеннән башка тагын 32 Советлар Союзы һәм Россия Геройлары булган Жуковский шәһәрендә яши. Алар шәһәрнең, Дан орденнары кавалерлары белән берлектә, «Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары клубы» эшендә актив катнашалар.





# РАФИКОВ Мансур Минибаевич

Родился 8 декабря 1965 года в селе Кугарчи Кугарчинского района Башкирской АССР. В многодетной крестьянской семье Минибая Салаватовича и Магинур Шаймардановны Мансур был четвертым ребенком. Трех сыновей и трех дочерей вырастили эти скромные труженики, многие годы работавшие в совхозе «Октябрьский».

В 1982 году Мансур окончил среднюю школу. В его школьные годы среди молодежи особой популярностью пользовался фильм «Офицеры», где один из героев произносит крылатую фразу: «Есть такая профессия – Родину защищать». Вот и Мансур решил посвятить свою жизнь защите Родины.

В 1982 году он стал курсантом Казанского высшего командного танкового училища. После его окончания первым местом офицерской службы стала ГСВГ – Группа советских войск в Германии. Здесь молодой офицер прошел хорошую школу боевого мастерства. По признанию ветеранов военной службы, в ГСВГ особенно серьезно относились к боевой подготовке военнослужащих.

В 1989 году, отслужив положенный срок, Мансур возвратился из ГДР на Родину. А на Родине было неспокойно. Тогдашняя политическая элита во главе с Горбачевым, а потом и Ельциным активно принялась за развал Советского Союза. В этой обстановке Рафикову пришлось участвовать в конфликте между двумя союзными республиками – Арменией и Азербайджаном в Нагорном Карабахе.

1965 елның 8 декабрендә Башкортстан АССРның Күгәрчен районы Күгәрчен авылында туа. Миңлебай Салават улы һәм Мәһинур Шәймәрдан кызының күп балалы крестьян гаиләсендә Мансур дүртенче бала була. «Октябрьский» совхозында озак еллар эшләгән бу тыйнак крестьяннар өч ул һәм өч кыз үстерә.

1982 елны Мансур урта мәктәпне тәмамлый. Ул мәктәптә укыган елларда яшьләр арасында «Офицерлар» дигән фильм бик популяр була. Анда геройларның берсе: «Шундый һөнәр бар – Ватанны саклау», – дигән канатлы гыйбарә куллана. Мансур да үзенең гомерен Ватанны саклауга багышларга була.

1982 елда ул – Казан югары команда танк училищесы курсанты. Аны тәмамлагач, офицерлык хезмәтенең иң беренче урыны ГСВГ – совет гаскәрләренең Германиядәге төркеме була. Монда яшь офицер хәрби осталык мәктәбен уза. Хәрби хезмәт ветераннары әйтүенчә, ГСВГда хәрби хезмәткәрләрне сугышка әзерләүгә аеруча җитди карыйлар.

1989 елда, хезмәт срогын тутырып, Мансур ГДРдан Ватанга кайта. Ә бу вакытта Ватанда бик үк тыныч булмый. Горбачев, ә соңрак Ельцин җитәкчелегендәге ул чактагы сәяси элита Советлар Союзын җимерергә керешә. Шушы вәзгыятьтә Таулы Карабахта ике союздаш республика – Әрмәнстан һәм Әзәрбайҗан арасындагы низагта катнашырга туры килә.







А вскоре запахло настоящей войной. Осенью 1994 года гвардии майор Мансур Рафиков в составе группировки 8-го гвардейского корпуса оказался в Чечне. К тому времени он уже командовал отдельным танковым батальоном 20-й гвардейской мотострелковой дивизии, дислоцированной в Волгограде.

Чечня бурлила. К власти здесь пришли мятежные дудаевцы. В республике воцарилось беззаконие. Военные инциденты, похищение людей за выкуп приобрели массовый характер. Со всей остротой встал вопрос о наведении конституционного порядка. В Чечне молодой офицер встретил свое тридцатилетие.

В декабре 1994 года обстановка в районе поселка Петропавловский сложилась непростая. Дудаевские боевики развернули полномасштабные военные действия и упорно держали оборону у реки Сунжи. Нашим подразделениям для развития успеха нужно было отбить у них мост через реку. Майор Рафиков со своими танкистами хорошо понимал, что разведывательный батальон без огневой поддержки задачу не сможет выполнить. Огневое прикрытие со стороны танкистов, смелость и решительность их командира позволили разведчикам разгромить дудаевцев с минимальными потерями. Танковое подразделение гвардии майора Рафикова под шквальным огнем боевиков первым ворвалось в Петропавловский. «Находясь в составе экипажа, – гласит наградной лист, – майор Рафиков лично уничтожил два пулеметных расчета и три расчета ПТУР».

За этот бой под Петропавловском гвардии майору Рафикову был вручен орден Мужества. Новый, 1995-й год

Ә озакламый чып-чын сугыш исе чыга башлый. 1994 елның көзендә 8 нче гвардия корпусы төркеме составында Мансур Рафиков Чечняга эләгә. Бу вакытка ул инде Волгоградта урнашкан 20 нче гвардия мотоукчылар дивизиясенең аерым танк батальонына командалык итә.

Чечня кайнап тора. Монда хакимияткә фетнәче дудаевчылар килгән була. Республикада законсызлык хөкем сөрә. Хәрби инцидентлар, акча өчен кеше урлаулар гадәти хәлгә әйләнә. Илдә конституциячел тәртип урнаштыру мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән килеп баса. Чечняда чакта яшь офицерга 30 яшь тула.

1994 елның декабрендә Петропавловский бистәсе янында катлаулы хәл килеп туа. Дудаев боевиклары сугыш хәрәкәтләрен җәелдереп җибәрә һәм Сунжа елгасы буенда оборона тота. Уңышка ирешү өчен, безнең подразделениеләргә алардан елга аша салынган күперне тартып алырга кирәк була. Ут ярдәменнән башка гына разведка батальонының бурычны үти алмаячагын майор Рафиков яхшы аңлый. Танкистларның ут белән каплап торуы, командирларының кыюлыгы һәм тәвәккәллеге разведчикларга аз гына югалтулар белән дудаевчыларны тар-мар итәргә мөмкинлек бирә. Гвардия майоры Рафиковның танк подразделениесе Петропавловскийга беренче булып бәреп керә. Бүләкләү кәгазендә: «Экипаж составында булган майор Рафиков шәхсән үзе ике пулемет расчетын һәм өч ПТУР расчетын юк итә», – дип язылган. Петропавловский янындагы бу сугыштан соң гвардия майоры Рафиковка Батырлык ордены бирелә. Яңа 1995 елны майор Грозныйда каршылый. Аның подразделениесе иң куркыныч юнәлешләрдә заданиеләр үти. Аның машинасы өч мәртәбә боевик-

майор встретил с боями в Грозном. Его подразделение выполняло задачи на самых опасных направлениях. Трижды его машина подбивалась огнем боевиков, но он оставался в строю и продолжал выполнять боевые задачи. «При прорыве группировки боевиков к центру Грозного, – говорится в том же наградном листе,– майор Рафиков действовал дерзко, обеспечивая непосредственную огневую поддержку и прикрытие штурмовых групп. Умело командовал батальоном в сложном уличном бою, быстро реагировал на изменения обстановки. В составе экипажа уничтожил танк противника, два пулеметных расчета и до 15 боевиков. Сам лично с риском для жизни эвакуировал экипаж нашего подбитого танка в безопасное место».

В ходе ожесточенных уличных боев комбат умело применял технологию «огненной карусели», которая давно была в арсенале войск. Суть этой «карусели» заключалась в том, чтобы вести ураганный огонь по целям, не давая противнику поднять головы. Делалось это так: в окоп загонялся танк, который вел огонь до полного расхода боезапаса в автомате заряжания. Два других танка стояли неподалеку, в укрытии. Отстрелявшись, танк покидал окоп, а на его место тут же вставал другой, затем третий, что позволяло поддерживать непрерывный огненный шквал, помогавший нашим наступающим подразделениям атаковать противника с наименьшими потерями. Боевикам трудно было понять, как это из одного и того же места беспрерывно в течение длительного времени можно вести ураганный огонь. Мансур-шайтан, как его называли боевики, в конечном итоге вышел из боя на четвертом танке, не получив ни одного ранения. Из девяти танков батальона лишь машина комбата осталась невредимой. Редкое везение.

Командир 8-го гвардейского корпуса генерал Лев Рохлин представил отважного комбата к званию Героя России. Генерал был в гневе, когда в Москве усомнились в его оценке отважного комбата. «Уже за то, что человек побывал в этом аду, ему положена медаль, – скажет Лев Яковлевич. – А уж если воевал, как Рафиков…». Настойчивость боевого генерала привела к признанию боевых заслуг майора. Указом Президента РФ от 20 января 1996 года за мужество и героизм, проявленные при выполнении специального задания по восстановлению конституционного порядка на территории Чеченской Республики, гвардии майору Рафикову Мансуру Минибаевичу было присвоено звание Героя России.

Вскоре он был направлен на учебу в бронетанковую академию, в после ее окончания в 1999 году вернулся в родную дивизию в Волгоград заместителем командира мотострелкового полка. На этом его боевая биография не закончилась. Он вновь был направлен старшим батальонной тактической группы в Северо-кавказский регион для участия в контртеррористической операции. И вновь боевой офицер проявил себя настоящим воином. К прежним наградам был добавлен орден «За воинские заслуги».

Какое-то время гвардии подполковник Рафиков передавал свой боевой опыт молодым воинам, а затем приказом министра обороны Герой России был назначен на вышестоящую должность в Сибирский военный округ. С 2006 года полковник Рафиков М.М. – заместитель военного комиссара Калужской области.

лар утыннан зыян күрә, ләкин ул стройда кала һәм хәрби бурычларны үтәвен дәвам иттерә. «Боевиклар төркеме Грозный уртасына үтеп керергә омтылганда, штурмлаучы төркемнәргә ут белән ярдәмне һәм каплап торуны турыдан-туры тәэмин итеп, майор Рафиков кыю гамәлләр кыла. Катлаулы урам сугышында батальонга акыл белән командалык итә, вәзгыять үзгәрешләренә тиз җавап бирә. Экипажы белән бергә дошман танкын, ике пулемет расчетын һәм 15ләп боевикны сафтан чыгара. Гомеренә куркыныч янауга карамастан, шәхсән үзе безнең атылган танк экипажын куркынычсыз урынга эвакуацияли», – диелә шул ук бүләкләү кәгазендә.

Рәхимсез урам сугышлары барышында комбат гаскәрләр арсеналында күптәннән булган «утлы карусель» технологиясен куллана. Бу «карусель»нең эчтәлеге дошманга баш күтәрергә дә ирек бирмичә, давыл сыман ут яудырудан гыйбарәт. Бу болай эшләнә: окопка снарядлары тулысынча беткәнче автомат корылу режимында атып торучы танк кертеп куела. Тагын ике танк якында гына яшеренеп тора. Атып бетергәч, танк окоптан чыга, ә аның урынына шунда ук икенчесе, аннан соң өченчесе кереп баса. Шулай итеп, безнең һөҗүм итүче подразделениеләргә бертуктаусыз ут белән ярдәм итү мөмкинлеге ачыла. Ничек бер үк урыннан озак вакыт буе туктаусыз атып торып булуын боевиклар аңлый алмый. Мансур-шайтан (боевиклар аны шулай дип атый), дүртенче танкка җиткәч, бер яра да алмыйча, сугыштан чыга. Батальонның тугыз танкыннан комбат машинасы гына исән-сау кала.

8 нче гвардия корпусы командиры генерал Лев Рохлин куркусыз комбатны Россия Герое исеменә тәкъдим итә. Мәскәүдәгеләр аның батыр комбатка биргән бәясенә шикләнеп каравын белгәч, генералның ачуы чыга. «Шул тәмугка кереп кенә чыккан өчен дә кешегә медаль бирелергә тиеш, – ди Лев Яковлевич. – Ә инде Рафиков кебек сугышса да...» Хәрби генералның үҗәтлеге аркасында майорның хәрби казанышларын таныргa мәҗбүр булалар. Чечня Республикасы территориясендә конституциячел тәртип урнаштыру буенча махсус задание үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1996 елның 20 гыйнварындагы Указы нигезендә гвардия майоры Рафиков Мансур Миңлебай улына Россия Герое исеме бирелә.

Озак та үтми ул Бронетанк академиясенә укырга җибәрелә, ә аны тәмамлагач, 1999 елда Волгоградтагы үз дивизиясенә мотоукчылар полкы командиры урынбасары булып әйләнеп кайта. Аның хәрби биографиясе шуның белән генә тәмамланмый әле. Ул яңадан, террорчылыкка каршы операциядә катнашу өчен, Төньяк Кавказ төбәгенә батальонның тактик төркеме җитәкчесе итеп җибәрелә. Хәрби офицер кабат үзен чын сугышчы итеп күрсәтә. Элекке бүләкләренә «Хәрби казанышлар өчен» ордены өстәлә.

Күпмедер вакыт гвардия подполковнигы Рафиков үзенең хәрби тәҗрибәсен яшь сугышчыларга өйрәтә, ә аннары оборона министры боерыгы белән Россия Герое Себер хәрби округына югарырак вазыйфага билгеләнә. 2006 елдан полковник М.М.Рафиков – Калуга өлкәсе хәрби комиссары урынбасары.







# САФИН Дмитрий Анатольевич

Родился 8 декабря 1972 года в городе Междуреченске Кемеровской области. Окончил среднюю школу № 1 имени Героя Советского Союза М.М. Куюкова. В 1989 году поступил в Уссурийское суворовское военное училище.

Дмитрий Сафин вырос в семье, славной боевыми традициями. Один его дед, Рюмин Юрий Иванович, – кадровый военный, ветеран Великой Отечественной войны. Командиром пулеметного подразделения вначале в составе Степного, а затем Второго Украинского фронта прошагал огненные версты от Курской дуги до Праги. Награжден орденом Красной Звезды, двумя орденами Отечественной войны, медалями.

Отец, Анатолий Игнатьевич Сафин, служил на флоте в мирное время, но тоже вернулся домой с воинской наградой. В составе экипажа знаменитого авианесущего крейсера «Москва» он участвовал в крупнейших военно-морских учениях «Океан». Был награжден медалью «За воинскую доблесть».

После суворовского училища Дмитрий с отличием окончил военное училище в Киеве, где получил воинскую специальность разведчика. Было смутное время развала амбициозными политиками Советского Союза, и ему предложили остаться на Украине. Дмитрий ответил: «Я уже давал присягу Родине, а два раза не присягают».

С 1989 года Сафин служил в 67-й отдельной бригаде специального назначения ГРУ Генштаба в составе Сибирского военного округа в городе Бердске Новосибирской области.

В период с 1995-го по 2001 год совершил пять командировок на первую и вторую чеченские войны. Самым суровым испытанием на боевой профессионализм стала для него четвертая командировка.

1972 елның 8 декабрендә Кемерово өлкәсенең Междуреченск шәһәрендә туа. Советлар Союзы Герое М.М.Куюков исемендәге 1 нче урта мәктәпне тәмамлый. 1989 елда Уссурийск Суворов хәрби училищесына укырга керә.

Дмитрий Сафин хәрби традицияләре белән данлыклы гаиләдә үсә. Аның бер бабасы – Рюмин Юрий Иванович – кадровый хәрби, Бөек Ватаны сугышы ветераны. Башта Степной, ә аннары Икенче Украина фронты составында пулеметчылар подразделениесе командиры булып Курск дугасыннан Прагага кадәр утлы юллар узган. Кызыл Йолдыз ордены, ике Ватан ордены, медальләр белән бүләкләнгән.

Әтисе Анатолий Игнатьевич Сафин флотта тыныч вакытта хезмәт иткән, әмма ул да өенә хәрби бүләк алып кайткан. Данлыклы «Мәскәү» авиайөртүче крейсер экипажы составында ул «Океан» дип исемләнгән бик зур хәрби диңгез учениеләрендә катнаша. «Сугышчан дан өчен» медале белән бүләкләнә.

Суворов училищесыннан соң Дмитрий Киев хәрби училищесын бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Аннан ул разведчик хәрби белгечлеген алып чыга. Бу амбицияле сәясәтчеләрнең Советлар Союзын таркаткан болганчык вакыты була. Аңа Украинада калырга тәкъдим итәләр. Дмитрий исә: «Мин Ватаныма присяга бирдем инде, присяганы ике тапкыр бирмиләр», – дип җавап бирә.

1989 елдан Сафин Новосибирск өлкәсе Бердск шәһәрендәге Себер хәрби округы составында Генштабның ГРУ 67 нче аерым спецназ бригадасында хезмәт итә.

1995 елдан 2001 елга кадәрге чорда беренче һәм икенче чечен сугышларына биш тапкыр командировкага бара. Хәрби профессиональлеген сынаган иң авыры дүртенче командировкасы була.

15 апреля 2000 года разведывательный отряд под командованием майора Сафина был десантирован вертолетами для разведки района сосредоточения бандформирования и обеспечения бесперебойного продвижения подразделений федеральных сил. После десантирования и захвата плацдарма отряд попал под огонь боевиков. Майор Сафин, грамотно оценив обстановку, умело организовал бой и в дальнейшем точно корректировал огонь артиллерии. В результате огневого налета были уничтожены база боевиков, автомобиль повышенной проходимости «УАЗ-469» и до 20 террористов.

5 мая 2000 года разведывательный отряд под командованием майора Сафина выполнял поисково-засадные действия. Головной дозор отряда обнаружил группу боевиков, организовавшую засаду на одной из лесных троп. В ходе завязавшегося боя боевикам удалось подорвать заранее установленное минное устройство, в результате чего в головном дозоре отряда появились раненые. Майор Сафин организовал оборону, вывел разведывательный отряд на выгодную высоту, откуда огнем из стрелкового оружия и гранатометов не позволил боевикам захватить в плен раненых разведчиков. Лично возглавил эвакуацию из-под огня противника раненых подчиненных.

20 мая 2000 года его разведывательный отряд проводил поисково-разведывательные мероприятия. Головной отряд обнаружил на склоне высоты замаскированную базу боевиков и принял решение своими силами атаковать эту базу. Бойцы быстро уничтожили расчет крупнокалиберного пулемета, который препятствовал продвижению. Однако противник ответил плотным огнем. О завязавшейся перестрелке майор сообщил на базу. Минут через 15 по «зеленке» открыла огонь артиллерия, а еще минут через 40 появилась пара вертолетов Ми-24. Обозначив себя, спецназовцы дали летчикам целеуказание. Огонь с вертолетов наряду с артиллерией заставил боевиков отступить. При осмотре поля боя спецназовцы обнаружили тела боевиков, в том числе погибшего полевого командира и тщательно замаскированную базу с боеприпасами, запасами оружия, продовольствия и вещевого имущества.

За участие в многочисленных боевых операциях Дмитрий Сафин был награжден орденом Мужества, медалью «За заслуги перед Отечеством» 2-й степени, медалью «За отвагу».

Несколько позднее за мужество и героизм, проявленные при ликвидации незаконных вооруженных формирований в Северо-Кавказском регионе, указом Президента РФ от 4 мая 2001 года Сафину Дмитрию Анатольевичу было присвоено звание Героя Российской Федерации.

Герой России продолжил службу в Вооруженных Силах страны. В 2004 году он окончил Академию имени М.В. Фрунзе, ему присвоили звание подполковника.

В одном из интервью журналисты задали Сафину такой вопрос: «Скажите, за что вы получили Звезду Героя?» – «За служение Отечеству, если коротко», – был ответ.

– Дмитрий Анатольевич,– последовал другой вопрос, – не жалеете ли вы о том, что связали жизнь с армией?

– Нет, я ни разу не пожалел о том, что стал офицером, – не раздумывая, ответил Сафин. – Уверен: все лучшее, что было в моей жизни, мне дала армия!

2000 елның 15 апрелендә майор Сафин җитәкчелегендәге разведка отряды, бандформированиеләр тупланган районга разведка ясау һәм федераль көчләр подразделениеләренең туктаусыз алга баруын тәэмин итү өчен, вертолетлардан десант булып төшә. Төшеп, плацдармны алганнан соң отряд боевиклар уты астына эләгә. Хәлгә дөрес бәя бирә алган майор Сафин сугышны оештыра һәм алга таба артиллерия уты белән төгәл идарә итә. Ут һөҗүме нәтиҗәсендә боевикларның базасы, начар юлдан йөри торган «УАЗ-469» автомобиле һәм егермеләп террорчы юк ителә.

2000 елның 5 маенда майор Сафин җитәкчелегендәге разведка отряды засадалар эзләү эшен башкара. Отрядның баш дозоры урман сукмакларының берсендә засада оештырган боевиклар төркемен күреп ала. Башланып киткән сугышта боевиклар алдан ук куелган минаны шартлата, нәтиҗәдә отрядның баш дозорында яралылар барлыкка килә. Майор Сафин оборона оештыра, разведка отрядын уңайлы биеклеккә чыгара. Шуннан мылтыклардан һәм гранатометлардан атып, боевикларга яралы разведчикларны әсирлеккә алырга комачаулый. Яраланган солдатларын дошман уты астыннан эвакуацияләүдә шәхсән үзе башлап йөри.

2000 елның 20 маенда аның разведка отряды эзләү-тикшерү чаралары үткәрә. Баштагы отряд биеклек итәгендә боевикларның маскировкаланган базасын күреп ала һәм үз көчләре белән бу базага һөҗүм итәргә ниятли. Алга барырга комачаулап торган эре калибрлы пулемет расчетын сугышчылар тиз генә юк итә. Ләкин дошман көчле ут белән җавап бирә. Башланып киткән атыш турында майор базага хәбәр итә. 15 минуттан соң артиллерия ут ача, ә 40 минуттан ике «Ми-24» вертолеты пәйда була. Үзләрен белгертеп, спецназчылар очучыларга кая атарга икәнен күрсәтәләр. Артиллерия белән бергә вертолетлардан да яуган ут боевикларны чигенергә мәҗбүр итә. Сугыш кырын тикшергәндә спецназчылар боевиклар мәетләрен, шул исәптән һәлак булган кыр командирын һәм бик тырышып маскировкаланган боеприпаслар, корал, азык-төлек һәм башка әйберләр запасы булган базаны табып алалар.

Бик күп сугышчан операцияләрдә катнашкан өчен Дмитрий Сафин Батырлык ордены, 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен», «Батырлык өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Бераз соңрак Төньяк Кавказ төбәгендә законсыз кораллы формированиеләрне юкка чыгарганда күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2001 елның 4 маендагы Указы нигезендә Сафин Дмитрий Анатольевичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә.

Россия Герое илнең Кораллы көчләрендә хезмәтен дәвам иттерә. 2004 елда ул М.В.Фрунзе исемендәге академияне тәмамлый, аңа подполковник званиесе бирелә.

Бер әңгәмә вакытында журналистлар Сафинга мондый сорау бирә: «Әйтегез әле, Герой Йолдызын сез нәрсә өчен алдыгыз?» «Кыскача гына әйткәндә, Ватанга хезмәт иткән өчен», – дигән җавап ишетелә. «Дмитрий Анатольевич, тормышыгызны армия белән бәйләгәнгә үкенмисезме?» – дигән икенче сорауга Сафин, ике дә уйламыйча: «Юк, офицер булуыма беркайчан да үкенмәдем, – дип җавап бирә. – Тормышымда булган иң яхшы нәрсәләрне миңа армия бирде!»







# САХАБУТДИНОВ Риф Раисович

Родился 9 декабря 1955 года в Уфе. С 1963-го по 1970 год жил в деревне Кляшево Чишминского района – на родине народного поэта Башкортостана Мустая Карима. Риф был самым старшим из четырех детей простых сельских тружеников Раиса и Сагиды Сахабутдиновых. Из школьного детства ему на всю жизнь запомнились приезды Мустая Карима в родную деревню: знаменитого земляка встречали всей школой. Ребята собирались у большого костра на опушке леса, читали его стихи…Тогда же у Рифа появилась мечта о небе.

Кляшевская школа была неполной, поэтому аттестат о среднем образовании он получил в уфимской средней школе № 15. Первым шагом к заветной мечте стало поступление в 1973 году в Сызранское высшее военное авиационное училище, которое он окончил в 1977 году. После четырех лет напряженной учебы и получения лейтенантских погон Риф пять лет прослужил в Монголии, где прошел должности летчика-оператора вертолета Ми-24, старшего летчика. Там, в Монголии, в 1980 году у них с женой Галиной появилась на свет старшая дочь Лена. Потом было Прикарпатье. В период с 1983 по 1984 год в составе Ограниченного контингента советских войск Риф участвовал в боевых действиях на территории Афганистана в должности заместителя командира эскадрильи.

В июне 1984 года в районе Кандагара экипаж вертолета Ми-24 под командованием капитана Сахабутдинова наносил удары по позициям душманов. При выходе из атаки душманская ракета, запущенная с земли из «стингера», попала в двигатель, и машина практически взорвалась в

1955 елның 9 декабрендә Уфада туа. 1993 елдан 1970 елга кадәр Чишмә районы Келәш авылында яши. Риф гади авыл хезмәтчәннәре Сәгыйдә һәм Рәис Сәхабетдиновларның дүрт баласыннан иң өлкәне була. Мәктәп елларыннан ук ул туган авылына Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим кайткан чакларны исендә калдыра. Танылган якташларын бөтен мәктәп белән каршылыйлар. Егетләр, урман кырыендагы зур учак янына җыелышып, аның шигырьләрен укыйлар. Рифнең күктә очу турындагы хыялы шул вакытта барлыкка килә.

Келәш мәктәбе сигезьеллык кына була, шуңа күрә урта белемне ул Уфадагы 15 нче мәктәптә ала. 1973 елда Сызрань югары хәрби авиация училищесына укырга керүе хыялына таба беренче адым булып тора. Училищены ул 1977 елны тәмамлый. Дүрт ел укыганнан соң лейтенант погоннарына ия булган Риф биш ел Монголиядә хезмәт итә. Анда «Ми-24» вертолетының очучы-операторы, өлкән очучы вазыйфаларын үти. Монголиядә чакта 1980 елны хатыны Галина белән икесенең Лена исемле кызлары туа. Шуннан соң – Карпат яны. 1983-1984 елларда совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты составында Әфганстан территориясендәге сугыш хәрәкәтләрендә эскадрилья командиры урынбасары буларак катнаша.

1984 елның июнендә Кандагар тирәсендә капитан Сәхабетдинов җитәкчелегендәге «Ми-24» вертолеты экипажы дошман позицияләренә удар ясый. Атакадан чыкканда җирдән «стингер»дан җибәрелгән дошман ракетасы моторга тия һәм машина һавада ук шартлый. Биеклекнең аз – 50



воздухе. Спасло то, что высота была небольшая – не более пятидесяти метров. Упали на склон горы. Душманы сразу же стали смыкать вокруг вертелетчиков кольцо, пришлось отстреливаться. Когда боеприпасы были на исходе, к счастью, подоспели наши «вертушки» и эвакуировали подбитый экипаж.

В Афгане Риф Раисович прослужил полтора года. Не раз он находился на волосок от смерти, но в разговоре упомянул лишь о таком опасном эпизоде:

– В Афганистане служил я в одной из самых «горячих» точек. Однажды вечером мы высадили спецназовцев в засаду на дорогу, а ночью они должны были выходить на связь, но их рация почему-то молчала. Было приказано разведать, найти и эвакуировать ребят. Когда подлетели к месту высадки, то попали в самый разгар кровопролитного боя, в котором отряд понес большие потери. Когда я пошел на приземление, в вертолет попала душманская ракета. Несмотря на повреждения, мне удалось посадить машину. Что меня спасло? Опыт и летное мастерство. Отчасти и везение. Иногда в это слово, как летчик, верю.

За оказание интернациональной помощи афганскому народу Сахабутдинов был награжден орденами Красной Звезды и «За службу Родине в Вооруженных Силах» 3-й степени.

Затем последовала служба в Польше. В 1985 году капитан Сахабутдинов стал слушателем Военно-воздушной академии имени Гагарина, имея за плечами 540 вылетов, совершенных в небе Афганистана. В период учебы в подмосковном Монино у Сахабутдиновых родилась младшая дочь Юля. После окончания академии в 1988 году Риф слу-

метрлар тирәсе генә булуы коткарып кала. Тау сөзәклегенә егылып төшәләр. Дошманнар шунда ук вертолетчыларны боҗрага әйләндереп ала, атышырга туры килә. Боеприпаслар бетте дигәндә генә, бәхеткә каршы, безнең «вертушкалар» килеп җитә һәм бәреп төшерелгән экипажны эвакуацияли.

Әфганда Риф Рәис улы ел ярым хезмәт итә. Үлем аның янына бер генә тапкыр килми. Ләкин Сәхабетдинов үзе бер куркыныч вакыйганы гына сөйләде.

– Әфганстанда мин иң «кайнар нокта»ларның берсендә хезмәт иттем. Бервакыт кич белән без спецназчыларны юлга засадага төшердек, ә төнлә алар элемтәгә чыгарга тиеш иде. Әмма рацияләре нишләптер эндәшми торды. Безгә егетләрне эзләп табарга һәм эвакуацияләргә дигән боерык булды. Аларны төшергән урынга килеп җиткәч, канкойгыч сугышның иң кызган чагына эләктек. Ул сугышта десантчылар отряды зур югалтуларга дучар булган иде. Мин җиргә төшеп утырырга әзерләнгәндә, вертолетка дошман ракетасы килеп тиде. Шуңа да карамастан, машинаны утырта алдым. Нәрсә коткарды дисезме? Тәҗрибә һәм очу osталыгы. Җай килү дә булгандыр. Очучы буларак, кайчак бу сүзгә ышанырга да туры килә.

Әфган халкына интернациональ ярдәм күрсәткән өчен Сәхабетдинов Кызыл Йолдыз һәм 3 нче дәрәҗә «Кораллы көчләрдә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары белән бүләкләнә.

Аннан соң Польшада хезмәт итү башлана. 1985 елны Әфганстан күгендә 540 очыш ясаган капитан Сәхабетдинов Гагарин исемендәге Хәрби-һава академиясе тыңлаучысы була. Уку чорында Сәхабетдиновларның кече кызла-



жил в Прикарпатье, Германии, командовал авиационным полком в Костроме.

После распада Советского Союза участвовал в миротворческой миссии в Таджикистане и в контртеррористической операции на Северном Кавказе.

В 1996 году полковник Сахабутдинов прибыл в Северо-Кавказский военный округ на должность заместителя начальника авиации 58-й армии во Владикавказе. К тому времени его классная квалификация летчика-снайпера говорила сама за себя. С началом контртеррористической операции на Северном Кавказе в августе 1999 года Риф Сахабутдинов исполнял обязанности начальника армейской авиации направления.

Отряды боевиков Басаева и Хаттаба закрепились на хорошо укрепленных позициях на высоте вблизи дагестанского села Болтлих. Продвижение наших подразделений в этом районе было чревато большими потерями. За дело взялись вертолетчики. Преодолевая сильное огневое противодействие со стороны бандитов, подчиненные Сахабутдинова методично наносили точечные залповые удары по окопавшимся террористам. Во взаимодействии с артиллерией «летающие танки» выбили противника с господствующей высоты.

За участие в этой операции Риф Раисович был награжден орденом Мужества. На начальном этапе чеченской фазы контртеррористической операции Риф Сахабутдинов участвовал в боевых действиях в составе Западной группировки. Как известно, это было одно из самых сложных направлений: с первых дней федеральные войска столкнулись с ожесточенным сопротивлением бандформирований.

13 декабря 1999 года на командный пункт генерала Владимира Шаманова поступила информация о том, что в районе населенного пункта Горагорск попала в засаду разведгруппа. Есть погибшие и раненые. Нужна срочная помощь. Для выяснения ситуации на место вылетели командующий группировкой и начальник армейской авиации полковник Сахабутдинов. «Восьмерка» приземлилась практически в эпицентре боя. Сориентировавшись в обстановке, Риф Раисович вызвал вертолеты боевой поддержки. Затем он же навел Ми-24 на боевые позиции противника с ювелирной точностью, да и нельзя было иначе: слишком близко друг к другу находились противоборствующие стороны. Среди вертолетчиков, участвовавших в спасении разведчиков, были и земляки Рифа Раисовича из Башкортостана – майор Владимир Алимов и подполковник Рафик Ихсанов, впоследствии удостоенный звания Героя России. По возвращении в «вертушке» Сахабутдинова насчитали 16 пробоин, но главное было сделано – разведчиков удалось вытащить из пекла. Всех – и живых, и погибших. Бандиты же потеряли тогда до 70 человек убитыми.

Позже Риф Раисович участвовал в различных сложнейших операциях, в том числе по разблокированию села Комсомольское.

В общей сложности в 2000 году полковник Сахабутдинов совершил 237 боевых вылетов. Успешных по всем параметрам летной науки.

Указом Президента РФ от 27 апреля 2001 года за мужество и героизм, проявленные при исполнении воинско-

ры Юля туа. Академияне 1988 елда тәмамлаган Риф Карпат янында, Германиядә хезмәт итә, Костромада авиация полкы командиры була.

Советлар Союзы таркалгач, Таҗикстандагы тынычлык урнаштыру миссиясендә һәм Төньяк Кавказда террорчылыкка каршы операциядә катнаша.

1996 елда полковник Сәхабетдинов Владикавказдагы 58 нче армиянең авиация начальнигы урынбасары вазыйфасында Төньяк Кавказ хәрби округына килеп төшә. Ул вакытка инде аның очучы-снайпер класс квалификациясе була. Төньяк Кавказда террорчылыкка каршы операция башланганда, 1999 елның августында Риф Сәхабетдинов армия авиациясе начальнигы вазыйфасын үти.

Басаев һәм Хаттаб боевиклары отрядлары Болтлих дагстан авылы янындагы биеклекләрдәге позицияләрдә ныклап урнашкан була. Бу районда безнең подразделениеләрнең хәрәкәтенең зур югалтуларга китерү ихтималы була. Бу эшкә вертолетчылар алына. Бандитларның көчле каршылык күрсәтүен җиңеп, Сәхабетдинов кул астындагылар окопларга урнашкан террорчыларга төбәп нокталы залплар бирәләр. Артиллерия белән берлектә «оча торган танклар» дошманны өстенлек иткән биеклекләреннән бәреп чыгара.

Бу операциядә катнашкан өчен Риф Рәис улы Батырлык ордены белән бүләкләнә. Террорчылыкка каршы операциянең чечен фазасының башлангыч этабында Риф Сәхабетдинов Көнбатыш төркеме составында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Билгеле булганча, бу иң авыр юнәлешләрнең берсе була. Беренче көннәрдә үк федераль гаскәрләр банформированиеләрнең бик каты каршылыгына очрый.

1999 елның 13 декабрендә генерал Владимир Шамановның команда пунктына Горагорск авылы тирәсендә разведка төркеменең засадага очравы турында мәгълүмат керә. Һәлак булганнар һәм яралылар да бар, бик тиз ярдәм кирәк, диләр. Вәзгыятьне ачыклау өчен, ул урынга төркем командующие һәм армия авиациясе начальнигы Сәхабетдинов оча. «Сигезле» сугышның нәкъ үзәгенә диярлек килеп төшә. Тиз генә хәлне аңлап алып, Риф Рәис улы ярдәмгә сугышчан вертолетлар чакыра. Аннан соң ул үзе үк «Ми-24»не зәркәнчеләр төгәллеге белән дошман позицияләренә юнәлтә. Башкача ярамый да: сугышучы яклар берберсенә артык якын урнашкан була. Разведчикларны коткаруда катнашучы вертолетчылар арасында Башкортстаннан Риф Рәис улының якташлары да – майор Владимир Алимов һәм соңыннан Россия Герое исемен алган подполковник Рафик Ихсанов та була. Әйләнеп кайткач, Сәхабетдинов вертолетында 16 тишек саныйлар, әмма иң мөһиме инде эшләнгән – разведчиклар ут эченнән алып чыгылган була. Исәннәре дә, үлгәннәре дә. Ә бандитлар ул чакта 70 кешеләрен югалта.

Соңрак Риф Рәис улы төрле катлаулы операцияләрдә, шул исәптән Комсомольское авылын азат иткәндә дә катнаша.

Гомумән алганда, 2000 елда подполковник Сәхабетдинов 237 сугышчан очыш ясый. Очышлар фәненең бөтен параметрлары буенча караганда да уңышлы очышлар була ул.

Төньяк Кавказ төбәгендә сугышчан бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Прези-



го долга в Северо-кавказском регионе, полковнику Сахабутдинову Рифу Раисовичу было присвоено звание Героя Российской Федерации. 8 мая 2001 года Президент В. Путин вручил ему «Золотую Звезду» в Георгиевском зале Кремля. Был и еще один ценный подарок – народный поэт Башкортостана Мустай Карим подарил Рифу Раисовичу сборник своих стихов с надписью: «Односельчанину с соседней улицы Герою России Рифу Сахабутдинову от Героя Труда Мустая Карима с наилучшими пожеланиями».

В апреле 2002 года Риф Раисович получил назначение на должность начальника штаба – первого заместителя начальника авиации Ленинградского военного округа, а с ноября того же года стал начальником армейской авиации округа. В августе 2003 года на его плечи заслуженно легли генеральские звезды, а еще через два месяца Риф Раисович стал начальником авиации – заместителем командующего 6-й армии ВВС и ПВО по авиации.

В служебном кабинете, расположенном на Дворцовой площади Санкт-Петербурга, Героя России генерал-майора авиации Рифа Сахабутдинова застать было сложно. Он постоянно находился в поездках по частям и соединениям армии. С 2007 года вышел в запас. Указом Президента Башкортостана от 30 мая 2008 года Риф Раисович назначен главой представительства Республики Башкортостан в Санкт-Петербурге.

Боевые награды генерала красноречиво говорят о том, какой ратный путь прошел этот человек: медаль «Золотая Звезда», ордена Красной Звезды, Мужества, «За службу Родине в Вооруженных Силах СССР» и 25 медалей. Он к тому же зслуженный военный летчик Российской Федерации.

– Я счастливый человек, – признается Риф Раисович, – имею хорошую семью, любимую работу. Все цели, которые я ставил перед собой, достиг. Если б мне предложили начать с нуля, то ничего не стал бы менять. Но самое главное – осуществилась моя детская мечта.

дентының 2001 елның 27 апрелендәге Указы нигезендә полковник Сәхабетдинов Риф Рәис улына Россия Федерациясе Герое исеме бирелә. 2001 елның 8 маенда Кремльнең Георгий залында Президент Владимир Путин аңа «Алтын Йолдыз» тапшыра. Тагын бер кыйммәтле бүләк тә була әле – Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим Риф Рәис улына: «Күрше урамдагы авылдашым Россия Герое Риф Сәхабетдиновка Хезмәт Герое Мостай Кәримнән иң изге теләкләр белән», – дип язып, үзенең шигырьләр җыентыгын бүләк итә.

2002 елның апрелендә Риф Рәис улы штаб начальнигы – Ленинград хәрби округының авиация начальнигы беренче урынбасары вазыйфасына билгеләнә, ә шул ук елның ноябреннән округның армия авиациясе начальнигы була. 2003 елның августында аның иңнәренә лаеклы рәвештә генерал йолдызлары ята. Тагын ике айдан Риф Рәис улы авиация начальнигы – Хәрби-һава көчләре һәм ПВО 6 нчы армиясе командующиенең авиация буенча урынбасары була.

Россия Герое авиация генерал-майоры Риф Сәхабетдиновны Санкт-Петербургның Сарай мәйданында урнашкан кабинетында туры китерү бик авыр була. Ул һәрвакыт армия частьлары һәм берләшмәләре буйлап йөри. 2007 елда запаска чыга. Башкортстан Президентының 2008 елның 30 маендагы Указы белән Риф Рәис улы Башкортстан Республикасының Санкт-Петербургтагы вәкиллеге башлыгы итеп билгеләнә.

«Алтын Йолдыз» медале, Кызыл Йолдыз, Батырлык, «СССРның Кораллы көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм 25 медаль бу кешенең нинди көрәш юлы үткәне хакында бик ачык сөйлиләр. Өстәвенә ул – Россия Федерациясенең хәрби очучысы да.

– Мин бәхетле кеше, – ди Риф Рәис улы, – әйбәт гаиләм, яраткан эшем бар. Үз алдыма куйган бөтен максатларыма ирештем. Әгәр миңа барысын да яңадан башларга тәкъдим итсәләр, бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Иң мөһиме – минем бала чактагы хыялым тормышка ашты.







# СИМОНОВ
## Михаил Петрович

Родился 19 октября 1929 года в Ростове-на-Дону в семье учителей. В 1933 году с родителями уехал в подмосковный поселок Быково, затем в Алма-Ату, куда после окончания аспирантуры получил распределение отец. Здесь Михаил пошел в школу, увлекся авиацией, занимаясь в Обществе юных авиастроителей. После Великой Отечественной войны Симоновы вернулись в родные края – город Каменск-Шахтинский Ростовской области. Здесь Михаил окончил среднюю школу.

В 1947 году он поступил в Новочеркасский политехнический институт на специальность «проектирование и эксплуатация автомобилей». К третьему курсу благодаря отличной учебе стал Сталинским стипендиатом. Помимо учебы увлеченно занимался велосипедным спортом и даже вошел в студенческую сборную Российской Федерации. Но интерес к авиации был настолько велик, что в 1951 году парень перевелся в Казанский авиационный институт, на четвертый курс самолетостроительного факультета. В 1953 году в КАИ был создан планерный кружок, вскоре преобразованный в студенческое конструкторское бюро, первое в стране, одним из основных организаторов его стал Михаил Симонов.

По окончании института в 1954 году Михаил был оставлен на работу в КАИ – назначен заведующим лабораторией и одновременно ассистентом кафедры конструирования самолетов.

1929 елның 19 октябрендә Ростов-Донда укытучылар гаиләсендә туа. 1933 елны әти-әниләре белән бергә Мәскәү астындагы Быково бистәсенә, аннары Алма-Атага күченеп китә. Аспирантура бетергәннән соң әтисен шунда эшкә җибәрәләр. Монда Михаил мәктәпкә укырга керә, авиация белән кызыксынып китә, Яшь авиатөзүчеләр җәмгыятендә шөгыльләнә. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, Симоновлар туган якларына – Ростов өлкәсенең Каменск-Шахтинский шәһәренә әйләнеп кайталар. Урта мәктәпне Михаил монда тәмамлый.

1947 елны ул Новочеркасск политехника институтына «автомобильләрне проектлау һәм эксплуатацияләү» белгечлегенә укырга керә. Өченче курска җиткәндә, бик яхшы укыганы өчен Сталин стипендиясенә ия була. Укудан тыш, бик мавыгып, велосипед спорты белән шөгыльләнә, хәтта Россия Федерациясенең студентлар җыелмасына да эләгә. Ләкин авиация белән кызыксынуы шулкадәр көчле була ки, 1951 елда дүртенче курска егет Казан авиация институтының самолетлар төзү факультетына күчә. 1953 елда КАИда планер түгәрәге оештырыла, озакламый ул илебездә беренче студентлар конструкторлык бюросына әверелә. Аның төп оештыручыларыннан берсе Михаил Симонов була.

1954 елда институтны тәмамлагач, Михаилны КАИда эштә калдыралар, лаборатория мөдире һәм бер үк вакыт-





В 1959 году в институте создается ОКБ спортивной авиации. Симонов становится в нем главным конструктором и одновременно инструктором и летчиком-буксировщиком авиаспортклуба. В ОКБ спортивной авиации под его началом были созданы первые в СССР цельнометаллические рекордные планеры, на которых установлено несколько рекордов СССР и мира.

Михаил не только проектировал планеры, но и летал на спортивных самолетах и практически на всех модификациях планеров, которые были в аэроклубах Советского Союза.

В 1969 году Симонова переводят в Москву и назначают первым заместителем главного конструктора Долгопрудненского КБ автоматики. С 1970 года он первый заместитель главного конструктора Таганрогского авиационного завода и начальник Ухтомского филиала этого завода. Там он работает под началом выдающегося конструктора и ученого Роберта Бартини.

С 1970-го по 1979 год Михаил Симонов в ОКБ П.О. Сухого – вначале заместителем главного, а затем главным конструктором. Здесь он руководит летными испытаниями и доводкой опытного самолета Т-6, будущего фронтового бомбардировщика Су-24, штурмовика Су-25, ставшего лучшим в своем классе в мировом авиастроении и родоначальником целого семейства многофункциональных авиакомплексов.

В 1979 году из-за конфликта с тогдашним генеральным конструктором ОКБ Симонова перевели на работу в Министерство авиационной промышленности СССР на должность заместителя министра по науке и новой технике. На новом месте он уделял особое внимание созданию авиационных боевых комплексов и особенно созданию авиационного бортового комплекса оборудования. В 1981 году выезжал в воюющий Афганистан для оказания технической помощи по эффективному применению штурмовиков Су-25.

В январе 1983 года Михаил Петрович был назначен генеральным конструктором ОКБ имени П.О. Сухого, а в 1995-м – одновременно генеральным директором ОКБ. Под его руководством и при непосредственном участии созданы боевые самолеты различного назначения Су-27,

та самолетлар төзү кафедрасы ассистенты итеп билгелиләр.

1959 елда институтта спорт авиациясе конструкторлык бюросы оештырыла. Симонов аның баш конструкторы һәм шул ук вакытта авиация спорт клубының инструкторы һәм очучы-буксирлаучысы була. Спорт авиациясе конструкторлык бюросында аның кул астында СССРда беренче тоташ металлдан эшләнгән планерлар ясала. Аларда берничә СССР һәм дөнья рекорды куела.

Михаил планерлар проектлап кына калмый, спорт самолетларында һәм Советлар Союзы аэроклубларында булган планерларның бөтен модификацияләрендә диярлек оча.

1969 елда Симоновны Мәскәүгә күчерәләр һәм Долгопрудный автоматика конструкторлык бюросына баш конструктор урынбасары итеп билгелиләр. 1970 елдан ул – Таганрог авиация заводы баш конструкторының беренче урынбасары һәм шушы заводның Ухтомскидагы филиалы начальнигы. Анда ул данлыклы конструктор һәм галим Роберт Бартини кул астында эшли.

1970 елдан 1979 елга кадәр Михаил Симонов П.О. Сухой исемендәге конструкторлык бюросында алдан баш конструктор урынбасары, ә аннары баш конструктор булып тора. Монда ул «Т-6» тәҗрибә самолетын, «Су-24» бомбардировщигын, бөтен дөнья авиатөзелешендә үз классында иң яхшыга әверелгән һәм күпфункцияле аваикомплекслар семьялыгының беренче «баласы» булган «Су-25» штурмовигын сынау һәм камилләштерү белән җитәкчелек итә.

1979 елдан конструкторлык бюросының ул чактагы генераль конструкторы белән низаг килеп чыгу аркасында, Симоновны СССРның Авиация промышленносте министрлыгына фән һәм яңа техника буенча министр урынбасары вазыйфасына күчерәләр. Яңа урында сугышчан авиация комплексларын, бигрәк тә авиация җиһазларының борт комплексын төзүгә аерым игътибар бирә. 1981 елда «Су-25» штурмовикларын нәтиҗәле куллану буенча техник ярдәм күрсәтү өчен сугыш барган Әфганстанга чыгып китә.

1983 елның гыйнварында Михаил Петрович П.О.Сухой исемендәге конструкторлык бюросына генераль конструктор итеп, ә 1995 елдан бер үк вакытта конструкторлык бюросының генераль директоры итеп билгеләнә. Аның






Су-30, Су-33, Су-34, Су-35 и их многочисленные модификации, спортивно-пилотажный самолет Су-26 и его модификации, пассажирский самолет С-80, экспериментальный самолет с обратной стреловидностью крыла Су-47 «Беркут», который стал первым отечественным прототипом самолета пятого поколения, а также Су-30МК, Су-32НФ, Су-37.

ОКБ было создано целое семейство спортивных пилотажных акробатических самолетов. На Су-26 неоднократно наши пилоты одерживали победы на чемпионатах мира по воздушной акробатике и пилотированию. Истребитель Су-33 впервые в практике отечественного авиастроения совершил посадку на палубу авианесущего крейсера «Адмирал Флота Советского Союза Кузнецов».

К 1995 году в возглавляемую Михаилом Симоновым корпорацию входили 32 предприятия, в том числе АО «ОКБ им. Сухого» (Москва) и авиационные заводы Комсомольска-на-Амуре, Иркутска и Новосибирска. В 21 стране мира эксплуатировалось более 2,5 тысячи самолетов марки «Су». ВВС России были укомплектованы этими самолетами на 70 процентов.

25 сентября 1997 года поднялся в небо истребитель пятого поколения С-37 «Беркут» с крылом обратной стреловидности, тогда же прошли испытания легких одновигательных УБС С-54, истребителя С-55 и палубного С-56.

җитәкчелегендә һәм турыдан-туры катнашында төрле билгеләнештәге «Су-27», «Су-30», «Су-33», «Су-34», «Су-35» хәрби самолетлары һәм аларның күп төрле модификацияләре, «Су-26» спорт-пилот самолеты һәм аның модификацияләре, «С-80» пассажир самолеты, «Бөркет» исеме алган бишенче буын самолетының беренче прототибы булган «Су-47» эксперименталь самолеты, шулай ук «Су-30МК», «СУ-32НФ», «Су-37» самолетлары ясала.

Конструкторлык бюросы тарафыннан спорт-акробатик самолетларының тулы бер семьялыгы барлыкка китерелә. «Су-26» белән безнең пилотлар һава акробатикасы һәм пилотлау буенча дөнья чемпионатларында күп тапкыр җиңү яулыйлар. «Су-33» истребителе илебез авиатөзелеше тарихында беренче булып, «Советлар Союзы Флоты адмиралы Кузнецов» авиаөйрәтүче крейсеры палубасына төшеп утыра.

1995 елга Михаил Симонов җитәкләгән корпорациягә 32 предприятие, шул исәптән «Сухой исемендәге конструкторлык бюросы» АҖ (Мәскәү) һәм Комсомольск-Амур, Иркутск, Новосибирск авиация заводлары да керә. Дөньяның 21 илендә «Су» маркалы 2,5 мең самолет эксплуатацияләнә. Россиянең Хәрби-һава көчләре 70 процентка шушы самолетлардан тора.

1997 елның 25 сентябрендә һавага бишенче буын «С-37» «Бөркет» истребителе күтәрелә, шул вакытта ук бер

Неоценим вклад Михаила Симонова в развитие отечественного авиастроения. Он отмечен высокими государственными наградами, среди которых Ленинская премия, орден Трудового Красного Знамени, избирался народным депутатом СССР с 1969 года. Михаил Петрович – доктор технических наук, профессор Московского авиационного института, академик Международной и Российской инженерных академий. Его заслуги в развитии мировой авиации признаны не только у нас в стране: 8 апреля 1998 года ему присуждено почетное звание «Человек-легенда аэрокосмической промышленности», а его имя представлено в галерее Славы в Национальном музее авиации и космонавтики в Вашингтоне.

Указом Президента РФ от 25 сентября 1999 года за большой вклад в разработку новых образцов авиационной техники Симонову Михаилу Петровичу присвоено звание Героя Российской Федерации с вручением медали «Золотая Звезда».

Михаил Петрович руководил ОКБ им. П.О. Сухого до последних дней жизни, входил в совет директоров ОАО «Компания «Сухой». Жил в Москве, вырастил с женой сына и дочь. Скончался 4 марта 2011 года. Похоронен на Новодевичьем кладбище Москвы.

Президент Казанского технического университета (ныне КНИТУ им. А.Н.Туполева) Геннадий Дегтярев сказал: «Смерть Михаила Симонова – это огромная потеря для страны и авиационной отрасли. Михаил Петрович – это гордость России, гордость КАИ, он наш выпускник». Михаил Симонов очень любил КАИ, с удовольствием приезжал, встречался с преподавателями и студентами и с гордостью говорил, что он выпускник Казанского авиационного института. На юбилее Московского авиационного института, поздравляя коллектив вуза от имени ОКБ «Сухого», Михаил Петрович сказал: «МАИ готовит хороших авиационных конструкторов и инженеров, но лучших готовит КАИ».

Михаил Симонов оставил яркий след в авиации. Его имя вписано в историю наряду с фамилиями таких прославленных корифеев отечественного авиастроения, как Туполев, Яковлев, Ильюшин. Это была великая эпоха нашей авиации. Он стал главным конструктором Су-27, признанного лучшим истребителем конца XX века. Когда экономическая ситуация в стране в «лихие 90-е» стала катастрофической и из-за безденежья нависла угроза закрытия проекта создания для ВВС РФ Су-30, он настоял на «переквалификации» истребителя в машину коммерческого назначения. До него такое в голову никому не приходило. Так появился Су-30МК – модернизированный коммерческий.

Михаила Петровича нет более в живых, но в небе летают красавцы Су – живая память о выдающемся конструкторе и замечательном человеке.

моторлы җиңел «С-54», «С-55» истребителе һәм «С-56» палуба истребителе дә сынау уза.

Михаил Симоновның илебез авиатөзелеше үсешенә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Аңа Ленин премиясе, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кебек югары дәүләт бүләкләре бирелә. Ул 1969 елдан башлап СССР халык депутаты итеп сайлана. Михаил Петрович – техник фәннәр докторы, Мәскәү авиация институты профессоры, халыкара һәм Россия инженерлык академияләре академигы. Аның дөнья авиациясен үстерүдәге казанышлары чит илләрдә дә танылган: 1998 елның 8 апрелендә аңа «Аэрокосмос промышленностеның легенда-кешесе» дигән мактаулы исем бирелә, ә аның исеме Вашингтондагы Милли авиация һәм космонавтика музеенда Дан галереясында язып куелган.

РФ Президентының 1999 елның 25 сентябрендәге Указы нигезендә авиация техникасының яңа үрнәкләрен эшләүгә зур өлеш керткән өчен Симонов Михаил Петровичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Михаил Петрович П.О. Сухой исемендәге конструкторлык бюросы белән гомеренең соңгы көннәренә кадәр җитәкчелек итә, «Сухой» компаниясе» ААҖ Директорлар советына керә. Мәскәүдә яшәп, ул һәм кыз үстерә. 2011 елның 4 мартында вафат. Мәскәүнең Новодевичье зиратына җирләнгән.

Казан техник университеты (хәзер А.Н.Туполев исемендәге КНИТУ) президенты Геннадий Дегтярев болай ди: «Михаил Симоновның үлеме – илебез һәм авиация өлкәсе өчен чиксез зур югалту. Михаил Петрович – Россиянең горурлыгы, КАИның горурлыгы». Михаил Симонов КАИны бик яраткан, рәхәтләнеп килә, укытучылар һәм студентлар белән очраша һәм үзенең дә Казан авиация институтын тәмамлавы турында горурланып сөйли торган була. Мәскәү авиация институты юбилеенда вуз коллективын «Сухой» конструкторлык бюросы исеменнән котлаганда, Михаил Петрович: «МАИ яхшы авиация конструкторлары һәм инженерлары әзерли, ләкин иң яхшыларын КАИ әзерләп чыгара», – дип әйтә.

Михаил Симонов авиациядә якты эз калдырды. Аның исеме тарихка илебез авиатөзелешенең Туполев, Яковлев, Ильюшин кебек данлыклы корифейлары фамилияләре белән беррәттән язып куелган. Ул чор безнең авиациянең бөек эпохасы иде. Ул XX гасыр ахырының иң яхшы истребителе булып танылган «Су-27»нең баш конструкторы булган иде. Хәвефле туксанынчы елларда илдәге икътисадый вәзгыять катастрофа хәленә килеп, РФ Хәрби-һава көчләре өчен «Су-30» самолетын төзү проектына ябылу куркынычы яный башлагач, ул истребительне коммерциячел билгеләнештәге машинага әйләндерү тәкъдиме кертте. Бу фикернең әле беркемнең дә башына килгәне юк иде. Модернизацияләнгән коммерциячел «Су-30МК» шулай барлыкка килә. Михаил Петрович бу дөньяда юк инде, ләкин күктә, данлыклы конструктор һәм шәп кеше турындагы истәлек булып, гүзәл «Су»лар оча.







# СИРАЗЕТДИНОВ
## Тимур Галиевич

Родился 20 января 1969 года в Ленинграде. По окончании средней школы № 534 Выборгского района города поступил в Ленинградское высшее военное училище железнодорожных войск. Окончив училище, до 1990 года служил в Вооруженных Силах СССР, в должности командира взвода в Уральском соединении железнодорожных войск, а спустя год был направлен в распоряжение Главного управления исполнения наказаний по Ленинграду и Ленинградской области.

Уволившись из армии, около года проработал инженером в ассоциации малых предприятий северной столицы. В октябре 1993 года Тимур поступил на службу в отдел специального назначения ГУИН Минюста России по Санкт-Петербургу и Ленинградской области. Заочно окончил Академию МВД РФ и поступил в адъюнктуру при ней.

Неоднократно в составе сводного отряда направлялся в Северо-кавказский регион для участия в контртеррористических операциях. В августе-сентябре 1999 года освобождал от боевиков и иностранных наемников дагестанские села. Был тяжело ранен, но вернулся в строй.

В марте 2000 года бойцы отдела специального назначения «Тайфун», в числе которых находился капитан внутренних войск Тимур Сиразетдинов, будучи в очередной раз командированным в Чеченскую Республику, в районе населенного пункта Комсомольское вступили в ожесточенную схватку с бандой боевиков, захвативших село.

10 марта в ходе боя по освобождению села Комсомольское капитан внутренней службы Тимур Сиразетдинов

1969 елның 20 гыйнварында Ленинградта туа. Шәһәрнең Выборг районындагы 534 нче урта мәктәпне тәмамлагач, Ленинград тимер юл гаскәрләре югары хәрби училищесына укырга керә. Училищены тәмамлый һәм 1990 елга кадәр СССРның Кораллы Көчләрендә тимер юл гаскәрләренең Урал берләшмәсендә взвод командиры вазыйфасында хезмәт итә. Бер елдан соң Ленинград һәм Ленинград өлкәсе буенча Җәзаларны үтәтүнең баш идарәсе карамагына җибәрелә.

Армиядән кайткач, бер елга якын төньяк башкаланың кече предприятиеләр ассоциациясендә инженер булып эшли. 1993 елның октябрендә Тимур Россия Юстиция министрлыгының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе буенча ГУИН спецназ бүлегенә эшкә урнаша. Читтән торып РФ ЭЭМ академиясен тәмамлый һәм академия каршындагы адъюнктурага керә.

Җыелма отряд составында, террорчылыкка каршы операцияләрдә катнашу өчен, берничә тапкыр Төньяк Кавказ төбәгенә бара. 1999 елның август-сентябрендә Дагстан авылларын боевиклардан һәм чит ил наемникларыннан азат итә. Авыр яралана, ләкин стройга яңадан кайта.

2000 елның мартында аралларында Чечня Республикасына чираттагы командировкага җибәрелгән эчке гаскәрләр капитаны Тимур Сиражетдинов та булган «Тайфун» спецназ бүлеге сугышчылары Комсомольское авылы янында авылны басып алган боевиклар бандасы белән рәхимсез сугышка керәләр.



погиб, закрыв своим телом от осколков взрыва командира отряда.

Указом Президента РФ от 29 августа 2000 года за мужество и героизм при выполнении специального задания капитану внутренней службы Сиразетдинову Тимуру Галиевичу посмертно присвоено звание Героя Российской Федерации. При жизни он был награжден двумя орденами Мужества и медалью ордена «За заслуги перед Отечеством» 2-й степени.

Похоронен с воинскими почестями на аллее Славы Серафимовского кладбища Санкт-Петербурга.

Имя героя присвоено Санкт-Петербургской школе № 534, в которой он учился, на здании школы установлена мемориальная доска в память о нем. В школьном музее – большой стенд, посвященный его жизни и подвигу. Бюст Тимура Сиразетдинова установлен на Аллее Героев Санкт-Петербургского военно-транспортного университета железнодорожных войск России.

10 мартта Комсомольское авылын азат итү өчен барган сугышта, отряд командирын шартлау ярчыкларыннан үз гәүдәсе белән каплап, эчке гаскәрләр капитаны Тимур Сиражетдинов һәлак була.

Махсус задание үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2000 елның 29 августындагы Указы нигезендә эчке гаскәрләр капитаны Сиражетдинов Тимур Гали улына, үлгәннән соң, Россия Федерациясе Герое исеме бирелә. Исән чагында ул ике Батырлык ордены һәм 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнгән була.

Хәрби хөрмәт күрсәтеп, Санкт-Петербургта Серафимово зиратында Дан аллеясына җирләнә.

Геройның исеме Санкт-Петербургның 534 нче мәктәбенә бирелә, мәктәп бинасына аның истәлегенә мемориаль такта урнаштырыла. Мәктәп музеенда аның тормышына һәм батырлыгына багышланган зур стенд төзелә. Тимур Сиражетдиновның бюсты Россия тимер юл гаскәрләре Санкт-Петербург хәрби-транспорт университетының Геройлар аллеясына куелган.







# СИТКИН Константин Васильевич

Родился 13 июля 1975 года в Новотроицке Оренбургской области. Окончил в родном городе среднюю школу № 317. Вспоминая Костю и его брата Сашу, учительница литературы отмечала, какое заинтересованное участие принимали братья в обсуждении повести Приставкина «Ночевала тучка золотая», рассказывающей о трагедии чеченского народа, выселенного в годы Великой Отечественной войны из родных мест. «В глазах мальчиков я видела искреннее сочувствие, – делилась педагог. – Братья как будто предчувствовали, что в будущем судьба их свяжет с Чечней».

В семье их было трое: два брата и сестра. Отец работал на металлургическом комбинате, и парни планировали также связать свою судьбу с рабочей профессией. Поэтому они после школы продолжили образование в Новотроицком профессионально-техническом училище № 5, где в 1993 году получили специальность электросварщика.

После окончания училища близнецов Костю и Сашу призвали в армию.

Срочную службу они прошли вместе – сначала в Карталах, потом в Чечне. Вскоре пути их разошлись. Костя принял решение стать профессиональным военным, заключил контракт и несколько лет служил в 201-й миротворческой дивизии в Таджикистане. Здесь ему с товарищами пришлось повоевать на границе с бандами наркоторговцев. В боевых операциях в Таджикистане Константин, по отзывам командиров, проявил себя с самой лучшей стороны.

Больше года он пробыл в Чеченской Республике в период первой войны 1994-1996 гг. Затем поступил и успешно окончил Казанское высшее танковое училище, после которого был назначен командиром взвода 506-го гвардейского Познаньского мотострелкового полка 27-й гвар-

1975 елның 13 июлендә Оренбург өлкәсе Новотроицк шәһәрендә туа. Туган шәһәрендә 317 нче урта мәктәпне тәмамлый. Костяны һәм аның туганы Сашаны искә төшергәндә, Приставкинның Бөек Ватан сугышы елларында туган җирләреннән сөрелгән чечен халкы трагедиясе турындагы «Ночевала тучка золотая» повесте буенча фикер алышканда, малайларның бик кызыксынып катнашуларын әйтә әдәбият укытучысы. «Мин аларның күзләрендә ихлас жәлләү күрдем, – ди укытучы. – Әйтерсең лә туганнар киләчәктә үз язмышлары да Чечня белән бәйләнәчәген сизеп торган».


Алар гаиләдә өчәү була: ике малай һәм бер кыз. Әтиләре металлургия комбинатында эшли. Егетләр дә үзләренә эшче һөнәре сайларга планлаштыра. Шуңа күрә алар мәктәптән соң Новотроицкиның 5 нче һөнәри техник училищесына укырга керәләр. 1993 елны электр белән эретеп ябыштыручы һөнәрен алып чыгалар.

Училищены тәмамлагач, игезәк Костя һәм Сашаны армиягә алалар.

Армия хезмәтен алар икәү бергә – башта Карталда, аннары Чечняда уза. Шуннан соң аларның юллары аерыла. Костя профессиональ хәрби булырга карар итә, контракт төзи һәм берничә ел Таҗикстанда 201 нче тынычлык урнаштыру дивизиясендә хезмәт итә. Монда аңа иптәшләре белән бергә чиктә наркотик сатучылар бандаларына каршы сугышырга туры килә. Таҗикстандагы хәрби операцияләрдә, командирлары әйтүенчә, Константин үзен иң яхшы яктан күрсәтә.

1994–1996 еллардагы беренче сугыш вакытында ул Чечня Республикасында бер елдан артык тора. Аннары Казан югары танк училищесын уңышлы тәмамлап, Идел буе хәрби округы 27 нче гвардия Омск-Новобуг дивизиясе




дейской Омско-Новобугской дивизии Приволжского военного округа. Полк дислоцировался на Тоцком полигоне Оренбургской области.

В октябре 1999 года в составе полка младший лейтенант Ситкин прибыл в Чеченскую Республику. 25 октября перед полком была поставлена задача – форсировать реку Терек, неподалеку от Гудермеса, и захватить стратегические высоты Терского хребта. В ночном бою мотострелковый взвод младшего лейтенанта Ситкина скрытно обошел позиции боевиков и с тыла ворвался на рубежи обороны противника. В траншеях закипел жестокий рукопашный бой. Не ожидавшие столь дерзкого нападения боевики сопротивлялись недолго и поспешно отступили.

Командир взвода шел в бой впереди своих солдат, показывая пример мужества и отваги. В атаке на вражеские позиции геройски погиб командир отделения младший сержант Алексей Мороховец, закрывший собой командира взвода от автоматной очереди боевика и удостоенный за этот подвиг звания Героя России.

После этого боя Константин получил десятидневный отпуск на родину. По возвращении неожиданно заболел пневмонией и попал в госпиталь, но, не долечившись, вернулся в свою часть, которая в это время продвигалась к Грозному. В городе полк вел тяжелые бои. Приходилось штурмом брать каждый дом, каждую улицу. 18 января 2000 года во время продвижения полка к площади Минутка младший лейтенант Ситкин погиб от разрыва упавшей рядом мины. Через год он ушел бы в запас. Собирался жениться, у него была невеста. Он прожил всего 24 года. Героя похоронили на родине в Новотроицке.

За мужество и героизм, проявленные в ходе контртеррористической операции на территории Северо-Кавказского региона, указом Президента РФ от 12 апреля 2000 года гвардии младшему лейтенанту Ситкину Константину Васильевичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно). Медаль «Золотая Звезда» вручена родственникам героя.

Именем героя названа улица в его родном городе, а также профессионально-техническое училище № 5, которое он окончил, на здании которого установлена мемориальная доска. Его имя выбито на памятной стеле Героев, установленной у Дома офицеров Приволжско-Уральского военного округа в Самаре, а в 27-й Тоцкой гвардейской дивизии открыта комната Героя России Константина Ситкина.

506 нчы гвардия Познань мотоукчылар полкына взвод командиры итеп билгеләнә. Полк Оренбург өлкәсенең Тоцк полигонында урнашкан була.

1999 елның октябрендә кече лейтенант Ситкин полк составында Чечня Республикасына килеп төшә. 25 октябрьдә полк алдына Гудерместан ерак булмаган җирдә Терек елгасын кичеп, Терский сыртының стратегик биеклекләрен яулап алу бурычы куела. Төнге сугышта кече лейтенант Ситкинның мотоукчылар взводы, боевиклар позицияләрен әйләнеп узып, дошманның оборона сызыгына тылдан бәреп керә. Траншеяларда рәхимсез кул сугышы кайный. Мондый дорфа һөҗүмне көтмәгән боевиклар озак каршы торып маташмыйлар һәм тиз-тиз чигенәләр.

Взвод командиры, батырлык үрнәге күрсәтеп, солдатларының алдыннан бара. Дошман позицияләренә һөҗүм вакытында, взвод командирын үз гәүдәсе белән боевик автоматыннан каплаган отделение командиры кече сержант Алексей Мороховец батырларча һәлак була (бу батырлыгы өчен аңа Россия Герое исеме бирелә).

Шушы сугыштан соң Константин ун көнлек отпуск ала. Туган ягына кайткач, көтмәгәндә пневмония белән авырып китә һәм госпитальгә эләгә. Ләкин дәваланып бетмәгән килеш, Грозныйга таба хәрәкәтләнүче үз частена әйләнеп кайта. Шәһәрдә полк авыр сугышлар алып бара. Һәр йортны, һәр урамны штурмлап алырга туры килә. 2000 елның 18 гыйнварында полк Минутка мәйданына таба барганда, кече лейтенант Ситкин янәшәсенә төшеп ярылган минадан һәлак була. Тагын бер елдан ул запаска чыгачак иде. Сөйгән кызы була, өйләнергә җыена. Ул барлыгы 24 ел яшәп кала. Геройны туган шәһәре Новотроицкида җирлиләр.

Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операция барышында күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2000 елның 12 апрелендәге Указы нигезендә гвардия кече лейтенанты Ситкин Константин Васильевичка үлгәннән соң Россия Федерациясе Герое исеме бирелә. «Алтын Йолдыз» медале геройның туганнарына тапшырыла. Туган шәһәрендәге урам, шулай ук ул тәмамлаган 5 нче һөнәри-техник училище Герой исемен йөртә, училище бинасына мемориаль такта куелган. Аның исеме Самарадагы Идел буе-Урал хәрби округының Офицерлар йорты янында куелган Геройлар стеласына уеп язылган.







# СМИРНОВ Георгий Семенович

Родился в 1914 году в дер. Албаево Юлдузского (ныне Мамадышского района) Татарстана. В Казани медаль Героя России «Золотая Звезда» вручили детям летчика, погибшего в годы Великой Отечественной войны.

...Они знают своего отца исключительно по письмам и рассказам матери. Летчик Георгий Смирнов погиб в самом начале войны, он так и не узнал, что в 41-м у него родился ребенок. В своем последнем письме лейтенант будто чувствовал, писал жене Елене: если родится мальчик, назови Геной. Геннадий Смирнов спустя 67 лет вновь держит в руках фронтовые письма отца. Их уже не нужно читать, каждое из них он знает наизусть. В каждом письме отец писал, что Красная Армия разобьет фашистов, верил в победу.

Георгия Смирнова призвали на военную службу в 1935 году. Выпускник школы летчиков-наблюдателей в начале войны попадает в 81-й дальнебомбардировочный авиационный полк. Став командиром звена, он совершил 22 боевых вылета, сбросил на врага 17 тонн бомб, сбил три «мессершмидта», уничтожил четыре танка.

Летать на боевые задания в начале войны при подавляющем господстве в воздухе немцев было сложно. Ни одного вылета не обходилось без встречи с вражескими самолетами. Бомбардировщик ТБ-3 значительно уступал немецким истребителям в скорости, поэтому уклониться от боя не мог. И тем не менее экипаж, выполняя боевые задания в глубоком тылу и нанося противнику значительный

1914 елны Татарстанның Йолдыз (хәзер Мамадыш) районы Албай авылында туа.

Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган очучының балаларына Россия Героеның «Алтын Йолдыз» медален Казанда тапшыралар.

...Алар әтиләрен бары тик хатлар һәм әниләре сөйләве буенча гына белә. Летчик Георгий Смирнов сугышның башында ук һәлак була, 1941 елны малае туганны да белми кала. Үзенең соңгы хатында лейтенант, күңеле сизгәндәй, хатыны Еленага, малай туса, Гена дип исем куш, дип яза. Геннадий Смирнов 67 елдан соң әтисенең фронттан язган хатларын кабат кулына ала. Аларны инде укып торасы да юк: һәрберсен ул яттан белә. Әтисе һәр хатында, Кызыл Армия фашистларны тар-мар итәчәк, дип яза, җиңүгә ышана.

Георгий Смирновны хәрби хезмәткә 1935 елны чакыралар. Очучы-күзәтүчеләр мәктәбен тәмамлагач, сугыш башында 81 нче ерактан бомбага тотучы авиация полкына эләгә. Звено командиры буларак, ул 22 хәрби очыш ясый, дошман өстенә 17 тонна бомба ташлый, 3 «мессершмидт»ны бәреп төшерә, 4 танкны юк итә.

Сугыш башында һавада немецлар өстенлек иткәндә хәрби заданиеләргә очу катлаулы була. Дошман самолетлары белән очрашмыйча бер генә очыш та узмый. «ТБ-3» бомбардировщигы тизлектә немец истребительләреннән шактый калыша, шуңа күрә булдыра алганча, бәрелештән читләштергә тырыша. Шуңа да карамастан, ерак тылда



урон, не только защищался, но и отражал вражеские атаки.

Ночью 31 апреля 1941 года экипаж самолета ТБ-3 в составе командира звена младшего лейтенанта Г.Смирнова, стрелка-бомбардира лейтенанта В.Кирилловича, воздушного стрелка младшего сержанта А.Захарченко, стрелка-радиста младшего сержанта М.Сотова при возвращении с боевого задания получил множество пробоин. Был пробит основной бак, выведены из строя один из двигателей и радиостанция. На борту возник пожар. В районе своего аэродрома штурман с помощью ракеты запросил посадку, однако ответа с земли не последовало. Экипаж в темноте пытался отыскать свой аэродром. В четыре часа утра закончилось топливо, и командир совершил вынужденную посадку в районе села Северное Александровского района Орджоникидзевского (ныне Ставропольского) края. При посадке в условиях сильного тумана самолет врезался в склон оврага. После посадки Смирнов успел вынести из горящего самолета раненых членов экипажа и оказать помощь. Штурман Кириллович умер через 30 минут после посадки. Младший лейтенант Г.Смирнов и младший сержант М.Сотов были отправлены в Орджоникидзевский госпиталь. Младший сержант А.Захарченко не пострадал.

27 июня 1941 года в районе Ярославля экипаж бомбардировщика, преодолев противодействие зенитной артиллерии противника, с малой высоты уничтожил несколько вражеских танков. 5 июля, при полете в составе восьми самолетов в районе Белой Церкви, самолет Смирнова был заметно поврежден огнем с земли. Однако, несмотря на серьезные повреждения планера, экипаж Смирнова точно сбросил бомбы на цель и сбил один из атаковавших его истребителей противника.

хәрби заданиеләр үтәгәндә һәм дошманнарга зыян салганда, сакланып кына калмый, дошман атакаларын кире дә кайтара.

1941 елның 31 апрелендә экипажы звено командиры кече лейтенант Г.Смирнов, атучы-бомбардир лейтенант В.Кириллович, һава укчысы кече сержант А.Захарченко, укчы-радист кече сержант М.Сотов булган «ТБ-3» самолеты, хәрби заданиедән кайтканда, бик күп җирдән тишелә. Төп бакта тишек хасил була, моторларның берсе һәм радиостанция сафтан чыга. Бортта янгын башлана. Үз аэродромына җиткәндә штурман, ракета җибәреп, утырырга рөхсәт сорый, ләкин җирдән җавап килми. Караңгыда экипаж үз аэродромын эзләп табарга тырышып карый. Иртәнге сәгать дүрттә ягулык бетә һәм командир Орджоникидзе (хәзер Ставрополь) краеның Александровский районы Северное авылы тирәсендә төшеп утырырга мәҗбүр була. Төшкәндә көчле томан аркасында самолет чокыр кырыена килеп бәрелә. Смирнов яна башлаган самолеттан экипажның яралы әгъзаларын алып чыгарга һәм ярдәм күрсәтергә өлгерә. Штурман Кириллович төшкәннән соң 30 минут үткәч үлә. Кече лейтенант Г.Смирнов һәм кече сержант М.Сотов Орджоникидзе госпиталенә озатыла. Кече сержант А.Захарченкога зыян килми.

1941 елның 27 июнендә Ярославль тирәсендә бомбардировщик экипажы, дошманның зенит артиллериясе каршылыгын җиңеп, дошманның берничә танкын юк итә. 5 июльдә Ак Чиркәү районында сигез самолет составында очканда, Смирновның самолеты зур зыян күрә. Ләкин планерның җитди җимерелүенә дә карамастан, Смирнов экипажы бомбаларны тиешле урынына ташлый һәм үзләренә һөҗүм иткән дошман истребительләренең берсен бәреп төшерә.



Но бой не завершился. После ухода от цели самолет Смирнова вновь был атакован четырьмя немецкими истребителями. В этом противостоянии один из двигателей самолета был выведен из строя. Маневрируя на одном двигателе и сбивая скольжением пламя, экипаж продолжал отбиваться от наседавшего противника и сбил еще один немецкий самолет. Проявляя исключительную выдержку, хладнокровие и знание дела, Смирнов сумел горящий самолет с одним работающем двигателем довести до своей территории и благополучно посадить его. После посадки он вынес из самолета тяжелораненных членов экипажа и оказал первую помощь.

20 августа 1941 года в районе города Днепропетровска самолет Смирнова был подбит истребителями противника. Выполнив задание, пилот довел израненный самолет до своего аэродрома, дал возможность экипажу покинуть самолет, сам, получив ожоги, успел выпрыгнуть из горящего самолета.

5 ноября 1941 года Георгию Смирнову присвоили звание лейтенанта, но дожить командиру звена 81-го полка 50-й дальнебомбардировочной авиационной дивизии до получения новых знаков отличия не суждено было. Как и узнать о том, что дома у него родился сын. 9 ноября 1941 года Георгий Смирнов скончался от ран, полученных в бою и в результате вынужденной посадки подбитого самолета.

Лейтенант Г.С. Смирнов дважды представлялся к званию Героя Советского Союза в 1941-м при жизни и в 1942-м (посмертно) годах. Однако оба представления где-то затерялись.

После войны родственникам об этом стало известно, и они решили восстановить справедливость. Сначала в архивы отправилась вдова Смирнова, а затем его сын – Геннадий Смирнов. Поиски продолжались около 50 лет. За помощью Геннадий Смирнов обратился к Президенту Путину В.В.. Справедливость восторжествовала лишь через 67 лет после гибели.

Указом Президента РФ от 8 марта 2008 года за мужество и героизм, проявленные в Великой Отечественной войне 1941-1945 годов, лейтенанту Смирнову Георгию Семеновичу присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).

14 мая 2008 года в республиканском военкомате Татарстана в торжественной обстановке начальник управления кадров Приволжско-Уральского военного округа генерал-майор Виктор Мельников передал на хранение детям Смирнова, Галине Георгиевне и Геннадию Георгиевичу, золотую медаль отца. От имени ветеранской общественности Татарстана родственников героя-фронтовика приветствовали Герой Советского Союза Борис Кузнецов и председатель Комитета ветеранов войны и военной службы РТ генерал-майор Ахат Юлашев. В казанском Парке Победы, возле Вечного огня, среди 260 мраморных табличек с именами героев есть теперь и табличка с именем Героя России Смирнова Георгия Семеновича.

Ләкин сугыш тәмамланмый. Цельдән киткәннән соң Смирнов самолетына яңадан дүрт немец истребителе һөҗүм итә. Бу бәрелештә самолетның бер двигателе сафтан чыга. Бер двигатель белән маневр ясап һәм ялкынны сүндерергә тырышып, экипаж үзен эзәрлекләүче дошманнан котылырга маташа һәм шул шартларда тагын бер немец самолетын бәреп төшерә. Искиткеч ныклык, салкын канлылык һәм үз эшен белүен күрсәтеп Смирнов бер генә моторы эшләгән самолетның үзләре территориясенә алып кайтып җиткерә һәм әй     бәт кенә утырта ала. Утыргач, ул самолеттан экипажның авыр яралы әгъзаларын күтәреп чыга һәм беренче ярдәм күрсәтә.

1941 елның 20 августында Днепропетровск шәһәре тирәсендә Смирновның самолетына дошман истребительләре ата. Заданиене үтәгәч, пилот теткәләнеп беткән самолетын үз аэродромына алып кайта, экипажга самолетны ташлап чыгарга мөмкинлек бирә. Ә үзе тәннәре пешкән килеш, янып торган самолеттан сикерә.

1941 елның 5 ноябрендә Георгий Смирновка лейтенант исеме бирелә. Ләкин ерактан бомбага тотучы 50 нче авиация дивизиясенең 81 нче ерактан бомбага тотучы полкы звено командирына яңа билгеләр алганчы яшәргә насыйп булмый. 1941 елның 9 ноябрендә Георгий Смирнов сугышта һәм җимерек самолетын мәҗбүри утырту нәтиҗәсендә алган яралардан үлеп китә.

Лейтенант Г.С.Смирнов Советлар Союзы Герое исеменә ике тапкыр: исән чагында 1941 елны һәм үлгәннән соң 1942 елны тәкъдим ителә. Әмма ике тәкъдим дә каядыр югала.

Сугыш беткәч, туганнары бу хакта ишетә, һәм алар гаделлекне торгызырга карар итә. Башта архивларга Смирновның тол хатыны, аннары улы Геннадий йөри. Эзләү 50 елга сузыла. Ярдәм сорап, Геннадий Смирнов Президент В.В.Путинга да мөрәҗәгать итә. Гаделлек Георгий Смирнов һәлак булганнан соң 67 ел үткәч кенә торгызыла.

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 2008 елның 8 мартындагы Указы нигезендә лейтенант Смирнов Георгий Семеновичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелә (үлгәннән соң).

2008 елның 14 маенда Татарстанның республика хәрби комиссариатында тантаналы шартларда Идел буе-Урал хәрби округы кадрлар идарәсе начальнигы генерал-майор Виктор Мельников Смирновның балалары Галина Георгиевнага һәм Геннадий Георгиевичка әтиләренең алтын медален тапшыра. Татарстанның ветераннар җәмәгатьчелеге тарафыннан фронтовик геройның туганнарын Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов һәм ТР сугыш һәм хәрби хезмәт ветераннары комитеты рәисе генерал-майор Әхәт Юлашев сәламли. Казанның Җиңү паркында – Мәңгелек ут янында – геройлар исеме язылган 260 мәрмәр табличка арасында хәзер Россия Герое Смирнов Георгий Семенович исеме язылган табличка да бар.





# СУЛИМЕНКО Юрий Геннадьевич

Родился 20 апреля 1971 года в поселке Рудногорске Иркутской области. В 1988 году Юрий окончил школу. Встал вопрос о выборе пути. Сколько себя помнит, он всегда мечтал стать офицером. Ведь профессия военного в Советском Союзе считалась престижной, а офицер был примером для подражания, образцом мужества, образованности и порядочности.

В аттестате зрелости у юноши были только четверки и пятерки. Несмотря на то, что поблизости были военные училища, военком посоветовал поехать в Казань и поступать в танковое, которое окончил сам.

Отец одобрил выбор сына. Сказал лишь: «Уж если выбрал для себя столь нелегкий путь, то и пройти его ты должен самостоятельно с самого начала».

В 1992 году, окончив училище с красным дипломом, Юрий вместе со своими однокашниками был распределен в один танковый батальон во Владикавказ. В дороге молодые лейтенанты переживали, боялись, что должностей командиров взводов на всех не хватит. Но опасения были напрасными. В то время шел массовый вывод частей Советской Армии из бывших союзных республик, их переформирование. Офицеров не хватало, многие оставались в новообразованных государствах, поэтому все шестеро получили по взводу.

Развал Советского Союза накалил обстановку на его бывшей территории до предела. Северный Кавказ стал тем котлом, в котором заваривались межнациональные конфликты. Первым был грузино-абхазский вооруженный конфликт. Обе стороны старались завладеть оружием и боевой техникой, которая находилась на их территориях. Доходило до того, что нападали на российские колонны, уходившие на Родину.

Выводить кутаисскую парашютно-десантную бригаду в Ставрополь Сулименко поехал вместе с однокашником Андреем Ткаченко. Это был их первый боевой рейд. Шли по горному серпантину через Крестовый перевал под постоянным обстрелом, в том числе и снайперским. Водитель одной из машин был убит, и она сорвалась в ущелье, выпрыгнуть никто не успел.

За грузино-абхазским последовал осетино-ингушский конфликт. Задача российских военных заключалась в том, чтобы сдержать разрастание конфликта, предотвратить кровопролитие, защитить мирное население от насилия с обеих сторон. До 1994 года Сулименко с товарищами пришлось выполнять миротворческую миссию, отражая нападения с той и другой стороны. За миротворческую миссию Юрий и его однокашник Виктор Бабич были награждены медалью «За отвагу», почитаемой со времен Великой Отечественной войны.

До того как попасть в Чечню, Сулименко уже накопил некоторый боевой опыт. Приходилось под огнем выручать товарищей, вытаскивать из-под огня подбитые машины.

25 декабря 1994 года часть подняли по тревоге и своим ходом направили в Чечню. Никто не знал, что их ожидает на самом деле. Подлинная ситуация замалчивалась, а там шла настоящая кровопролитная война, с линией фронта, опорными пунктами и регулярными дудаевскими войсками, хорошо вооруженными и обученными.

Первый серьезный бой произошел за населенный пункт Октябрьское. Появились потери убитыми и ранеными. Отражая сопротивление противника, федеральные войска продвигались вперед. 29 декабря подошли к Промышленному району Грозного и с ходу атаковали противника. Через два дня комбату Сулименко было приказано возглавить штурмовой отряд, представлявший собой тан-

1971 елның 20 апрелендә Иркутск өлкәсенең Рудногорск бистәсендә туа. 1988 елда Юрий мәктәпне тәмамлый. Аның алдына һөнәр сайлау мәсьәләсе килеп баса. Ул һәрвакыт офицер булырга хыялланган була. Чөнки Советлар Союзында хәрби һөнәре абруйлы санала, ә офицерлар батырлык, белемлелек һәм тәртиплелек үрнәге булып тора.

Яшүсмернең өлгергәнлек аттестатында «4ле» һәм «5ле» билгеләре генә була. Якын тирәдә хәрби училищелар булуына да карамастан, военком аңа Казанга барырга һәм үзе тәмамлаган танк училищесына керергә киңәш итә.

Улының теләгенә әтисе дә каршы килми. Бары тик: «Үзеңә шундый авыр юлны сайлагансың икән, син аны башыннан ахырына кадәр үзең мөстәкыйль үтәргә дә тиеш», – дип кенә әйтә.

1992 елда училищены кызыл дипломга тәмамлаган Юрий, бергә укыган иптәшләре белән Владикавказдагы танк батальонына җибәрелә. Юлда барганда яшь лейтенантлар барысына да взвод командирлары вазыйфалары җитмәс дип борчылалар. Ләкин аларның куркуы юкка була. Ул вакытта совет армиясе частьларын элекке союздаш республикалардан чыгару һәм үзгәртү бара. Офицерлар җитми, күбесе яңа барлыкка килгән дәүләтләрдә калган була, шуңа күрә алтысына да берәр взвод эләгә.

Советлар Союзының таркалуы элек аныкы булган территориядә хәлне соңгы чиккәчә кыздыра. Төньяк Кавказ милләтара низаглар «пешә» торган казанга әверелә. Башта Грузия белән Абхазия арасында кораллы низаг килеп чыга. Ике як та үзләре территориясендә калган корал һәм хәрби техникага ия булырга омтыла. Хәтта Ватаннарына кайтып китүче Россия колонналарына һөҗүм итүгә кадәр барып җитә.

Кутаиси парашютчы-десантчылар бригадасын Ставропольгә чыгару өчен Сулименко курсташы Андрей Ткаченко белән бергә бара. Бу аларның иң беренче сугышчан рейды була. Бормалы тау сукмаклары буйлап Хач үткеле аша барганда, аларга снайперлар атып тора. Машиналарның берсенең йөртүчесе үтерелә һәм ул тарлавыкка мәтәлеп төшеп, сикерергә беркем дә өлгерми.

Аннары осетин-ингуш конфликты башлана. Россия хәрбиләренең бурычы бу низагны зурга җибәрмәү, кан коюны булдырмый калу, тыныч халыкны ике якның да көч кулланудан яклаудан гыйбарәт була. 1994 елга кадәр Сулименкога һәм аның иптәшләренә, ике яктан да ясалып торган һөҗүмнәрне кире кайтарып, тынычлык урнаштыру миссиясен үтәргә туры килә. Бу миссияләре өчен Юрий һәм аның иптәше Виктор Бабич Бөек Ватан сугышы вакытыннан ук дәрәҗәле саналган «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнәләр.

Чечняга килеп эләккәнче, Сулименко инде күпмедер хәрби тәҗрибә туплаган була. Ут астыннан иптәшләрен, снаряд тигән машиналарны алып чыгарга, сугышчан иптәшләрен пуля һәм снарядлардан үз гәүдәсе белән капларга туры килгәли.

1994 елның 25 декабрендә частьны тревога белән күтәреп, Чечняга чыгарып җибәрәләр. Алда нәрсә көткәнен беркем дә белми. Чын вәзгыятьне әйтмиләр, ә анда фронт сызыгы, яхшы коралланган һәм әзерлекле Дудаев гаскәрләре белән чып-чын канкойгыч сугыш бара торган була.

Беренче җитди сугыш Октябрьское авылы өчен була. Үтерелгән һәм яраланганнар барлыкка килә. Дошманның каршылыгын җиңә-җиңә, федераль гаскәрләр алга таба бара. 29 декабрьдә Грозныйның Промышленный районы-



ковый батальон, усиленный мотострелками. Майкопская бригада вошла в Грозный с северной стороны, отряд Сулименко – с северо-западной.

Дудаевцы встретили их шквальным огнем. Надо было срочно отойти от окружающих домов на открытое место, чтобы сохранить личный состав и технику. Замполит когда-то служил в Грозном и хорошо знал город, поэтому предложил войти в близлежащий парк. Машина комбата туда прорвалась первой, и отряд всю ночь вел там бой.

7 января танкисты прорвались к конференц-залу дворца Дудаева и закрепились на этом рубеже, но продвигаться дальше уже не было сил: две трети личного состава отряда вышло из строя, к тому же заканчивались горючее, боеприпасы, медикаменты и продовольствие. Поскольку снабжение отсутствовало, приходилось экономить каждый патрон, каждый снаряд, выбирались и уничтожались только самые важные цели. Дудаевцы, вооруженные в неограниченном количестве «мухами», «шмелями», зарядов не жалели. Противостоять им было трудно. Многие танки горели.

Танкисты, взаимодействуя с мотострелками, действовали профессионально, но ряды их таяли. Взятие каждого квартала влекло потери в живой силе. Танки практически оставались без прикрытия, и комбат с болью в сердце видел, как гибнут его подчиненные.

– Не было там ни безграмотных офицеров, ни неподготовленных солдат. Готов это заявить кому угодно, – вспоминает сегодня Юрий Геннадьевич. – Противник был серьезным, у него были новейшие противотанковые средства: орудия, минометы и гранатометы. Вели бои они грамотно – в составе боевых двоек и троек. Этому теперь учат в войсках. Но и тогда в уличных боях наши офицеры, среди которых было много ветеранов Афганистана, быстро освоили тактику действий мелких подразделений. Трижды не правы те, кто, не зная, как было на самом деле, обвиняли Российскую армию в том, что она бездарно воевала и несла неоправданные потери. В городе тогда не было мирных жителей. Там, казалось, стреляли в нас все. На стороне дудаевцев было много иностранцев, профессиональных наемников.

7 января танк Сулименко, поддерживая наступающие подразделения, прорвался к президентскому дворцу в центре Грозного. Сразу с нескольких сторон по машине ударили из гранатометов. В танк не попали, но отход ему перекрыл завал из груды кирпичей от взрывов гранат. Следующие выстрелы уже пришлись по машине, которую объяло пламя. Покинув танк, экипаж продолжал отбивать атаки огнем из автоматов. От очередной вражеской гранаты загорелось остававшееся в наружных баках танка топливо. Опасаясь взрыва, дудаевцы отступили. Это позволило экипажу спешно укрыться в ближайшем подъезде. И тут раздался сильный взрыв – это сдетонировал неизрасходованный боекомплект танка. Комбат получил осколочные ранения лица и рук. Ему перевязали, стянули скобами раны, но от эвакуации он отказался, поскольку кроме него в батальоне в строю не осталось ни одного офицера. Виктор Бабич был убит, командир танковой роты Лазорев тоже погиб, Полищук ранен и эвакуирован, старшего лейтенанта Горского Сулименко вынес на себе из боя. Последним из командиров подразделений остался старший лейтенант

на килеп җитәләр һәм килешли үк дошманга һөҗүм итәләр. Ике көннән соң комбат Сулименкога мотоукчылар белән ныгытылган танк батальоныннан гыйбарәт булган штурм отрядын җитәкләргә боерык бирәләр. Майкоп бригадасы Грозныйга – төньяктан, Сулименко отряды төньяк-көнбатыштан килеп керә.

Дудаевчылар аларны көчле ут белән каршы ала. Личный составы һәм техниканы саклап калу өчен, тиз арада йортлар яныннан ачык урынга китәргә кирәк була. Замполит кайчандыр Грозныйда хезмәт иткән булган, шуңа күрә шәһәрне яхшы белә, якындагы паркка керергә тәкъдим итә. Комбат машинасын анда беренче булып үтеп керә. Отряд төн буе сугыш алып бара.

7 гыйнварда танкистлар Дудаев сараеның конференцияләр залына үтеп керәләр һәм шунда урнашалар. Ләкин алга таба барырга инде хәлләре булмый: солдатларның өчтән икесе сафтан чыккан, җитмәсә ягулык, боеприпаслар, медикаментлар һәм азык-төлек тә бетеп килә. Тәэмин итү булмаганлыктан, һәр патронны, һәр снарядны саклап тотарга туры килә. Бары тик иң мөһим урыннар гына сайлап алына һәм юк ителә. «Чебен»нәр, «төклетура»лар белән чикләнмәгән күләмдә коралланган дудаевчылар патроннарны жәлләп тормый. Аларга каршы тору авыр була. Күп танклар яна.

Мотоукчылар белән танкистлар профессиональларча хәрәкәт итсәләр дә, рәтләре сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Һәрбер кварталны алу кешеләрне югалтуга китерә. Танклар бөтенләй диярлек каплаусыз кала. Үз кул астындагыларның һәлак булуларын күреп, комбатның йөрәге әрни.

– Анда белемсез офицерлар да, әзерлексез солдатлар да юк иде. Моны теләсә кемгә әйтә алам, – дип искә төшерә бүген Юрий Геннадьевич. – Дошман бик җитди һәм аның танкка каршы торучы иң яңа орудиеләре, минометлары һәм гранатометлары бар иде. Алар сугышны да бик белеп – икеле һәм өчле составта алып бардылар. Гаскәрләрдә хәзер шулай сугышырга өйрәтәләр. Хәер, ул чакта ук араларында Әфганстан ветераннары күп булган безнең офицерлар, урам сугышлары вакытында, вак подразделениеләр тактикасын тиз үзләштереп алдылар. Чынлыкта ничек булганлыгын белмәгән килеш, Россия армиясен мәгънәсез сугыш алып барган һәм акланмаган югалтуларга дучар булган, дип гаепләүчеләр мең кат хаксыз. Ул чакта шәһәрдә тыныч халык юк иде. Безгә барысы да аткан кебек тоелды. Дудаевчылар ягында чит илдән килгән профессионал наемниклар күп иде.

7 гыйнварда һөҗүмгә баручы подразделениеләргә ярдәм итә-итә, Сулименко танкы Грозный үзәгендәге Президент сарае янына үтеп керә. Машинага берьюлы берничә яктан гранатометлардан аталар. Танкка тидерә алмыйлар, ләкин гранаталар шартлаудан ишелеп төшкән кирпеч өеме аның чыгу юлын каплый. Шуннан соңгы атулар инде машинага тия, аны ялкын чолгап ала. Танктан чыккан экипаж, автоматлардан атып, һөҗүмнәрне кире кайтаруын дәвам иттерә. Дошман гранатасы тиюдән танкның тышкы бакларында калган ягулыкка ут элә. Шартлау булудан куркып, дудаевчылар чигенә. Моннан файдаланып, экипаж тиз генә якындагы подъездга кереп яшеренә. Шул чакта көчле шартлау яңгырый – танктагы кулланылмый калган боеприпасларга ут капкан була. Ярчыклар тиеп, комбатның йөзе һәм куллары яралана. Аның яраларын





Хламов, который вскоре также был ранен. Остался один Сулименко. Весь израненный, он занял место командира другого танка и вновь пошел в бой…

Под непрекращающимся огнем боевиков контуженного командира вынес с места сражения будущий Герой России старшина роты Виктор Величко. Комбата положили вместе с тяжело ранеными, и единственный, кто за ним ухаживал, был танкист из его батальона. Он узнал своего командира, хотя лицо Юрия представляло собой кровавое месиво. Когда за ранеными прилетел вертолет и медики стали транспортировать танкиста на борт, тот наотрез отказался лететь без командира. Так благодаря этому солдату Сулименко, не подававший признаков жизни, был эвакуирован. Ему пришлось сменить не один госпиталь, прежде чем выкарабкаться, казалось, с того света.

Указом Президента РФ от 15 мая 1995 года за мужество и героизм, проявленные при выполнении воинского долга, гвардии старшему лейтенанту Сулименко Юрию Геннадьевичу присвоено звание Героя России. После длительного излечения он продолжил службу старшим офицером в Управлении боевой подготовки штаба Московского военного округа.

бәйлиләр, скобалар белән тарттыралар. Ләкин эвакуацияләнүдән ул баш тарта, чөнки батальонда башка офицер калмаган була. Виктор Бабич үтерелгән, танк ротасы командиры Лазорев шулай ук һәлак булган, Полищук яраланган һәм эвакуацияләнгән, өлкән лейтенант Горскийны Сулименко сугыш кырыннан үзе күтәреп алып чыга. Подразделение командирларыннан соңгысы булып өлкән лейтенант Хламов кала, озакламый ул да яралана. Сулименко берүзе кала. Берничә җирдән яраланган килеш, ул икенче танкның командиры урынын ала һәм кабаттан сугышка керә…

Боевикларның өзлексез уты астында, контузия алган командирны сугыш кырыннан булачак Россия Герое рота старшинасы Виктор Величко алып чыга. Комбатны авыр яралылар янына яткызалар. Аның батальоныннан булган бер танкист командирын карап-тәрбияләп тора. Юрийның йөзе канлы ит кисәгенә әйләнгәнгә карамастан, танкист үз командирын таныган була. Яралыларны алып китәргә вертолет килгәч һәм медиклар әлеге танкистны бортка күтәрә башлагач, ул командирын калдырып очудан катгый рәвештә баш тарта. Яшәү билгеләре калмаган Сулименко шул солдат аркасында эвакуацияләнә. Теге дөньядан кире әйләнеп кайту өчен аңа берничә госпитальдә ятарга туры килә.

Хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1995 елның 15 маендагы Указы нигезендә гвардия өлкән лейтенанты Сулименко Юрий Геннадьевичка Россия Герое исеме бирелә. Озак дәвалангannan соң ул хезмәтен Мәскәү хәрби округы штабының Сугышчан әзерлек идарәсендә өлкән офицер булып дәвам иттерә.





# СУПОНИНСКИЙ Александр Анатольевич

Родился в 1979 году в селе Шешминка Черемшанского района Татарской АССР. Семья Супонинских в небольшом, на сорок дворов, селе известная и уважаемая. Саша и две его сестренки росли в тепле и заботе. Учились хорошо, помогали родителям в подсобном хозяйстве. В 1985 году Саша, окончив школу, поступил в Чистопольский совхоз-техникум. Активно занимался спортом, в основном единоборствами. Получив специальность техника-механика, осенью 1998 года добровольно пришел в военкомат и заявил: «Хочу в армию!» Мечтал попасть в воздушно-десантные войска, потому что «голубые береты» среди молодежи весьма престижны. Вышло так, как хотел.

Службу проходил в РДО – роте десантного обеспечения 104-го гвардейского парашютно-десантного полка 76-й Черниговской воздушно-десантной дивизии.

Три месяца обучения премудростям армейской службы в ВДВ пролетели незаметно. После учебы сержанта Супонинского распределили в 104-й парашютно-десантный полк в поселке Череха под Псковом. Время шло, некоторые из друзей в составе сводного батальона полка уже повоевали в Дагестане и вернулись в Псков, другие готовились к отправке в Чечню.

– У нас тогда было такое настроение: кто не воевал на Кавказе, тот как бы и не служил, – вспоминает Александр.– Собрались мы с сержантами и пошли к комбату подполковнику Евтюхину. Говорим ему, так, мол, и так, возьмите нас с собой в Чечню. Короче, уговорили мы его. Зачислил он нас в 6-ю роту, и скоро мы полетели в Моздок. Оттуда выехали в Чечню.

1979 елда Татарстан АССРның Чирмешән районы Чишмә авылында туа. Кырыклап кына йорттан торган кечкенә авылда Супонинскийлар гаиләсен барысы да хөрмәт итә. Саша һәм аның ике сеңлесе җылы мөнәсәбәт һәм кайгыртучанлык тоеп үсәләр. Әйбәт укыйлар, әти-әниләренә йортта булышалар. 1985 елда мәктәпне тәмамлагач, Саша Чистай совхоз-техникумына укырга керә. Спорт белән актив шөгыльләнә, бигрәк тә көрәшне ярата. Техник-механик белгечлеге алгач, 1998 елның көзендә хәрби комиссариатка килеп: «Армиягә барырга телим!» – дип әйтә. Һава-десант гаскәрләренә эләгергә хыялана, чөнки «зәңгәр беретлар» яшьләр арасында бик абруйлы була. Ул теләгенә ирешә.

76 нчы Чернигов һава-десант дивизиясе 104 нче гвардия парашютчы-десантчылар полкының десант тәэмин итү ротасында (РДО) хезмәт итә.

Һава-десант гаскәрләрендә (ВДВ) хезмәт итүнең нечкәлекләрен өйрәнгән өч ай сизелми дә үтеп китә. Өйрәнүләр тәмамлангач, сержант Супонинскийны Псков астындагы Череха бистәсендә урнашкан 104 нче парашютчы-десантчылар полкына җибәрәләр. Вакыт уза тора, полкның җыелма батальоны составында кайбер иптәшләре инде Дагстанда сугышып, Псковка әйләнеп кайта, башкалары Чечняга китәргә әзерләнә.

– Ул чакта безнең кәеф шундый иде: Кавказда сугышмаган кеше хезмәт итмәгән дә сыман, – дип искә ала Александр. – Без сержантлар белән җыелыштык та комбат подполковник Евтюхин янына киттек. Безне дә үзегез белән



Перед отлетом из части написал письмо родителям, сообщил, что еду в Чечню. Стояли там поначалу в Ведено, Ца-Ведено, затем выдвинулись в сторону Аргунского ущелья. Первое боестолкновение, в котором я принял участие, было 8 февраля. Тогда, после непродолжительной, но жесткой перестрелки боевикам пришлось отступить не солоно хлебавши.

Затем, до боя на высоте 776.0, серьезных столкновений не было, в основном боевики обстреливали наши блокпосты по ночам, иногда постреливали и днем, но – обходилось без потерь.

После падения Грозного в начале февраля 2000 года крупная группировка чеченских боевиков отступила в Шатойский район, где 9 февраля была блокирована федеральными войсками.

Шатой был последним крупным населенным пунктом Чечни, оставшимся в руках боевиков, хорошо укрепленным еще со времен первой войны 1994-1996 годов. После ожесточенных боев 22-29 февраля он был взят, и, как сочло федеральное командование, разбитые боевики должны были разделиться на небольшие отряды и рассредоточиться по горным базам.

Однако выбитые из Шатоя и других крупных узлов сопротивления отряды боевиков, в совокупности насчитывавшие около трех тысяч бойцов, сосредоточились в кулак. Большинство командиров боевиков, в том числе Шамиль Басаев и Хаттаб, предложили прорываться в северо-восточном направлении, к дагестанской границе. Несогласный с ними Руслан Гелаев с отрядом примерно в тыся-

Чечняга алып барыгыз әле, дидек. Кыскасы, ризалаттык без аны. Ул безне 6 нчы ротага кертте. Озакламый Моздокка очтык, аннан Чечняга киттек.


Частьтан очып китәр алдыннан, әти-әнигә хат язып, Чечняга барасымны хәбәр иттем. Анда башта Веденода, Ца-Веденода тордык, аннары Аргун тарлавыгы ягына кузгалдык. Мин катнашкан беренче сугышчан бәрелеш 8 февральдә булды. Ул чакта кыска гына, ләкин рәхимсез атышудан соң боевикларга чигенергә туры килде.

776,0 биеклегендәге сугышка кадәр җитди бәрелешләр булмыйча торды. Нигездә, боевиклар безнең блок-постларга төнлә, кайчак та көндез дә аткалыйлар иде, ләкин югалтулар булмады.

Грозный бирелгәннән соң 2000 елның февралендә чечен боевикларының зур төркеме Шатой районына чигенде, ә 9 февральдә федераль гаскәрләр тарафыннан камап алынды.

Шатой Чечняның боевиклар кулында калган, 1991–1996 еллардагы беренче сугыш вакытында ук әйбәт ныгытылган соңгы зур авылы иде. 22-29 февральдәге аяусыз сугышлардан соң ул яулап алынды. Федераль җитәкчелек фикеренчә, тар-мар ителгән боевиклар кечкенә-кечкенә отрядларга бүленеп, таулардагы базаларда урнашырга тиеш иде.

Ләкин Шатойдан һәм башка зур каршылык урыннарыннан бәреп чыгарылган өч меңгә якын боевик бер йодрыкка берләште. Боевикларның күп командирлары, шул исәптән Шамил Басаев һәм Хаттаб та төньяк-көнчыгыш юнәлешендә Дагстан чигенә таба барырга тәкъдим итәләр.



чу боевиков ушел на северо-запад – в сторону его родного Ачхой-Мартановского района. Там он рассчитывал, закрепившись в селе Комсомольское, начать широкомасштабную партизанскую войну на стыке горной и равнинной Чечни и Ингушетии. Басаев же и Хаттаб решили выполнить первоначальный план.

Командующий российской войсковой группировкой генерал Геннадий Трошев так позднее объяснил действия российского командования: «В феврале 2000 года мы подготовили бандитам неприятный сюрприз, когда в глубоком тылу, в районе Итум-Кале, высадили тактический десант. Тем самым был перерезан основной канал поставок вооружения и боеприпасов по горной дороге Итум-Кале – Шатили… И главари боевиков понимали, что здесь все их попытки оказать вооруженное сопротивление обречены. Согласно разведдонесениям, арабские наемники и чеченские ваххабиты под командованием Эмира Хаттаба двинулись северо-восточнее, в сторону Дачу-Борзой и Зоны.

Выбор места для прорыва из этого района у зажатого со всех сторон нашими частями Хаттаба был, мягко говоря, ограниченным. Чтобы пробиться во Веденский район, где у Хаттаба была разветвленная сеть небольших горных баз, ему нужно было двигаться на Сельментаузен вверх, либо по руслу реки Шароаргун, либо по руслу ее притока – реки Абазулгол.

Однако мы не могли тогда предположить, что противник рискнет пробиваться на восток крупными силами. Банды соединились – к отрядам арабских наемников «прилепились» банды других полевых командиров – Басаева, Вахи Арсанова, Багауди Бакуева, отряд «Джамаат»… Всего, как потом выяснилось, в районе Улус-Керта тогда сосредоточилось около полутора тысяч хорошо подготовленных боевиков».

28 февраля сводному отряду десантников под командованием гвардии подполковника Марка Евтюхина была поставлена задача: до 14:00 следующего дня завершить выход на рубеж в четырех километрах юго-восточнее Улус-Керта. Часть сил полка должна была блокировать район населенного пункта Сельментаузен и не допустить прорыва боевиков в направлении Махкеты, Киров-Юрта, Элистанжи, Ведено. Ранним утром 29 февраля 6-я рота, десантный взвод и группа полковой разведки начали выдвигаться к Урус-Керту. Рота должна была расположиться у выхода из ущелья на высоте 776,0 и не допустить прорыва.

Однако боевики пошли напролом. Здесь им преградила путь 6-я рота. Вот как об этом рассказывает Александр:

– Мы снялись с блокпостов во Веденском районе и начали выдвижение на рубеж на БМДэшках, затем, уткнувшись в горы, спешились, а техника вернулась на блокпосты. Роту повел вперед подполковник Евтюхин.

Обошли реку, долго шли вверх и дошли до высоты 776,0, где оставили один взвод. Разведка, а вслед за ними три взвода – отправились дальше. Насколько я понял, мой взвод должен был дойти до окраины Сельментаузена и закрепиться там, но в полдень разведдозор, выдвинувшийся в сторону горы Исты-Корд, столкнулся с группой боевиков. Завязался бой, и комбат во избежание потерь приказал всем отойти назад к высоте 776,0.

Аның белән килешмәгән Руслан Гелаев мең тирәсе боевиктан торган отряд белән төньяк-көнбатышка – үзе туып үскән Ачхой-Мартан районы ягына китә. Комсомольское авылында ныгып урнашып, таулы һәм тигезлекле Чечня белән Ингушетия чигендә ул партизан сугышын киң җәелдерергә уйлый. Ә Басаев һәм Хаттаб беренче планны тормышка ашырырга булалар.

Россия гаскәрләре төркеме командующие генерал Геннадий Трошев соңрак Россия командованиесе гамәлләрен болай аңлата: «2000 елның февралендә ерак тылдагы Итум-Кала районына тактик десант төшереп, без бандитларга көтелмәгән сюрприз әзерләдек. Итум-Кала – Шатили тау юлы буйлап корал һәм боеприпаслар китерүнең төп каналы ябылды… Боевикларның башлыклары монда кораллы каршылык күрсәтү омтылышларының җиңелүгә дучар булуын аңлый иде. Разведка мәгълүматларына караганда, Әмир Хаттаб җитәкчелегендәге гарәп наемниклары һәм чечен ваһһабчылары төньяк-көнчыгышка таба – Дачу-Борзой һәм Зона ягына юл тота.

Безнең частьлар белән бөтен яклап кысып китерелгән Хаттабның бу районнан чыгып китү юлы чикләнгән иде. Хаттабның кечерәк тау базалары челтәре урнашкан Веденский районына үтеп чыгу өчен аңа өскә таба Сельментаузенга, яки Шароаргун елгасы ярлары буйлап, яки аның кушылдыгы – Абазулгол елгасы ярлары буйлап хәрәкәт итәргә кирәк иде.

Ләкин ул чакта без дошман көнчыгышка таба зур-зур төркемнәр белән барырга җөрьәт итәр диеп башыбызга да китермәдек. Бандалар берләште – гарәп наемниклары отрядларына башка кыр командирлары – Басаев, Вахи Арсанов, Багауди Бакуев бандалары, «Җәмәгать» отряды килеп кушылды... Соңыннан билгеле булганча, Урус-Киртә районында ул вакытта мең ярымга якын яхшы әзерлекле боевиклар тупланган булган».

28 февральдә гвардия подполковнигы Марк Евтюхин командалыгындагы десантчылар җыелма отрядына шундый бурыч куела: киләсе көннең 14.00 сәгатенә кадәр Урус-Киртәдән дүрт чакрым көньяк-көнчыгышкарак чыгып җитәргә. Полк көчләренең бер өлеше Сельментаузен авылы тирәсен камап алырга һәм боевикларны Махкета, Киров-Юрт, Элистанжа, Введено юнәлешенә җибәрмәскә тиеш була. 29 февральдә иртән иртүк 6 нчы рота, десантчылар взводы һәм полк разведкасы төркеме Урус-Киртәгә таба кузгалды. Рота тарлавыктан чыккан җирдәге 776,0 биеклегенә урнашырга һәм боевикларның юлын бүләргә тиеш иде.

Ләкин боевиклар берни белән исәпләшмичә баруларын дәвам иттеләр. Монда аларның юлына 6 нчы рота төште. Бу хакта Александр менә нәрсәләр сөйли:

– Без Введено районында блокпостлардан кузгалып, БМДларга төялешеп, чиккә таба киттек. Аннары, тауга барып төртелгәч, җәяүгә калдык, ә техника блокпостларга кире китте. Ротаны подполковник Евтюхин алып барды. Елганы әйләнеп уздык, озак кына өскә таба бардык һәм 776,0 биеклегенә килеп җитеп, анда бер взводны калдырдык. Разведка, ә аның артыннан өч взвод алга таба киттек. Аңлавымча, минем взвод Сельментаузен читенә барып җитәргә һәм шунда урнашырга тиеш булган. Ләкин көн уртасында Исты-Корд тавы ягына киткән разведка дозоры боевиклар төркеме белән очрашкан. Сугыш башланып



Командир роты Молодов, который с группой бойцов пошел на помощь разведчикам, погиб один из первых от пули снайпера.

Боевиков было много, но точного количества я не знал, о том, что их там собралось более двух тысяч, впервые услышал только в госпитале.

Нас обстреляли из минометов и постепенно окружили. Лупили почти в упор из автоматов, пулеметов, гранатометов, месиво страшное. Когда мы забирали тело ротного, меня ранило – в колено вонзился осколок. Нас «трехсотых», сначала было пятеро, и комбат сразу организовал нашу эвакуацию. Мой лучший друг, младший сержант Костя Кривушев, рискуя жизнью, вытащил меня из под-огня и оказал первую помощь. Чуть позже он погиб, отличный был парень, жаль его очень.

Вечер был пасмурный, сырой, в метре от себя из-за тумана ничего не видно. Евтюхин попросил вертолетной поддержки, они прилетели, но помочь нам из-за отвратительных метеусловий не смогли. На следующее утро неожиданно пришла подмога – майор Доставалов и с ним еще 14 человек. Но «духи» шли на нас волнами, сменяя друг друга и не давая передышки. Со всех сторон крики, ругань, предложения сдаться, рукопашная, ребята гибли, боеприпасы заканчивались, из боеспособных на высоте нас осталось несколько человек: Евтюхин, Доставалов, капитан Романов, Поршнев и я. Боевики были всего в трех метрах, так близко, что я слышал их смех, брань, издевки. Не скрою,

киткән һәм, югалтуларны булдырмас өчен, комбат барысына да 776,0 биеклегенә кире чигенергә боерык биргән.

Сугышчылар төркеме белән разведчикларга ярдәмгә киткән рота командиры Молодов, беренчеләрдән булып, снайпер пулясыннан һәлак була.

Боевиклар күп иде, ләкин төгәл санын мин белмәдем. Аларның 2000 артык җыелганын госпитальдә ятканда гына ишеттем.

Безгә минометлардан аттылар һәм акрынлап камап алдылар. Туп-туры төзәп автоматлардан, пулеметлардан, гранатометлардан аттылар. Рота командирының гәүдәсен алып чыккан чакта мин яраландым – тезомә ярчык керде. «300ле»ләрдән без башта бишәү идек. Комбат тиз генә безне эвакуацияләүне оештырды. Якын дустым кече сержант Костя Кривушев, үз гомерен куркыныч астына куеп, мине ут астыннан тартып чыгарды һәм беренче ярдәм күрсәтте. Озак та үтми, ул һәлак булды. Бик кызганыч, шәп егет иде.

Кич болытлы, юеш, томан аркасында бер метр арадан берни күренми иде. Евтюхин вертолетлардан ярдәм сорады, алар очып килделәр, тик бик начар һава шартлары аркасында ярдәм итә алмадылар. Икенче көнне иртән көтмәгәндә ярдәм килде – майор Доставалов һәм аның белән 14 кеше. Ләкин «дух»лар безнең өскә дулкын-дулкын булып, берсен-берсе алмаштырып, сулыш алырга да ирек бирмичә килделәр. Бөтен яктан акыру, сүгенү, бирелергә тәкъдим итү ишетелеп тора. Кул сугышлары бара. Егетләр бер-бер артлы һәлак була, боеприпаслар бетеп бара.





было очень страшно. Комбат по рации стал вызывать огонь артиллерии на себя. И разрывы снарядов артиллерии попридержали боевиков.

Когда погибли Доставалов и Евтюхин, я пересчитал свои оставшиеся боеприпасы – оказалось шесть патронов… Капитан Романов, вставив последний рожок с патронами в автомат, сказал: «Кто-то должен выжить и рассказать о нас правду. Уходите, пацаны, я вас прикрою»… Всего 27 лет ему было, капитану… Я потом в Москве с его вдовой встречался, с дочерью, с родителями созванивался. Хорошие они люди.

Следуя приказу Романова, я поковылял вниз по склону, а Поршнев, контуженный, встал в полный рост и пошел. У него из ушей и носа кровь шла, он шел, качаясь из стороны в сторону. Боевики стреляли в упор из подствольников, но почему-то не попали. Может, они просто не захотели нас убивать, я не знаю… Овраг был извилистым, мы скрылись из зоны видимости, примерно через километр выползли на своих – шла запоздалая подмога.

Почти сразу за нами пришел Женя Владыкин. У него боеприпасы кончились, и в схватке он от удара автоматом в лицо упал, потерял сознание. Боевики приняли его за мертвого, раздели и бросили. Очнувшись от холода ночью полуголым, Женя надел чей-то бушлат и штаны и побрел вниз по реке. Потом нашелся Тимошенко. Он был ранен, весь в крови. Как выбрались Христолюбов и Комаров, я не знаю.

Биеклектә безнекеләрдән сугышырга яраклы берничә кеше генә калды: Евтюхин, Доставалов, капитан Романов, Поршнев һәм мин. Боевиклар бездән өч метр арада гына. Шулкадәр якын: аларның көлгән, сүгенгән, мыскыллаган тавышлары ишетелеп тора. Яшермим, бик куркыныч иде. Комбат рация аркылы артиллериядән безгә төбәп атарга боерды. Артиллерия снарядларының шартлавы боевикларны бераз тоткарлады.

Доставалов һәм Евтюхин һәлак булгач, мин үземнең боеприпасларымны санап карадым – алты патрон калган иде... Автоматына патронлы соңгы  мөгезне куйганда, капитан Романов: «Кем булса да исән калырга һәм безнең хакта дөреслекне сөйләп бирергә тиеш. Китегез, егетләр, мин сезне каплап торырмын», – диде. Капитанга нибары 27 яшь иде... Соңыннан Мәскәүдә мин аның тол хатыны белән очраштым, кызы һәм әти-әниләре белән телефоннан сөйләшеп тордым. Әйбәт кешеләр алар.

Романовның боерыгына буйсынып, мин, аксаклап, сөзәклек буйлап аска таба төшеп киттем. Ә контузия алган Поршнев бөтен буена торып басты да атлап китте. Аның колагыннан һәм борыныннан кан ага, үзе як-якка чайкала-чайкала бара иде. Боевиклар аңа туп-туры төзәп атсалар да, нишләптер тидерә алмадылар. Бәлки алар безне үтерергә теләмәгәннәрдер, белмим... Чокыр сырлы-сырлы иде, без күз күреме зонасыннан качтык.  Чама белән бер чакрым шуышып баргач, үзебезнекеләр янына чыктык – соңарган ярдәм килеп бара иде.

Безнең арттан ук диярлек Женя Владыкин килеп җитте. Аның боеприпаслары беткән һәм кул сугышы вакытында йөзенә автомат белән сугудан җиргә егылган, аңын югалткан. Боевиклар аны, үлгән дип белеп, чишендергәннән һәм ташлап калдырганнар. Суыктан төнлә ярымялангач килеш аңына килгән Женя кемнеңдер бушлатын, чалбарын алып кигән дә елга буйлап аска таба төшеп киткән. Аннары Тимошенко табылды. Ул яралы, бөтенләй канга баткан иде. Христолюбов һәм Комаров ничек чыкканнардыр – мин белмим.

Ничә боевик үлгән, һәлак булган безнекеләрне ничек алып чыкканнар, сугыш кыры нинди хәлдә булган – мин күрмәдем. Икенче көнне биеклеккә күтәрелгәннәр арасында булачак туганым – хатынымның туганнан туган энесе Сергей Захаров булган. Ротадан нәрсә калганлыгын ул сөйләде...

Мине Моздок госпиталенә, аннан Тверьга җибәрделәр. Терелгәч,  үземнең Псковтагы частемда хезмәт итеп бетердем. 2000 елның 3 августында запаска чыктым.

Александр сөйләгәнне тыңлагач, алар бернинди батырлык та күрсәтмәгән кебек тоела.  Боевиклар таләбе буенча бирелмәгәннәр, мең ярым бандитны тарлавыктан чыгармаганнар, штык һөҗүмендә сугышканнар, соңгы патронгача каршы торганнар. Ә боевиклар белән чагыштырганда алар бик аз  булган бит, барлыгы бер рота. Ләкин ул махсус рота шул – десант ротасы. Аның сугышчан ныклыгы бөтен дөньяны шаккатырды. Соңрак бу рота турында соклану тулы мәкаләләр, телевизион тапшырулар һәм фильмнар чыкты...

Террорчылар белән сугышта батырлык һәм каһарманлык күрсәтүләре өчен РФ Президентының 2000 елның 12 мартындагы Указы нигезендә 22 десантчыга Россия Герое исеме (алардан 21енә – үлгәннән соң) бирелә, 69 десант-





Сколько погибло боевиков, как забирали наших погибших, что из себя представляло поле боя – я не видел. В числе тех, кто на следующий день поднялся на высоту, был Сергей Захаров, мой будущий родственник – двоюродный братишка жены. Он и рассказал, что осталось от роты…

Меня эвакуировали в госпиталь в Моздок, оттуда в Тверь. После выздоровления дослуживал в родной части в Пскове. Уволился в запас 3 августа 2000 года.

Из рассказа Александра создается впечатление, что ничего героического они и не совершили. Не сдались по требованию боевиков, не пропустили полторы тысячи бандитов из ущелья, дрались в штыковой атаке, отбивались до последнего патрона. А ведь по сравнению с наседавшими боевиками их была горстка, всего одна рота. Но это была особая рота – десантная. Ее боевая стойкость потрясла весь мир. Это потом появятся и восторженные статьи, и телевизионные передачи, и фильмы об этой роте…

Указом Президента РФ от 12 марта 2000 года за мужество и героизм, проявленные в бою с террористами, 22 десантника были удостоены звания Героя России (из них 21 – посмертно), 69 десантников стали кавалерами ордена Мужества (63 из них – посмертно).

Итак, если обобщить все написанное о подвиге псковских десантников, картина предстает следующая. Разведывательный дозор шестой роты первым столкнулся с группой боевиков в 20-30 человек. Они потребовали их пропустить, мол, «командиры договорились». Старший лей-

чы Батырлык ордены кавалеры була (шуларның 63е – үлгәннән соң).

Псков десантчыларының батырлыгы турында бөтен язганнарны гомумиләштерсәк, шундый картина күз алдына килеп баса. Башта 6 нчы ротаның разведка дозоры 20-30 кешелек боевиклар төркеме белән очраша. Боевиклар үзләрен үткәреп җибәрүне таләп итәләр, «командирлар сөйләшкән» диләр. Өлкән лейтенант Алексей Воробьев шунда ук рация аша батальон подполковнигы Марк Евтюхин белән элемтәгә керә һәм хәлне аңлатып бирә. Ә ул десантчылар төркеме җитәкчелеге белән элемтәгә керә. Аннан боерык килә: боевикларга бирелергә тәкъдим итәргә яки барысын да үтерергә!

Евтюхинның командование белән рация аша сөйләшкәнен Хаттаб ишетеп калган һәм «десантчыларны җир йөзеннән себереп түгәргә!» дигән боерык биргән. Шулай итеп икенче көнгә дә сузылган сугыш башланып киткән. Командованиедән канга баткан ротага ярдәм җибәрүләрен бертуктаусыз сорап торсалар да, берни дә барып чыкмаган. 1 мартта төнге сәгать 3 тә сугыш инде 15 нче сәгать дәвам иткәндә чолганышта калучылар янына майор Александр Доставалов җитәкчелегендә 3 нче взводның 4 гвардиячесе үзбаш үтеп керәләр.

Иң критик мизгелдә бандитлар десантчылар позицияләренә бәреп кергәндә, подполковник Евтюхин утны үзләренә алырга дигән карар кабул итә. Нәтиҗәдә тәмуг утында бик күп бандитлар янып үлә, ләкин безнең егетләрдән дә исәннәр бармак белән санарлык кына кала.

тенант Алексей Воробьев срочно связался по рации с командиром батальона подполковником Марком Евтюхиным и доложил обстановку. Тот вышел на связь с командованием десантной группировки. Оттуда поступил приказ: предложить боевикам сдаться или всех уничтожить!

Разговор Евтюхина с командованием по радиоперехвату услышал Хаттаб и отдал приказ «десантников смести с лица земли!»

Разгорелся бой, продолжавшийся и на следующий день. Несмотря на постоянные просьбы к командованию прислать истекающей кровью роте подкрепление, ничего не вышло. В 3 часа ночи 1 марта, когда бой уже шел около 15 часов, к окруженным самовольно прорвались 14 гвардейцев из 3-го взвода во главе с майором Александром Доставаловым.

В критический момент, когда бандиты ворвались на позиции десантников, подполковник Евтюхин принимает решение вызвать огонь на себя. В результате в огненном пекле сгорели многие бандиты, но и наших ребят в живых осталось единицы.

– Нас, последних, оставалось пятеро – комбат Евтюхин, замкомбата Доставалов и старший лейтенант Кожемякин (или капитан Романов?). Офицеры. Ну и мы с Сашей, – вспоминал позднее Поршнев. – Евтюхин и Доставалов погибли, а у Кожемякина обе ноги были перебиты, и он нам руками подбрасывал патроны. Боевики подошли к нам вплотную, оставалось метра три, и Кожемякин нам приказал уходить, прыгать с обрыва вниз, а сам с автоматом остался прикрывать наш отход. Мы сначала ползком, потом на четвереньках, потом в полный рост стали уходить и чудом остались живы.

Утро после боя выдалось ясным. Над полем боя барражировал вертолет, и летчики передавали на землю, что боевики собирают тела гвардейцев и намереваются их куда-то вывезти. Тут же начавшимся авиационно-артиллерийским налетом разметало оставшихся боевиков, однако около 500 из них ушли в горы.

Погибшие десантники были уроженцами 47 республик, краев и областей России. Среди них был и наш соплеменник гвардии рядовой Бадретдинов Дмитрий Мансурович. Он родился в Оренбурге, откуда переехал в Набережные Челны, где и похоронен. Посмертно награжден орденом Мужества.

Непросто сложилась судьба шестерых выживших десантников. Пятеро получили ордена Мужества, а Александр Анатольевич Супонинский стал Героем России.

После увольнения в запас он долго не мог трудоустроиться. Потом жизнь потихоньку наладилась. С помощью тогдашнего помощника Президента РФ Александр получил бесплатную квартиру. С женой Людмилой растят двух дочерей и сына. Окончил нефтяной институт, работает в нефтяной компании «Татнефть».

В феврале 2011 года альметьевская средняя школа № 16 по желанию учащихся и педагогов стала называться школой имени Героя России Александра Супонинского. Учащиеся старших классов с учителями истории создали стенд, посвященный подвигу Александра и его товарищей-десантников. В городском музее воинов-интернационалистов открыта экспозиция с фотографиями и документами героя.

– Иң соңгылардан без бишәү калдык. – Комбат Евтюхин, комбат урынбасары Доставалов һәм өлкән лейтенант Кожемякин (әллә капитан Романовмы икән?). Офицерлар. Һәм Саша белән без, – дип искә төшерә соңрак Поршнев. Евтюхин һәм Доставалов һәлак булдылар, ә Кожемякин ике аякսыз калды. Шул килеш ул безгә куллары белән гранаталар ыргытып торды. Боевиклар безгә бик якын килделәр. Өч метрлар гына ара калгач, Кожемякин безгә китәргә, ярдан түбәнгә сикерергә боерды, ә үзе автоматы белән безне капларга калды. Без башта шуышып, аннары дүртаякланып, аннары торып басып киттек һәм могҗиза белән генә исән калдык.

Сугыштан соңгы иртә аяз иде. Кыр өстендә вертолет очып йөрде һәм очучылар боевикларның гвардиячеләр мәетләрен җыеп йөрүен һәм каядыр алып китәргә җыенуын хәбәр иттеләр. Шул мизгелдә үк анда йөргән боевикларны авиация-артиллерия һөҗүме төрле якка алып ташлады, ләкин аларның 500ләбе тауларга китә алды.

Һәлак булган десантчылар Россиянең 47 республикасы, крае һәм өлкәләреннән иде. Алар арасында милләттәшебез гвардия рядовое Бәдретдинов Дмитрий Мансур улы да бар иде. Ул Оренбургта туган, аннан Чаллыга күчкән. Шунда күмелгән дә. Үлгәннән соң Батырлык ордены белән бүләкләнә.

Исән калган алты десантчының язмышы да гади генә булмый. Бишесе Батырлык ордены ала, ә Александр Анатольевич Супонинский Россия Герое була.

Запаска чыкканнан соң ул озак вакыт эшкә урнаша алмый. Аннары тормышы акрынлап җайлана. РФ Президентының ул чактагы ярдәмчесе булышлыгы белән Александр бушлай фатир ала. Хатыны Людмила белән ике кыз һәм бер малай үстерәләр. Нефть институтын тәмамлый, «Татнефть» компаниясендә эшли.

2011 елның февралендә укучылар һәм укытучылар теләге белән 16 нчы Әлмәт урта мәктәбе Россия Герое Александр Супонинский исемендәге мәктәп дип йөртелә башлый. Өлкән сыйныф укучылары тарих укытучылары белән бергәләп, Александр һәм аның десантчы иптәшләре батырлыгына багышланган стенд төзиләр. Шәһәрнең хәрби интернационалистлар музеенда Геройның фотосурәтләре һәм документларыннан экспозиция ачыла.







## ТРОШЕВ Геннадий Николаевич

Родился 14 марта 1947 года в Грозном, где и прошло его детство. Там похоронены его родственники. Дед верой и правдой служил царю и Отечеству в Терском казачьем войске. Отец, Николай Николаевич Трошев, – кадровый офицер, военный летчик, участник Великой Отечественной войны, дошел до Берлина. Мать, Надежда Михайловна, – казачка. С молоком и рассказами матери Геннадий впитал в себя крепкие казачьи традиции, а поскольку учился в школе и рос вместе с мальчишками-чеченцами и ингушами, хорошо был знаком с нравами горцев, других народов Кавказа. Позже, отвечая на вопрос, каково ему, уроженцу Чечни, воевать в родных краях, тяжело вздохнув, отвечал: «Конечно, обидно. Конечно, тяжело воевать на своей земле, российской земле. Тем более там, где родился и вырос».

В 1965 году Трошев поступил на архитектурный факультет Московского института инженеров землеустройства, после смерти отца оставил учебу, но вскоре возвратился уже в Казанское танковое училище, которое окончил в 1969 году. В 1976 году окончил Академию бронетанковых войск им. Р.Я. Малиновского, а в 1988 году Академию Генштаба Вооруженных Сил СССР.

Геннадий Трошев служил на разных должностях в танковых войсках. Был командиром 10-й Уральско-Львовской добровольческой дивизии в Группе советских войск в Германии, с 1991 года – первый заместитель командующего танковой армией.

С 1994-го по 1997 год командовал 42-м Владикавказским армейским корпусом Северо-Кавказского военного округа.

1947 елның 4 мартында Грозныйда туа, бала чагы да шунда уза. Шунда аның туганнары күмелгән. Бабасы Терск казаклар гаскәрендә патшага һәм Ватанга намус белән хезмәт итә. Әтисе Николай Николаевич Трошев – кадровый офицер, хәрби очучы, Бөек Ватан сугышы ветераны, Берлинга кадәр барып җиткән. Әнисе Надежда Михайловна – казачка. Казакларның нык традицияләре Геннадийга әнисенең сөте һәм хикәяләре белән кергән. Чечен һәм ингуш балалары белән бергә үскән һәм бергә мәктәптә укыганлыктан тау халыкларының холкын әйбәт белә. Соңрак, Чечняда туып үскән кеше буларак, туган якларында сугышып йөрү кыендыр, дигән сорауга ул: «Күңел рәнҗи, әлбәттә. Үз җиремдә, Россия җирендә сугышу авыр, билгеле. Бигрәк тә үзең туган һәм үскән җирдә».

1965 елда Трошев Мәскәү җир төзү инженерлары институтының архитектура факультетына укырга керә. Әтисе үлгәч, укуын ташлый. Ләкин озакламый Казан танк училищесында укый башлый. Аны 1969 елда тәмамлый. 1976 елда Р.Я.Малиновский исемендәге Бронетанк гаскәрләре академиясен, ә 1988 елда СССР Кораллы Көчләре Генштабы академиясен тәмамлый.

Геннадий Трошев төрле вазыйфаларда танк гаскәрләрендә хезмәт итә. Совет гаскәрләренең Германиядәге төркемендә 10 нчы Урал-Львов ирекле дивизиясе командиры була. 1991 елдан – танк армиясе командующие беренче урынбасары.

1994 елдан 1997 елга кадәр Төньяк Кавказ хәрби округының 42 нче Владикавказ армия корпусы белән командалык итә.

В январе 1995 года по приказу министра обороны в район Грозного началась переброска армейских подразделений из большинства российских военных округов. Трошев был назначен командующим группировкой федеральных войск в Чеченской Республике. В том же году ему было присвоено звание генерал-лейтенанта.

С 1995-го по 1997 год он командует 58-й общевойсковой армией, а затем назначается заместителем командующего Северо-Кавказским военным округом. В августе 1999 года стал командующим группировкой федеральных войск в Дагестане. Именно ему было поручено командование операцией по очистке от исламских боевиков Кадорской зоны. Он разработал и осуществил операцию по блокированию и уничтожению бандформирований в селах Карамахи и Чабанмахи и освобождению Новолакского района Дагестана. Там Трошин показал себя не только как опытный военачальник, но и как хороший дипломат. Он вел переговоры со старейшинами населенных пунктов, через которые наступали его войска, находил у них поддержку и тем самым сохранил десятки жизней своих солдат.

В октябре 1999 года Геннадий Трошев был назначен командующим группировкой войск на Северном Кавказе.

Чеченцы относились к нему с уважением за личную храбрость. Он постоянно повторял: «Этот народ мне близок, эта земля мне родная, и я пришел сюда не для того, чтобы разрушать».

Осенью 1999 года он отправился в Гудермес для встречи с влиятельными братьями Ямадаевыми, занимавшими в армии Аслана Масхадова ключевые посты. Убедил тех, что воевать бессмысленно, что Гудермес федеральные войска все равно возьмут. В ноябре 1999 года группировка под командованием Трошева практически без боя заняла второй по величине город Чечни – Гудермес. В декабре того же года Трошева назначили первым заместителем командующего Объединенной группировкой войск.

4 декабря за мужество и героизм, проявленные при ликвидации незаконных вооруженных формирований, указом Президента РФ генерал-лейтенанту Геннадию Николаевичу Трошеву присвоено звание Героя России с вручением медали «Золотая Звезда».

За Трошевым шла постоянная охота боевиков. В 2000 году действовавший в то время совет полевых командиров боевиков Чечни объявил Трошева «военным преступником» и назначил за его голову награду.

14 января в районе Грозного был обстрелян вертолет МИ-8, на борту которого он летел. Вертолет получил серьезные повреждения, но пилоту удалось посадить подбитую машину рядом с родовым кладбищем генерала. Там похоронены его родственники – бабушка, сестра, дядя и тетя. Говорят, что генерал вылез из изуродованной машины и сказал: «Они спасли меня». Тут же пересел в другой вертолет и полетел дальше.

Геннадия Трошева можно считать одним из создателей чеченских спецподразделений Министерства обороны России. В январе 2000 года он прилетел на вертолете в аул Беной, расположенный в Веденском районе – оплоте мятежников. Здесь генерал вручил российский флаг одному из Ямадаевых – Джабраилу и приказал создать роту спецназа. В эту роту влились боевики Сулима Ямадаева, сделавшего войну своим смыслом жизни. Ямадаевцы стали громить ваххабитов по всей горной Чечне. Так появился батальон «Восток».

В феврале 2000 года Геннадию Трошеву присвоили звание генерал-полковника, а в апреле его назначили командующим ОГВ на Северном Кавказе, 31 мая – командующим войсками Северо-Кавказского военного округа.

За годы пребывания и борьбы на Северном Кавказе он насмотрелся на зверства боевиков, сам приговоренный ими к смерти был непримиримым борцом с бандитами. И когда 4 июля 2000 года появилось его интервью в газете «Известия», в правозащитных кругах поднялся шум. Он заявил в частности: «Да, я за смертную казнь для чеченских боевиков! Если на его совести убийства десятков, сотен людей – что ему еще?! Когда в бою убивают – это понятно, но когда взрывают дома с мирным населением! И что, пожизненное заключение? Ни в коем случае! Самую мучительную казнь! Я бы сделал так: собрал бы всех на площади, вздернул бы бандита – и пусть висит, пусть все видят! Даже слово «бандит» ему не подходит – это изверги!».

Во время первой и второй чеченских войн наблюдатели отмечали, что, будучи уроженцем Грозного, генерал Трошев, в отличие от многих своих коллег, старался договориться с местным населением о взятии населенных пунктов под контроль без боя и что стремление «напугать до смерти» никогда ему присуще не было.

За его спиной многотрудная офицерская карьера от курсанта училища и командира танкового взвода до командующего военным округом. Вереницы военных городков, кочевой быт, бесконечные учения, тревоги и редкие

1995 елның гыйнварында оборона министры боерыгы белән Грозный тирәсенә Россиянең күп хәрби округларыннан армия подразделениеләрен күчерү башлана. Трошев Чечня Республикасындагы федераль гаскәрләр төркеме командующие итеп билгеләнә. Шул ук елны аңа генерал-лейтенант званиесе бирелә.

1995 елдан 1997 елга кадәр ул 58 нче гомуми гаскәрләр армиясе белән җитәкчелек итә, ә аннары Төньяк Кавказ хәрби округы командующие урынбасары итеп билгеләнә. 1999 елның августында федераль гаскәрләрнең Дагстандагы төркеме командующие була. Кадор зонасын ислам боевикларыннан чистарту операциясенә командалык итү нәкъ менә аңа тапшырыла. Ул Карамах һәм Чабанмах авылларындагы бандформированиеләрне камап алып юк итү һәм Дагстанның Новолак районын азат итү операциясен уйлый һәм тормышка ашыра. Анда Трошин үзен тәҗрибәле хәрби җитәкче генә түгел, яхшы дипломат та итеп күрсәтә. Ул үз гаскәрләре үтәргә тиешле авылларның аксакаллары белән сөйләшүләр алып бара, алардан хуплау таба һәм шул юл белән уннарча солдатының гомерләрен саклап кала.

1999 елның октябрендә Геннадий Трошин Төньяк Кавказда гаскәрләр төркеме командующие итеп билгеләнә.

Чеченнар шәхси кыюлыгы өчен аны хөрмәт итәләр. Ул һәрвакыт: «Бу халык миңа якын, бу – минем туган җирем, мин монда җимерер өчен килмәдем», – дип кабатлый торган була.

1999 елның көзендә ул Аслан Масхадов армиясендә төп постларны биләүче бертуган Ямадаевлар белән очрашу өчен Гудермеска китә. Сугышуның мәгънәсе юклыгына, гаскәрләрнең Гудермесны барыбер алачагына тегеләрне ышандыра. 1999 елның ноябрендә Трошев командалыгындагы төркем сугышсыз-нисез диярлек Чечняның икенче дәрәҗәле шәһәре Гудермесны ала. Шул ук елның декабрендә Трошевны гаскәрләрнең Берләшкән төркеме командующиеның беренче урынбасары итеп билгелиләр.

Законсыз коралллы формированиеләрне юк итүдә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 4 декабрьдәге Указы нигезендә генерал-лейтенант Геннадий Николаевич Трошевка Россия Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Боевиклар Трошевка ау оештыралар. 2000 елда Чечня боевикларының кыр командирлары хәрби советы Трошевны хәрби җинаятьче дип игълан итә һәм аның башы өчен бүләк билгели.

14 гыйнварда Грозный тирәсендә ул очкан «МИ-8» вертолетына аталар. Вертолет яхшы ук зарарлана, ләкин пилот машинаны генералның туганнары зираты янына төшереп утырта. Анда аның туганнары – әбисе, сеңлесе, абзасы һәм түтие күмелгән. Җимерек машинадан чыккач, генерал: «Алар мине коткарды», – дип әйткән, имеш. Шунда ук икенче вертолетка күчеп утыра һәм очуын дәвам иттерә.

Геннадий Трошевны Россия Оборона министрлыгының чечен махсус подразделениеләрен оештыручыларның берсе дип санарга мөмкин. 2000 елның гыйнварында ул, вертолетта очып, фетнәчеләр тулган Введено районына урнашкан Беной авылына килә. Монда генерал Ямадаевларның берсенә – Җабраилга Россия флагын бирә һәм спецназ ротасын оештырырга боера. Бу ротага сугышны тормышының мәгънәсе дип санаган Сулим Ямадаев боевиклары да кушыла. Ямадаевчылар бөтен Чечня буенча ваһһабчыларны туздыра башлыйлар. «Көнчыгыш» батальоны шулай барлыкка килә.

2000 елның февралендә Геннадий Трошевка генерал-полковник званиесе бирәләр, ә апрельдә аны Төньяк Кавказдагы ОГВ командующие, 31 майда Төньяк Кавказ хәрби округының гаскәрләре командующие итеп билгелиләр.

Төньяк Кавказда яшәгән һәм сугышкан елларында ул боевикларның явызлыгын күп күрә. Үзе алар тарафыннан үлемгә хөкем ителгән буларак, бандитлар белән аяусыз сугыш алып бара. 2000 елның 4 июлендә «Известия» газетасында аның интервьюсы чыккач, хокук яклау органнары арасында гауга куба. Ул мондый сүзләр әйткән була: «Әйе, мин чечен боевикларына үлем җәзасы бирү яклы! Әгәр ул үзе унлаган, йөзләгән кешеләрне үтергән икән – аңа тагын нәрсә?! Сугыш вакытында үтерүне аңлыйм әле мин, ләкин тыныч халык яшәгән йортларны шартлатуны аңлый алмыйм! Нәрсә, гомерлек тоткынлыкмы? Һичкайчан да! Иң газаплы җәза бирергә кирәк! Мин болай эшләр идем: барысын да мәйданга җыеп, бандитны асар идем. Элenеп торa бирсен, барысы да күрсен! «Бандит» дигән сүз дә туры килми аңа, алар – ерткычлар!»

Беренче һәм икенче чечен сугышлары вакытындагы күзәтүчеләр шуны билгеләп үтә: Грозныйда туып үскәнлектән, башка күп хезмәттәшләреннән аермалы буларак, генерал Трошев җирле халык белән авылларны сугышсыз гына контрольгә алу турында сөйләшеп килешергә тырышкан, үләрлек итеп куркытырга омтылу аңа беркайчан да хас булмаган.



выходные. Только его родные и близкие знали цену этой «блестящей карьере», как потом напишут в его официальной биографии.

Трошев пережил тяжелый, мучительный распад формирований Советской Армии. Именно ему пришлось в спешном порядке сворачивать и выводить из Германии в Россию одну из наших танковых армий. С какой горечью он вспоминал о том, как, выполняя приказ, полки и дивизии оставляли прекрасно обжитые городки, отлично оборудованные полигоны и учебные центры и сотнями эшелонов двигались в никуда. В пустые поля, в палатки, под открытое небо, потому что деньги, выделенные на строительство военных городков и полигонов, бесследно исчезли, осели в карманах высокопоставленных воров.

И в этом развале и распаде генералу Трошеву фактически с нуля, в огне вспыхнувшей кавказской войны, пришлось формировать 58-ю армию. Ту самую, которая прошла через две чеченские войны, перемолов, разгромив и уничтожив многочисленные бандформирования, а потом за пять суток в августе 2008 года разметала подготовленную по натовским стандартам грузинскую армию.

В его сердце навсегда остался рубец позорного Хасавюрта, когда некий генерал, выслуживаясь перед своим кремлевским покровителем, одним росчерком пера подарил победу и огромное количество оружия в первой войне дудаевцам и подписал полную капитуляцию России. Трошев пронес на своих плечах страшный груз первой чеченской войны с ее бесконечным предательством военного и политического руководства, под улюлюканье «демократической» прессы, непрерывную травлю и постоянные угрозы физической расправы со стороны боевиков.

Многих блестящих офицеров, профессионалов своего дела сломало предательство, гнездившееся в верхах политического и военного руаководства России, и они выбрали отставку. Трошев же выстоял. Он вырос на Кавказе, знал хорошо эту землю, знал, что эта война не последняя. Уйти было легко. Но кто прикроет собой эту страшную рану? Опьяненный безнаказанностью и победой, начал раздуваться ичкерийский (дудаевский) нарыв, захватывая все новые и новые территории, расползаясь по всей стране.

Трошев остался, и все последующие годы он спокойно и основательно готовил российскую армию на Кавказе к будущей войне. В условиях полной нищеты, без денег, когда зарплаты военным не платили по полгода, он вместе с единомышленниками, рядом с которыми прошел первую чеченскую войну, смог сделать, казалось, невозможное – сохранить боеспособность Северо-Кавказского округа. И когда в августе 1999 года банда Басаева вторглась в Дагестан, она, вместо победного марша, попала в стальные тиски, где ее и уничтожили.

Оттуда, из дагестанских ущелий, началось возрождение России, которую, казалось, уже ничто не могло спасти от распада. Победы генералов Квашнина, Казанцева, Трошева, Шаманова, Булгакова позволили России вновь поверить в себя и начать подниматься с колен.

Там, на той второй чеченской войне, Трошев пережил то редкое чувство, что дается не многим генералам – триумф! Победу, одним из главных творцов которой он был сам. Награды генерала – признание его заслуг: Герой России, ордена «За заслуги перед Отечеством», «За военные

Ул авыр хезмәткә тиң офицер карьерасы училище курсантыннан һәм танк взводы командирыннан башлап, хәрби округ командующиена кадәр үткән. Бер-бер артлы алышынып торган хәрби шәһәрчекләр, күчмә тормыш, даими өйрәнүләр, тревогалар һәм бик сирәк эләккән ял көннәре. Аның рәсми биографиясенә язылган «ялт иткән карьера»ның бәясен бары тик туганнары һәм якыннары гына белгән.

Трошев Совет Армиясе формированиеләренең бик авыр һәм газаплы таркалышын башыннан кичергән. Безнең танк армияләренең берсен ашыгыч рәвештә җыеп алып, Германиядән Россиягә чыгарырга нәкъ менә аңа туры килә. Боерыкны үтәп полклар һәм дивизияләрнең менә дигән яшәү шартлары булган шәһәрчекләрне, бик яхшы җиһазландырылган полигоннарны һәм уку үзәкләрен калдырып китүләре һәм йөзләгән эшелоннарга төялеп, билгесезлеккә таба юл алганнарын тирән әрнү белән искә төшерә ул. Буш кырларга, палаткаларга, ачык һавага. Чөнки хәрби шәһәрчекләр һәм полигоннар төзергә бүлеп бирелгән акча эзсез югалган, югары дәрәҗәле урыннар биләүче караклар кесәсендә утырып калган була.

Шушы таркалу, кабынып киткән Кавказ сугышы шартларында Трошевка 58 нче армияне нульдән башлап оештырырга туры килә. Күп санлы бандформированиеләрне тар-мар итеп һәм юкка чыгарып, ике чечен сугышын узган, ә аннары 2008 елның августында биш тәүлек эчендә НАТО стандартлары буенча әзерләнгән Грузия армиясе пыран-заран китергән армия турында сүз бара.

Аның йөрәгендә гомерлеккә Хасавюрт хурлыгының җөе кала. Ул чакта Кремльдәге яклаучысы алдында яхшы булып күренергә теләп, беренче сугышта бер генерал каләменең бер сызыгы белән дудаевчыларга җиңү һәм бик күп корал бүләк иткән һәм Россиянең тулысынча капитуляция ясавына имза куйган иде. Трошев хәрби һәм сәяси җитәкчелек тарафыннан бертуктаусыз хыянәт ителгән беренче чечен сугышының куркыныч йөген күтәреп бара. «Демократик» матбугатның мыскыллы язмаларына, берөзлексез ясалган басымга һәм боевикларның үлем белән янавына түзәргә туры килә.

Россиянең сәяси һәм хәрби җитәкчелеге башына оялаган хаинлек бик күп шәп офицерларны, үз эшләренең профессионалларын сындырды һәм алар отставкага чыгуны сайладылар. Трошев исә чыдады. Ул Кавказда үскән, бу җирләрне яхшы белә. Әлеге сугышның соңгысы булмаганын да белә. Китү җиңел ул. Ләкин бу куркыныч яраны кем каплар соң? Ичкериянең (Дудаевның) җәзасызлык һәм җиңүдән исергән чуаны, яңадан-яңа территорияләрне яулап, бөтен ил буйлап таралып үскәннән-үсә иде бит.

Трошев кала, һәм шуннан соңгы елларда ул тынычлап һәм ныклап Кавказдагы Россия армиясен булачак сугышка әзерли. Хәерчелек, акчасызлык шартларында, хәрбиләргә яртышар ел хезмәт хакы түләмәгән чакта, ул беренче чечен сугышын бергә узган фикердәшләре белән бергә мөмкин булмастай тоелган эшне эшли – Төньяк Кавказ округының сугышка яраклылыгын саклап кала. 1999 елның августында Басаев бандасы Дагстанга бәреп кергәч, җиңү маршы урынына корыч кыскычларга килеп эләгә. Банданы шунда ук юк итәләр.

Таркалудан инде берни дә коткарып кала алмас кебек тоелган Россиянең тернәкләнүе шуннан – Дагстан тарла-





заслуги», Дружбы народов, «За службу Родине в Вооруженных Силах СССР», орден Петра Великого и другие. Он признан почетным гражданином городов Прохладный и Нальчик, Махачкалы и Шали.

Война в Чечне закончилась, и за признанием, наградами и стремительным взлетом последовала опала. Но генерал Трошев стойко пережил и ее. Не замкнулся, не озлобился, не пополнил собой ряды обиженных. Он просто принял новое дело и со всей энергией взялся за него. Почти шесть лет занимался возрождением казачества в России. «Ведь нам, казакам, делить нечего. Казаки были, есть и будут оплотом государства своего, опорой главы государства: раньше был царь, сегодня – президент. Сегодня казачество возрождается с единой целью: возрождаясь самим, возродить матушку-Россию». Поддержанный Советом войсковых и окружных атаманов, всеми войсковыми казачьими обществами, Трошев настаивал на принятии нового федерального закона «О государственной службе российского казачества» и добился поставленной цели – закон в нужной редакции, с должной правовой основой был принят в конце 2005 года.

Он написал три книги воспоминаний: «Моя война. Чеченский дневник окопного генерала», «Чеченский рецидив», «Чеченский излом», по которым можно изучать не только историю чеченских войн, но и историю Кавказа и

выкларыннан башлана. Генераллар Квашнин, Казанцев, Трошев, Шаманов, Булгаковның җиңүләре Россиягә кабаттан үзенә ышанырга һәм тезләнгән җиреннән күтәрелә башларга мөмкинлек бирделәр.

Икенче чечен сугышында Трошев бик сирәк генераллар гына кичерә торган триумф хисен кичерә. Генералның бүләкләре – аның казанышларын тану: Россия Герое исеме, «Ватан алдындагы казанышлар өчен», «Хәрби казанышлар өчен», Халыклар дуслыгы, «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, Бөек Петр ордены һәм башкалар. Ул Прохладный һәм Нальчик, Махачкала һәм Шәле шәһәрләренең мактаулы гражданинын булып таныла.

Ул өч хатирәләр китабы яза: «Минем сугыш. Окоп генералының Чечня көндәлеге», «Чечен рецидивы», «Чечен борылышы». Ул китаплар буенча чечен сугышларының тарихын гына түгел, Кавказ тарихын да, соңгы ике дистә ярым елда Россия армиясе тарихын да өйрәнергә була.

Ләкин Трошевның популярлыгы, аның бәйсез холкы хәрби җитәкчелекнең ачуын чыгара. Әйе, аның сугыш солдаты буларак, горурланырга хакы бар. Ул Себер хәрби округын җитәкләүдән баш тарта. Әгәр ризалашсам, Төньяк Кавказ округы хәрби хезмәткәрләрен, үземә ышанган чечен халкын саткан кебек булам, ди. Ләкин бу ярдәм итми. Бер тәүлектән соң ул Төньяк Кавказ хәрби округы белән

историю российской армии последних двух с половиной десятилетий.

Однако популярность Трошева, его независимый характер раздражали военное руководство. Да, он был гордым, но по праву боевого солдата. Он отказался возглавить Сибирский военный округ, заявив, что если согласится, то предаст этим военнослужащих Северо-Кавказского округа, чеченский народ, который верит ему. Не помогло. Через сутки он был освобожден от командования Северо-Кавказским военным округом и отправлен в распоряжение министра обороны с формулировкой: «за публичное обсуждение принимаемых руководством Вооруженных Сил страны решений». В войсках недоумевали: как могло случиться, что успешный, талантливый, любимый солдатами генерал, так много сделавший для мира на Кавказе, поспешно был снят со всех постов и отправлен в отставку?..

В феврале 2003 года Трошев стал советником Президента России по вопросам казачества. Планы у него были большие, но, к сожалению, реализовать их не суждено было. Генерал-полковник Трошев погиб в авиакатострофе 14 сентября 2008 года, когда летел из Москвы в Пермь…

Его похоронили 22 октября 2008 года с воинскими почестями на кладбище поселка Северный недалеко от Краснодара. Сразу же после авиакатастрофы СМИ распространили заявление президента Чеченской Республики Рамзана Кадырова, в котором, в частности, говорилось: «Будучи командующим Объединенной группой российских войск на Северном Кавказе, он очень болезненно переживал события, которые тогда происходили на его родине. Благодаря именно таким боевым генералам, как Геннадий Трошев, удалось спасти в те страшные годы большое количество военных и гражданских, хотя жертв могло быть намного больше. Он часто сам шел на переговоры со старейшинами и убеждал их повлиять на боевиков, старался разрешить ситуацию мирными способами».

Гибель генерала Трошева отозвалась болью не только у тех, кто его знал, кто воевал под его началом, но и в сердцах тысяч людей в городах и селах страны. Сегодня одна из улиц Грозного носит его имя. Дубликат Звезды Героя России и личные вещи генерала Трошева хранятся в кадетской школе в якутском поселке Чернышевский, на открытии которой 1 сентября 2008 года присутствовал генерал. Школе присвоено имя Трошева. На Кубани именем генерала Трошева назвали казачий кадетский корпус, в Волгоградской области – кадетскую школу-интернат. Именем Геннадия Трошева названа средняя школа в Нальчике, в которой он учился с 1958-го по 1965 год. В Смоленске новая улица названа именем генерала Трошева, а в Ростове-на-Дону на фасаде здания штаба Северо-Кавказского военного округа установлена мемориальная доска генерал-полковнику, одна из улиц в новом микрорайоне названа его именем.

На Кубани учрежден фонд памяти Трошева – некоммерческий фонд содействия развитию спорта и культуры «Дружба народов Северного Кавказа» имени Героя России генерал-полковника Геннадия Трошева. В фонд вошли ветераны военных действий, политики, артисты, бизнесмены, простые люди. Председателем фонда избрана Надежда Михайловна Трошева, мать героя-генерала.

командалыктан азат ителә һәм «илнең Кораллы Көчләре җитәкчелеге кабул иткән карарларны бөтен халык алдында тикшергән өчен» дигән сылтау белән оборона министры карамагына җибәрелә. Гаскәрләр аптырашта кала: уңышка ирешүчән, талантлы, солдатлары яраткан, Кавказда тынычлык урнаштыру өчен шулкадәр күп эш башкарган генерал, бөтен вазыйфаларыннан азат ителеп, ни сәбәпле отставкага җибәрелгән?..

2003 елның февралендә Трошев Россия Президентының казаклар мәсьәләләре буенча киңәшчесе итеп куела. Аның планнары зурдан була, тик кызганычка каршы, аларны тормышка ашыра алмый кала. Генерал- полковник Трошев 2008 елның 14 сентябрендә Мәскәүдән Пермьгә очканда, авиакатастрофада һәлак була...

Аны бик хөрмәтләп, 2008 елның 22 октябрендә Краснодардан ерак булмаган Северный бистәсе зиратына күмәләр. Авиакатастрофадан соң ук матбугат чаралары Чечня Республикасы Президенты Рамзан Кадыйров сүзләрен тарата. Анда болай диелә: «Төньяк Кавказда Россия гаскәрләренең берләшкән төркеме командующие буларак, ул үзенең туган ягында булган вакыйгаларны бик авыр кичерә иде. Геннадий Трошев кебек сугышчан генераллар аркасында ул куркыныч елларда бик күп хәрбиләрне һәм гади халыкны коткарып калу мөмкин булды. Корбаннар тагын да күбрәк булу ихтималы зур иде. Ул еш кына аксакаллар белән очрашуларга үзе йөрде һәм аларны боевикларга йогынты ясарга үгетләде, вәзгыятьне тыныч юллар белән җайга салырга тырышты».

Генерал Трошевның һәлакәте аны белгән, аның кул астында сугышкан кешеләрнең генә түгел, илнең күп шәһәр һәм авылларындагы меңнәрчә кешеләрнең йөрәкләрен әрнетте. Бүген Грозныйның бер урамы аның исемен йөртә. Россия Герое Йолдызының дубликаты, генерал Трошевның шәхси әйберләре Якутиядәге Чернышевский бистәсе кадет мәктәбендә саклана (2008 елның 1 сентябрендә генерал аның ачылышында катнашкан иде). Мәктәпкә Трошев исеме бирелә. Кубаньда генерал Трошев исеме белән казак кадет корпусын, Волгоград өлкәсендә кадет мәктәп-интернатын атап йөртәләр. Нальчикта Геннадий Трошев 1958 елдан 1965 елга кадәр укыган урта мәктәп аның исемен йөртә. Смоленскида яңа урамга генерал Трошев исеме бирелгән, ә Ростов-Донда Төньяк Кавказ хәрби округы штабы бинасы фасадына генерал–полковникка мемориал такта куелган, яңа микрорайондагы бер урамга аның исеме бирелгән.

Кубаньда Трошев истәлеге фонды – Россия Герое генерал–полковник Геннадий Трошев исемендәге «Төньяк Кавказ халыклары дуслыгы» дип аталган коммерциячел булмаган спорт һәм мәдәният үсешенә ярдәм фонды оештырылган. Фондка хәрби хәрәкәтләр ветераннары, сәясәтчеләр, артистлар, эшкуарлар, гади халык керә. Фондның рәисе итеп герой генералның әнисе Надежда Михайловна Трошева сайланган.







# ТУЛИН (Гизатуллин) Сергей (Риф) Загитович

Родился 11 сентября 1957 года в деревне Малые Гайны Миякинского района Башкирской АССР в крестьянской семье. Мысль о поступлении в суворовское училище у подростка возникла после просмотра фильма «Офицеры». И вот в 1974 году после окончания 9 классов Риф был зачислен в Казанское суворовское военное училище во 2-ю роту майора Алексея Рябова. В период учебы Риф ходил в секцию по парашютным прыжкам, и к выпуску в 1976 году в его активе было три прыжка с парашютом.

По окончании суворовского Риф поступил в Рязанское высшее воздушно-десантное командное училище. С 1980-го по 1987 год проходил службу в отдельной десантно-штурмовой бригаде Прикарпатского военного округа, вначале в качестве командира взвода, потом разведроты, затем начальника штаба батальона, командира десантно-штурмового батальона. После окончания в 1990 году Военной академии имени М.В. Фрунзе гвардии майор Гизатуллин служил заместителем командира 38-й отдельной воздушно-десантной бригады в Белорусском военном округе. После распада Советского Союза офицер продолжил службу в Вооруженных Силах Российской Федерации. В 1992-1993 годах служил начальником штаба 554-го отдельного пехотного батальона в составе миротворческих войск ООН в Югославии.

1957 елның 11 сентябрендә Башкортстан АССРның Миякә районы Кече Гайнә авылында крестьян гаиләсендә туа. «Офицерлар» фильмын караганнан соң яшүсмердә Суворов училищесына укырга керү теләге туа. 1974 елны 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң Риф Казан Суворов хәрби училищесына майор Алексей Рябовның 2 нче ротасына кабул ителә. Укыганда Риф парашют белән сикерү секциясенә йөри, 1976 елда укуын тәмамлаган вакытка ул инде өч тапкыр парашют белән сикергән була.

Суворов училищесын тәмамлагач, Риф Рязань югары һава-десант команда училищесына укырга керә. 1980 елдан 1987 елга кадәр Прикарпатье хәрби округының аерым десантчы-штурмлаучылар бригадасында башта взвод командиры, аннары разведка ротасы командиры, соңрак батальон штабы начальнигы, десантчы-штурмлаучылар батальоны командиры булып хезмәт итә. 1990 елда М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлаганнан соң гвардия майоры Гыйззәтуллин Белорусия хәрби округында 38 нче аерым һава-десант бригадасы командиры урынбасары булып хезмәт итә. Советлар Союзы таркалгач, офицер хезмәтен Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә дәвам итә. 1992-1993 елларда БМОның Югославиядәге тынычлык урнаштыручы гаскәрләре составында 554 нче аерым пехота батальоны штабы начальнигы була.

В 1992 году Гизатуллин Риф Загитович официально изменил фамилию и имя и стал Тулиным Сергеем Загитовичем. С 1993 года подполковник Тулин командовал 104-м полком 76-й гвардейской воздушно-десантной дивизии, расквартированной в Пскове.

События на Северном Кавказе начала девяностых годов не обошли стороной боевого офицера. С декабря 1994-го по май 1995 года во главе батальонной тактической группы полка Сергей Тулин участвовал в боевых действиях в Чечне, в том числе в штурме Грозного, где командовал передовым отрядом 76-й воздушно-десантной дивизии в составе группировки «Запад».

Передовой отряд совершил сложнейший переход через горный хребет, захватил рубеж в трех километрах юго-западнее Грозного, уничтожив при этом танк и 28 боевиков, и вывел главные силы дивизии к городу. За умелое руководство воинскими подразделениями Сергенй Тулин был награжден орденом Мужества.

Парашютно-десантный полк, которым командовал подполковник Тулин, освобождал от боевиков город Гудермес. В ходе блокирования Гудермеса боевой офицер, несмотря на контузию, оставался в строю, управлял боем. В течение недели полк сдерживал атаки боевиков, но позиций не оставил.

Указом Президента РФ от 20 июля 1996 года за умелое руководство боевыми действиями полка, мужество и героизм, проявленные при исполнении воинского долга в Северо-Кавказском регионе, полковнику Тулину Сергею Загитовичу присвоено звание Героя России с вручением медали «Золотая Звезда».

В 1997-1998 гг. Сергей Загитович – офицер Главного управления международного военного сотрудничества Генштаба Вооруженных Сил РФ. В 2000 году окончил Военную академию Генштаба. В 2000-2001 годы – командир 205-й отдельной мотострелковой бригады, дислоцированной в Буденновске Ставропольского края, через год назначается заместителем командующего 58-й армией Северо-Кавказского военного округа в Северной Осетии во Владикавказе.

С 2002 года генерал– майор С.З. Тулин работал военным комиссаром Рязанской области. В 2007 году вышел в запас.

Сергей Загитович всегда рад бывать в стенах Казанского суворовского училища. В один из своих приездов в Казань в книге почетных гостей училища он оставил такую запись: «Я горд, что учился в Казанском суворовском! Для меня, сына крестьянина, – это все!!! Все, чего достиг в жизни, – это благодаря тому фундаменту, который заложили в меня в стенах родного Казанского СВУ. Желаю коллективу училища удачи, успехов!

Сергей Тулин,
27 июня 2002 года».

1992 елда Гыйззәтуллин Риф Заһит улы рәсми рәвештә фамилиясен үзгәртә һәм Тулин Сергей Заһит улы булып йөри башлый. 1993 елдан подполковник Тулин Псковта урнашкан 76 нчы гвардия һава-десант дивизиясенең 104 нче гвардия парашютчы-десантчылар полкына командалык итә.

Төньяк Кавказдагы 1990 нчы башындагы вакыйгалар хәрби офицерны читләтеп үтми. Полк батальонының тактик группасы башында 1994 елның декабреннән 1995 елның маена кадәр Сергей Тулин Чечнядагы сугыш хәрәкәтләрендә, шул исәптән Грозныйны штурмлауда да катнаша, «Көнбатыш» төркеме составында 76 нчы һава-десант дивизиясенең алдынгы отрядына командалык итә.

Алдынгы отряд, бик катлаулы тау сыртын үтеп чыгып, Грозныйдан көньяк-көнбатышка таба өч чакрым ераклыктагы сызыкны яулап ала. Шул вакытта боевикларның бер танкын һәм 28 кешесен юкка чыгара. Һәм дивизиянең төп көчләрен шәһәр янына алып чыга. Хәрби подразделеңиеләр белән оста җитәкчелек иткән өчен Сергей Тулин Батырлык ордены белән бүләкләнә.

Тулин җитәклэгән парашютчы-десантчылар полкы Гудермес шәһәрен боевиклардан арындыра. Гудермесны камап алу барышында, контузия алган булуына карамастан, хәрби офицер стройда кала, сугышны идарә итә. Полк боевиклар һөҗүмнәрен атна буе тоткарлап тора, позицияләрен ташлап китми.

Полкның сугыш хәрәкәтләренә оста җитәкчелек иткәне, Төньяк Кавказ төбәгендә хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1996 елның 20 июлендәге Указы нигезендә полковник Тулин Сергей Заһит улына Россия Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

1997-1998 елларда Сергей Заһит улы – РФ Кораллы Көчләре Генштабының Халыкара хәрби хезмәттәшлек баш идарәсе офицеры. 2000 елда Генштабның Хәрби академиясен тәмамлый. 2000-2001 елларда – Ставрополь крае Буденновск шәһәрендә урнашкан 205 нче аерым мотоукчылар бригадасы командиры. Бер елдан соң Төньяк Осетиянең Владикавказдагы Төньяк Кавказ хәрби округы 58 нче армиясе командующиеның урынбасары итеп билгеләнә.

2002 елдан генерал-майор С.З.Тулин Рязань өлкәсе хәрби комиссары булып эшли. 2007 елда запаска чыга.

Сергей Заһит улы, бик шатланып, Казан Суворов училищесына килеп йөри. Казанга бер килүендә училищеның мактаулы кунаклары китабында ул мондый язу калдыра: «Мин Казан Суворов училищесында укыганым белән горурланам! Миңа, крестьян улына, ул барысын да бирде!!! Тормышымда ирешкән бөтен нәрсә – Казан Суворов училищесында миңа салынган нигез аркасында. Училище коллективына уңышлар телим!

Сергей Тулин,
2002 елның 27 июне».







# УРАЗАЕВ Игорь Кабирович

Родился 28 февраля 1960 года в поселке Печенга Мурманской области в семье военного. Отец, Кабир Камильевич, окончил Киевское артиллерийское училище, мать, Надежда Александровна, работала на фабрике шелковых тканей. В 1978 году Игорь окончил одиннадцать классов средней школы в Могилеве. В мае того же года его призвали на срочную службу в ряды Советской Армии. После окончания школы младших командиров службу проходил в 80-й отдельной разведроте 103-й гвардейской воздушно-десантной дивизии в Витебске в должности командира отделения. Участвовал в боевых операциях в Афганистане в составе Ограниченного контингента советских войск.

В мае 1980 года Игорь уволился в запас. Но недолго пробыл «на гражданке»: уже в следующем году поступил в Новосибирское высшее военно-политическое общевойсковое училище. После окончания училища в 1985 году служил в 104-м гвардейском парашютно-десантном полку 76-й гвардейской воздушно-десантной дивизии, дислоцированной в Пскове.

В декабре 1994 года воздушно-десантный полк был переброшен в Чечню. В разгар кровопролитных новогодних боев рота капитана Уразаева участвовала в штурме Грозного. Десантники капитана Уразаева прорвались в центральную часть города для оказания помощи 131-й мотострелковой бригаде, понесшей тяжелые потери в районе

1960 елның 28 февралендә Мурманск өлкәсе Печенга бистәсендә хәрби хезмәткәр гаиләсендә туа. Әтисе Кәбир Камил улы Киев артиллерия училищесын тәмамлаган, әнисе Надежда Александровна ефәк тукымалар фабрикасында эшли. 1978 елны Игорь Могилевта урта мәктәпнең 11 сыйныфын тәмамлый. Шул ук елның маенда аны Совет Армиясенә хәрби хезмәткә алалар. Кече командирлар мәктәбен тәмамлагач, Витебскидагы 103 нче гвардия һава-десант дивизиясенең 80 нче аерым разведка ротасында отделение командиры вазыйфасында хезмәт итә. Совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты составында Әфганстандагы хәрби операцияләрдә катнаша.

1980 елның маенда Игорь запаска чыга. Ләкин «гражданка»да озак йөрми, киләсе елны ук Новосибирск югары хәрби-сәяси гомумгаскәрләр училищесына укырга керә. Училищены тәмамлаганнан соң, 1985 елны, Псковта урнашкан 76 нчы гвардия һава-десант дивизиясенең 104 нче гвардия парашютчы-десантчылар полкында хезмәт итә.

1994 елның декабрендә һава-десант полкы Чечняга күчерелә. Яңа ел башындагы канкойгыч сугышларның иң кызган чагында капитан Уразаевның ротасы Грозныйны штурмлауда катнаша. Капитан Уразаевның десантчылары тимер юл вокзалы тирәсендә авыр югалтуларга дучар булган һәм 131 нче мотоукчылар бригадасына ярдәм итү



железнодорожного вокзала. В ходе боя капитан Уразаев получил контузию, но продолжил командовать ротой. Подразделение выбило дудаевцев из укрепленного и тактически выгодного здания и оборудовало в нем свой опорный пункт.

Трое суток гвардейцы Уразаева удерживали это здание. Неоднократно боевики предпринимали попытку вернуть его. Их атаки следовали одна за другой, в том числе и с применением бронетехники. Здание обстреливалось из всех видов оружия. Но все атаки были отражены, при этом до 150 боевиков выведены из строя. Гвардейцы Уразаева подбили 3 танка дудаевцев, 6 боевых машин пехоты, уничтожили 7 крупнокалиберных пулеметов с расчетами, захватили два склада с боеприпасами и взяли в плен до 150 боевиков. Командир роты Уразаев постоянно находился на самых опасных участках обороны, умело расставлял солдат. Своим личным примером он поддерживал боевой дух солдат, уничтожил до 20 боевиков. В бою 9 января 1995 года Уразаев получил вторую контузию, на этот раз тяжелую, лишившую его речи. Но и в этом случае мужественный офицер не покинул своих подчиненных, воодушевляя их личным примером на решительность и отвагу в бою.

Героический гарнизон капитана Уразаева оказал большую помощь остальным воинским частям, штурмовавшим центральную часть Грозного.

Все участники этого многодневного боя были награждены боевыми наградами. За мужество и героизм, проявленные при выполнении специального задания, указом Президента РФ от 29 мая 1995 года капитану Уразаеву Игорю Кабировичу присвоено звание Героя России.

После Чечни он продолжил службу в воздушно-десантных войсках, был начальником штаба и командиром парашютно-десантного батальона. В 2005 году ему присвоили звание полковника.

В честь Героя России Игоря Кабировича Уразаева на мемориале героев-выпускников Новосибирского военного общевойскового командного училища установлен бюст.

Игорь Уразаев сегодня живет в Москве, работает научным сотрудником в Центральном музее Вооруженных Сил Российской Федерации.

өчен, шәһәр үзәгенә бәреп керәләр. Сугыш барышында капитан Уразаев контузия ала, ләкин ротага командалык итүеннән туктамый. Подразделение дудаевчыларны ныгытылган һәм тактик яктан уңайлы бинадан бәреп чыгара һәм анда үзенең терәк пунктын оештыра.

Уразаев гвардиячеләре бу бинаны өч тәүлек буена тотып торалар. Боевиклар аны үзләренә кире кайтару өчен берничә омтылыш ясап карый. Алар бер-бер артлы, шул исәптән бронетехника кулланып та һөҗүм итәләр. Бинага бөтен төр коралдан аталар. Ләкин барлык һөҗүмнәр кире кайтарыла, 150 ләп боевик сафтан чыгарыла. Уразаев гвардиячеләре дудаевчыларның өч танкын, алты пехота хәрби машинасын, расчетлары белән бергә 7 эре калибрлы пулеметны юк итә, 2 боеприпас складын кулга төшерә. һәм 150гә якын боевикны әсирлеккә ала. Рота командиры Уразаев һәрвакыт оборонаның иң куркыныч урыннарында йөри, солдатларны оста итеп урнаштыра. Үзенең шәхси үрнәге белән ул солдатларның рухын күтәрә, 20ләп боевикны үтерә. 1995 елның 9 гыйнварындагы сугышта Уразаев икенче кат контузия ала. Бу юлы ул телдән кала. Ләкин бу очракта да куркусыз офицер үз солдатларын ташлап китми, аларны сугышта тәвәккәллеккә һәм батырлыкка дәртләндереп тора.

Капитан Уразаевның герой гарнизоны Грозный үзәген штурмлаган башка хәрби частьларга зур ярдәм күрсәтә.

Берничә көнгә сузылган сугышта катнашучылар барысы да хәрби бүләкләр белән бүләкләнә. Махсус задание үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1995 елның 29 маендагы Указы нигезендә капитан Уразаев Игорь Кәбир улына Россия Герое исеме бирелә.

Чечнядан соң ул хезмәтен һава-десант гаскәрләрендә дәвам иттерә, штаб начальнигы һәм парашютчы-десантчылар батальоны командиры була. 2005 елда аңа полковник исеме бирелә.

Новосибирск хәрби гомумгаскәрләр команда училищесын тәмамлаган геройлар мемориалында Россия Герое Игорь Кәбир улы Уразаевның бюсты куелган.

Игорь Уразаев хәзер Мәскәүдә яши, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең Үзәк музеенда фәнни хезмәткәр булып эшли.







# ХАЙРУЛЛИН Газинур Гарифзянович

Родился 10 сентября 1961 года в селе Старое Дрожжаное Дрожжановского района Татарской АССР. После окончания средней школы с 1979 года служил в Военно-воздушных силах СССР.

Служба в армии подвигла парня избрать военную профессию, и он поступил в Балашовское высшее военное авиационное училище, по окончании которого в 1983 году начал служить в 339-м авиаполку 3-й гвардейской Смоленской военно-транспортной авиадивизии в городе Витебске Белорусской ССР. Вначале помощником командира, затем командиром воздушного корабля Ил-76. Газинур неоднократно участвовал в доставке грузов и личного состава в Афганистан в период боевых действий Ограниченного контингента советских войск в этой стране, в доставке грузов в зону землетрясения в Армении в 1989 году, а также в дальних полетах в ряд зарубежных стран. В 1992 году майор Хайруллин Г.Г. уволен в запас по сокращению Вооруженных сил.

С 1994 года он работал в авиакомпаниях гражданской авиации Российской Федерации вторым пилотом, затем командиром воздушного судна. С 2008-го по 2009 год – генеральным директором ОАО «Авиакомпания Татарстан».

Теперь уже многие, похоже, подзабыли, а молодые читатели вовсе не знают одиссею наших летчиков, попавших

1961 елның 10 сентябрендә Татарстан АССРның Чүпрәле районы Иске Чүпрәле авылында туа. 1979 елда мәктәпне тәмамлаганнан соң СССРның Хәрби-һава көчләрендә хезмәт итә.

Армиядә хезмәт итү егетне хәрби һөнәр сайларга этәрә. һәм ул Балашово югары хәрби авиация училищесына укырга керә. Аны 1983 елда тәмамлап, Белорусия ССРның Витебск шәһәрендә 3 нче гвардия Смоленск хәрби-транспорт авиадивизиясенең 339 нчы авиаполкында хезмәт итә башлый. Башта командир ярдәмчесе, аннары «Ил-76» һава корабы командиры була. Газинур совет гаскәрләренең Әфганстандагы чикләнгән контингентының сугыш хәрәкәтләре чорында күп мәртәбә бу илгә йөкләр һәм солдатлар ташуда, 1989 елда Әрмәнстанга җир тетрәү зонасына йөкләр ташуда, шулай ук кайбер чит илләрдә озакка сузылган очышларда катнаша. 1992 елны майор Г.Г.Хәйруллин, Кораллы Көчләр кыскартылгач, запаска чыга.

1994 елдан ул Россия Федерациясенең Гражданнар авиациясе авиакомпанияләрендә икенче пилот, соңрак һава судносы командиры булып эшли. 2008 елдан 2009 елга кадәр «Татарстан авиакомпаниясе» ААҖдә генераль директор була.

в плен к афганским талибам в Кандагаре. Потому уместно будет вкратце изложить ее здесь.

После развала по воле амбициозных политиков великой державы – Союза ССР невостребованными в одночасье оказались тысячи людей, обладавших профессиональными знаниями, большим опытом во многих областях жизнедеятельности, науки и техники. С развалом советского Аэрофлота в таком незавидном положении оказались сотни, если не тысячи высококлассных летчиков, вынужденных искать работу на чужбине, нередко в экстремальных ситуациях. Многие экипажи советских летчиков погибли, пропали без вести. В экстремальной ситуации оказался и экипаж из Татарстана, в составе которого был и Газинур Хайруллин.

Татарстанский самолет Ил-76 арендовала фирма «Трансавиа», одна из перевалочных баз которой располагалась на территории Объединенных Арабских Эмиратов. Российские летчики транспортировали оттуда тюки с одеждой, топливо, один раз даже везли 34 тонны денег.

Однажды менеджер компании предложил экипажу: «Есть хорошая работа: из Албании доставить груз в Афганистан, в город Баграм. Грузом будут патроны к автоматам Калашникова». Предложение не вызвало возражений у экипажа, поскольку ему уже приходилось транспортировать военную технику и боеприпасы, тем более что на поставку патронов имелось соглашение между Албанией и Афганистаном. Два рейса прошли безо всяких происшествий. Оставался последний, третий. Как и ранее, в Тиране летчики погрузили 1200 ящиков с патронами, взлетели и взяли курс на Афганистан.

2 августа 1995 года самолет в десять утра вошел в воздушное пространство Афганистана. До пункта назначения оставалось полчаса лета, когда радисту с земли поступило требование на русском языке садиться самолету в Кандагаре для досмотра.

В хвост Ил-76 пристроился истребитель МиГ-21, за штурвалом которого сидел афганец Гулям, летному делу он учился в Советском Союзе и знал русский язык. С земли предупредили о том, что в случае неповиновения будет открыт огонь на поражение: под крылом МиГ-21 подвешены боевые ракеты.

По всем международным правилам это был прямой акт воздушного пиратства. Экипаж Ил-76 никаких международных правил не нарушал. Принадлежащий казанской фирме «Аэростан», зарегистрированной в Арабских Эмиратах, он вез патроны по соглашению между Албанией и Афганистаном.

Баграм, куда летел самолет, контролировал военачальник Ахмад Шах Масуд, а небо Кандагара контролировало движение «Талибан». После двух рейсов, очевидно, произошла утечка информации, и талибы решили захватить Ил-76.

Экипаж вынужден был подчиниться и пойти на посадку. При досмотре в одном из ящиков были обнаружены крупнокалиберные снаряды, запрещенные для перевозки. Этот ящик в Тиране загрузили, видимо, не сказав ничего летчикам, в последний момент. Не исключено, что это была просто грубая провокация. Ящик со снарядами послужил причиной для обвинения экипажа в контрабанде.

Хәзер инде күпләр оныткандыр, ә яшьрәк укучылар Кандагарда әфган талиблары кулына әсир төшкән очучыларыбыз тарихын бөтенләй дә белмидер. Шуңа күрә монда кыскача гына шул хакта сөйләп китү урынлы булыр.

Амбицияле сәясәтчеләр ихтыяры белән бөек держава – Советлар Союзы таркатылганнан соң тормышның, фәннең һәм техниканың күп өлкәләрендә профессиональ белемнәргә, зур тәҗрибәгә ия булган меңнәрчә кешеләр бер мизгел эчендә кирәксезгә калды. Аэрофлот таралгач, шул хәлгә төшкән йөзләгән (бәлки меңләгәндер) югары класслы очучылар чит җирләрдә, еш кына экстремаль хәлләрдә эш эзләргә дучар итеде. Совет очучыларының күп экипажлары һәлак булды, хәбәрсез югалды. Составында Газинур Хәйруллин булган Татарстан экипажы да экстремаль хәлгә тарыды.

Татарстанның «Ил-76» самолетын йөк күчерү базаларыннан берсе Берләшкән Гарәп Әмирлекләре территориясендә булган «Трансавиа» фирмасы арендалый иде. Россия летчиклары аннан кием төялгән тюклар, ягулык ташыйлар, хәтта бервакыт 34 тонна акча күчерәләр.

Берзаман компаниянең менеджеры экипажга тәкъдим ясый: «Албаниядән Әфганстанның Баһрам шәһәреннән йөк алып кайтырга кирәк. Ул йөк Калашников автоматлары өчен патроннар булачак». Экипаж бу тәкъдимгә каршы килми, чөнки ул инде хәрби техника һәм боеприпаслар ташыган була. Өстәвенә Албания белән Әфганстан арасында патроннар китерү турында килешү дә төзелгән. Ике рейс әйбәт кенә үтеп китә. Соңгысы – өченчесе кала. Элеккечә үк очучылар Тиранда патрон тутырылган 1200 әрҗәне төяп, Әфганстан ягына таба очып китәләр.

1995 елның 2 августында иртәнге сәгать 10 да самолет Әфганстан һава пространствосына керә. Җирдән радистка рус телендә «самолетны тикшерү өчен Кандагарда утырырга» дигән таләп килеп ирешкәндә, билгеләнгән урынга кайтып җитәргә ярты сәгать кенә очасы калган була.

«Ил-76»ның койрыгына «МиГ-21» истребителе тагыла. Аның штурвалы артында әфганлы Гөләм утыра. Очучылык эшенә ул Советлар Союзында өйрәнгән була һәм рус телен белә. Җирдән кисәтеп куялар: буйсынмаган очракта юк итү өчен ут ачылачак (МиГ-21нең канаты астына хәрби ракеталар элеп куелган була).

Халыкара кагыйдәләр буенча бу һава пиратлыгы булып санала. «Ил-76» экипажы бернинди халыкара кагыйдәне дә бозмаган. Гарәп Әмирлекләрендә теркәлгән «Аэростан» Казан фирмасыныкы булган самолет, Албания белән Әфганстан арасындагы килешү буенча, патроннар алып бара.

Самолет барырга тиешле Баһрам шәһәрен хәрби начальник Әхмәд Шаһ Масуд, ә Кандагар күген «Талибан» хәрәкәте контрольдә тота. Ике рейстан соң мәгълүмат саркып чыккан, күрәсең, һәм талиблар «Ил-76»ны эләктерергә булганнар.

Экипаж буйсынырга һәм төшеп утырырга мәҗбүр була. Тикшергәндә әрҗәләрнең берсеннән ташырга рөхсәт ителми торган эре калибрлы снарядлар табыла. Бу әрҗәне Тиранда иң соңгы мизгелдә, очучыларга берни әйтмичә, куйган булырга тиешләр. Моның тупас провокация булуы да ихтимал. Снаряд тутырылган әрҗә экипажны контрабандада гаепләргә сәбәп була.





Потом, когда казанские летчики после многих мытарств и испытаний вновь оказались на родине, на вопрос собкора «Российской газеты»: «Не было ли предчувствия, что вам не следует подниматься в небо?» Газинур ответил: «Как раз напротив, все шло хорошо. Настроение у экипажа было приподнятым, ведь маршрут знали, поэтому не сомневались, что полет пройдет успешно. Такой груз экипаж перевозил не впервые. Все шло хорошо до тех пор, пока на хвост не сел истребитель и не приказал садиться...»

Как только самолет сел в Кандагаре, к нему ринулась обезумевшая вооруженная толпа. В те минуты летчикам действительно стало страшно. Допрос экипажу учинил сам мулла Омар – глава местной администрации, к тому же правая рука международного террориста Бен Ладена. В Кандагар в срочном порядке прибыл министр иностранных дел Пакистана с группой журналистов. Не было сомнения, что готовилось громкое заявление. Искали российский след, но не нашли, поскольку на ящиках значились китайские иероглифы. Так татарстанские летчики 3 августа 1995 года оказались в плену у талибов, который продлится целых 378 дней.

В Кабуле тогда у власти находились моджахеды во главе с президентом Бурханутдином Раббани. В стране творился хаос – война всех против всех. На политическую арену вышли талибы – то ли молодые муллы, то ли исламские студенты, тогда толком мало кто что-то знал. А тут в связи с перехватом самолета представился случай на весь мир громко заявить талибам о себе!

Бик күп газаплар һәм сынаулар кичеп, яңадан Ватаннарына кайткан Казан очучыларыннан «Российская газета» хәбәрчесе: «Ул чакта һавага күтәрелмәскә дигән уй күңелегезгә килмәдеме?» – дип сорый. «Киресенчә, барысы да җайлы барды, – дип җавап бирә Газинур. – Экипажның кәефе күтәренке иде, чөнки маршрутны беләбез. Очышның уңышлы тәмамланачагына шикләнмәдек тә. Мондый йөкне күчерүебез дә беренче тапкыр гына түгел. Артыбыздан истребитель ияреп, төшәргә боерык биргәнчегә кадәр барысы да әйбәт иде...»

Самолет Кандагарга төшеп утыруга ук аның янына коралллы котырган халык төркеме ыргыла. Ул минутларда очучылар, чынлап та куркып калалар. Экипаждан җирле администрация башлыгы, халыкара террорчы бен Ладенның уң кулы мулла Гомәр үзе сорау ала. Кандагарга тиз арада журналистлар төркеме белән бергә Пакьстанның тышкы эшләр министры килеп төшә. Зур янгыраш алачак хәбәр әзерләнүенә шик булмый. Россия эзен эзлиләр, тик таба алмыйлар, чөнки әрҗәләрдә кытай иероглифлары тора. Шулай итеп 1995 елның 3 августында талиблар кулына 378 көнгә сузылачак әсирлеккә эләгә.

Ул вакыттагы Кабулда хакимлек Президент Борһанетдин Раббани кул астындагы мөҗәһитләрдә була. Илдә хаос хөкем сөрә – бөтен кеше бөтен кешегә каршы сугыша. Сәяси аренага талиблар чыга. Әллә яшь муллалар, әллә ислам студентлары – ул чакта беркем дә чынлап торып белми. Ә монда самолетны кулга төшергәч, талибларга үзләре турында бөтен дөньяга кычкырып хәбәр салырга җай чыга.

1995 елның 3 августыннан башлап, Татарстан Кандагардагы вакыйгаларны борчылып күзәтә. Чөнки Әфган-

Начиная с 3 августа 1995 года, Татарстан с тревогой следил за событиями в Кандагаре, поскольку сразу семь соотечественников оказались в плену у движения, оппозиционного официальному правительству Афганистана. На октябрьской сессии Госсовета Татарстана директор департамента внешних связей республики Тимур Акулов доложил: «Когда мы выяснили, что полет проходил согласно всем международным правилам, Президентом Татарстана было принято решение об активном участии в возникшей проблеме. Я в составе делегации вылетел вначале в Эмираты, где мы встретились с руководством компании «Трансавиа», затем в Кандагар, где провели переговоры с талибами. После восьмичасовых переговоров мы все-таки нашли определенные точки соприкосновения».

Короче, талибы согласились с доводами о невиновности экипажа и выразили готовность освободить его после встречи с представителями ООН, российского МИДа и Организации Исламская Конференция». Однако пока единственное, что практически удалось сделать за два с лишним месяца,– это добиться того, чтобы летчиков перевели в более-менее сносные условия.

Работа по освобождению членов экипажа осуществлялась в тесном контакте с Министерством иностранных дел РФ. Российская сторона готова была выполнить все условия талибов, которые порой бывали непростыми. За помощью обращались к дипломатам, которые приезжали в Казань. Так, посол Пакистана в России Аюб Хан пообещал передать премьер-министру этой страны Беназир Бхутто просьбу о содействии. 28 августа Президент Татарстана Минтимер Шаймиев обратился к Бхутто с личным посланием. Председатель Госсовета РТ Василий Лихачев в письме к Генеральному секретарю ООН Бутросу Гали попросил представителей этой международной организации в Пакистане оказать помощь делегации Татарстана на переговорах по освобождению летчиков.

К переговорному процессу подключились представители мусульманских стран – Ирана, Саудовской Аравии, Турции. К руководителям талибов обратился генеральный секретарь Организации Исламская Конференция. 25 ноября Госдума РФ приняла специальное заявление с требованием освободить пленных летчиков, обратившись к руководителям Пакистана, Ирана, Саудовской Аравии и США, к парламентариям всего мира.

Но, несмотря на многосторонние переговоры, усилия по освобождению экипажа в 1995 году не увенчались успехом.

Вернемся, однако, к членам экипажа. Их разместили в небольшом сарайчике во дворе губернатора Кандагара. Дворик, в котором позволяли прогулки «гостям», день и ночь охраняли автоматчики. Иногда поглазеть на пленников пускали местных жителей. К ним частенько наведывался мулла, предлагавший принять ислам и тем самым приблизить час освобождения. Кормили пленных талибы тем же, что ели сами. От их пищи наши летчики часто страдали животом. Выручали дыни и арбузы, которых было в достатке. Правда, талибы относились к летчикам не как к пленным, они их называли своими «гостями». Однако всякой связи с внешним миром «гости» были лишены.

На третий день всех семерых членов экипажа – командира Владимира Шарпатова, второго пилота Газинура Хай-

станның рәсми хөкүмәтенә оппозициядә торган хәрәкәткә берьюлы җиде ватандашыбыз әсирлеккә эләгә бит. Татарстан Дәүләт Советының октябрьдәге сессиясендә республиканың тышкы элемтәләр департаменты директоры Тимур Акулов болай ди: «Очышның бөтен халыкара кагыйдәләргә туры килүе ачыклангач, Татарстан Президенты килеп туган проблемага актив рәвештә катнашу турында карар кабул итте. Делегация составында мин башта Әмирлекләргә очтым. Без анда «Трансавиа» компаниясе җитәкчелеге белән очраштык. Аннары Кандагарга китеп, талиблар белән сөйләшүләр алып бардым. Сигез сәгать буена сузылган сөйләшүләрдән соң без берничә уртак фикергә килдек».

Кыскасы, талиблар экипажның гаепсезлеге турындагы дәлилләр белән килешәләр һәм БМО, Россия ТЭМ һәм «Ислам конференциясе» оешмасы вәкилләре белән очрашканнан соң очучыларны  азат итәргә әзер булуларын белдерәләр. Ләкин ике айдан артык вакыт эчендә башкарылган бердәнбер эш очучыларны бераз гына яхшырак шартларга күчерүгә ирешү була.

Экипаж әгъзаларын азат итү эше РФ Тышкы эшләр министрлыгы белән тыгыз бәйләнештә алып барыла. Россия ягы талибларның шактый катлаулы булган бөтен шартларын үтәргә әзер була. Казанга килгән дипломатларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, Пакьстанның Россиядәге илчесе Әюб Хан бу илнең Премьер-министры Беназир Бхуттога ярдәм итү турындагы үтенечне тапшырырга вәгъдә бирә. 28 августта Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Бхуттога шәхсән үзе мөрәҗәгать итә. ТР Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев, БМО Генераль секретаре Бутрос Галигә хат язып, бу халыкара оешманың Пакьстандагы вәкилләреннән Татарстан делегациясенә очучыларны азат итү буенча сөйләшүләрдә ярдәм күрсәтүләрен үтенә.

Сөйләшүләр процессына  Иран, Согуд Гарәбстаны, Төркия кебек мөселман илләренең вәкилләре дә кушылып китә. Талибларның җитәкчеләренә «Ислам конференциясе» оешмасының генераль секретаре да мөрәҗәгать итә. 25 ноябрьдә РФ Дәүләт Думасы, Пакьстан, Иран, Согуд Гарәбстаны һәм АКШ җитәкчеләренә, бөтен дөнья парламентарийларына мөрәҗәгать итеп, әсир очучыларны азат итү таләбе белән махсус гарызнамә кабул итә.

Ләкин, күпьяклы сөйләшүләргә дә карамастан, экипажны азат итү омтылышы 1995 елда  уңыш белән тәмамланмый.

Экипаж әгъзаларына әйләнеп кайтыйк. Аларны Кандагар губернаторы ишегалдындагы кечкенә генә сарайга урнаштыралар. «Кунаклар»га  чыгып йөрергә рөхсәт ителгән ишегалдын көн-төн автоматчылар саклап тора. Кайчакта әсирләрне карарга җирле халыкны кертәләр. Әсирләр янына еш кына мулла килә һәм аларга ислам динен кабул итеп, азат ителү сәгатен якынайтырга тәкъдим ясый. Әсирләргә талиблар үзләре ашаган ризыкны ашаталар. Аларның ризыгыннан безнең очучыларның эчләре еш авырта. Туйганчы ашарлык күп булган кавын һәм карбызлар коткара. Дөрес, талиблар очучыларга әсирләр итеп карамыйлар, аларны «кунак» дип йөртәләр. Ләкин «кунак»лар тышкы дөнья белән барлык элемтәдән дә мәхрүм була.

Өченче көнне экипажның барлык җиде кешесен дә – командир Владимир Шарпатовны, икенче пилот Газинур Хәйруллинны, штурман Александр Здорны, бортинженер




руллина, штурмана Александра Здора, бортинженера Асхата Аббязова, радиста Юрия Вшивцева, инженеров Сергея Бутузова и Виктора Рязанова увезли в неизвестном направлении. «Нам ничего не объяснили, только сказали: «Теперь вы останетесь здесь!», – вспоминали потом летчики. – В ту минуту мы попрощались с жизнью. Думали, везут на расстрел. Отлегло от сердца, только когда увидели жилой барак».

Он оказался пристроен к гостевому дому губернатора Кандагара. Каменная постройка больше напоминала склад. Рядом – крохотный дворик с колодцем, окруженный высоким забором с колючей проволокой. Из колодца доставали потом протухшую воду, которой в жуткую жару поливали двор. Это была слабая попытка спастись от нещадно палящего афганского солнца. Поначалу из еды давали четыре картофелины и небольшой кусок бараньего жира – это для всех семерых.

Через три месяца, в октябре, когда нервы летчиков уже были на пределе, благодаря стараниям дипломатов к пленным впервые допустили российских врачей. Под контролем автоматчиков они осмотрели пленников. Потом медработники приезжали еще несколько раз, привозили продукты, лекарства и письма из дома. Пленные жили в хозблоке, где бетонный пол должен был служить им постелью. Через некоторое время летчики нашли старые рулоны с тканью, разорвали их и настелили вместо простыней.

На вопрос, что было страшнее всего, Газинур Хайруллин, не задумываясь, ответил: «Неизвестность».

Сказать, что российские власти не предпринимали мер для освобождения кандагарских пленников, будет неверно. Президент России направил даже в Кандагар министра иностранных дел Козырева, но талибы отказались его при-

Әсхәт Аббязовны, радист Юрий Вшивцевны, инженерлар Сергей Бутузов  һәм Виктор Рязановны билгелесез юнәлештә алып китәләр. «Безгә берни дә аңлатмадылар. Бары тик: «Сез хәзер монда калачаксыз!» – дип кенә әйттеләр, – дип искә ала  соңыннан очучылар. – Ул минутларда без дөнья белән саубуллаштык. Атарга алып баралар дип уйладык. Яшәрлек баракны күргәч кенә җиңел сулап куйдык».

Ул Кандагар губернаторының кунаклар йортына янкорма итеп ясалган була. Таш корылма складны хәтерләтә. Янәшәдә – коелы, чәнечкеле тимерчыбыклы биек койма белән әйләндереп алынган бәләкәй генә ишегалды. Коедан сасыган су алып, бик кызу чакларда ишегалдына сибәләр. Бу аяусыз яндырып торган әфган кояшыннан качуның бер омтылышы була. Баштарак җиде кешегә ашарга дүрт бәрәңге һәм кечкенә генә кисәк сарык мае бирәләр.

Өч айдан соң, октябрьдә, очучыларның нервлары соң чиккә җиткәндә, дипломатлар тырышлыгы белән әсирләр янына беренче тапкыр Россия табибларын кертәләр. Автоматчылар  күзәтүе астында алар әсирләрне тикшерә. Аннары медиклар тагын берничә тапкыр килә, азык-төлек, дарулар һәм Ватаннан хатлар китерәләр. Әсирләр хозблокта яши, аның бетон идәне ятак булып хезмәт итә. Күпмедер вакыттан соң очучылар тукыма төргәкләре табып ала. Һәм шуларны ерткалап, асларына җәяләр.

Иң куркынычы нәрсә иде, дигән сорауга Газинур Хәйруллин, уйлап та тормыйча, билгесезлек, дип җавап бирә.

Россия хакимиятләре Кандагар әсирләрен азат итү өчен чара күрмәделәр дию дөрес булмас. Россия Президенты Кандагарга хәтта тышкы эшләр министры Козыревны да җибәреп карый. Ләкин талиблар, куркынычсызлыгын тәэмин итү мөмкинлеге булмауга сылтап,  аны кабул

нять, сославшись на невозможность обеспечить его безопасность. Власти Татарстана также делали все возможное для вызволения экипажа. Достаточно сказать, что госсоветник Президента Акулов летал туда двадцать шесть раз! Талибы принимали его вежливо, но ответ их каждый раз был стандартным: летчики, мол, признаны преступниками, их будут судить по законам шариата, их ждет смерть.

Но не таким простаком оказался Тимур Акулов, как могли предположить талибы. «У вас, как у других народов, есть свой кодекс чести, – заявил он при очередной встрече с талибами. – Кодекс пуштуна, по которому вы должны выслушать своего гостя. Чтобы мы, мусульмане, были правильно понятыми, давайте перейдем на язык великого Корана».

И стал говорить по-арабски. Это был гениальный ход дипломата Акулова. Ведь откуда знать арабский язык вчерашним бедуинам, хотя и называвшим себя «сыновьями Аллаха»?!

Талибы растерялись и попросили паузу. Вскоре они вызвали своего министра иностранных дел, который знал язык Корана. Акулов, взяв слово, стал растолковывать тому, что в Татарстане тоже живут мусульмане, которые ничего не имеют против талибов. А летчики – они обычные наемные перевозчики.

Словом, лед тронулся. Казнь была отменена. А отношения теплели с каждым визитом щедрого гостя. Узнав, например, что у главы охраны вышла из строя коробка передач его «Тойоты», Тимур Юрьевич привез ему ее из Казани. Презентовал нужным людям модные тогда часы нашей фирмы «Восток» с исламской символикой.

«Наконец настал момент, когда мы договорились о сумме выкупа,-вспоминал позже Тимур Юрьевич. – Вот-вот летчики были бы освобождены».

Но сделка не состоялась. Произошла утечка информации. Каким образом? Тогдашний министр иностранных дел России Козырев, далеко не лучший российский дипломат тех лет, решил «отрапортовать о больших успехах» его внешнеполитического ведомства. В качестве иллюстрации не нашел ничего лучшего, как привести пример, что скоро лично вернет российских летчиков из афганского плена. Разведка талибов не дремала, и они тут же ухватились за козыревское обещание. Оно было более выгодное, чем выкуп. Ведь в случае высокого визита российского министра о них, талибах, никем не признанных, кроме соседнего Пакистана, сразу узнает весь мир!

Но в Афганистан Козырев, конечно, не полетел: там же война! И Акулову пришлось все начинать с нуля. Уязвленные талибы стали выдвигать новые условия. Ситуация зашла в тупик.

Тогда возникла идея побега. Риск, конечно, огромный. И сценарий требовался особый. Надо было договариваться с Ираном и Объединенными Арабскими Эмиратами о паролях и воздушных коридорах, на которые будут рассчитывать беглецы в «час икс». Поскольку все усилия российских и международных организаций успеха не имели, экипаж твердо решил действовать самостоятельно.

10 июля 1996 года летчиков в очередной раз отвезли на аэродром. При осмотре выяснилось, что у самолета лопнуло одно из колес. Это стало поводом вернуться на борт, чтобы устранить неисправность... Приводя понемногу са-

итүдән баш тарталар. Татарстан хакимиятләре дә экипажны коткару өчен мөмкин булганның барысын да эшли. Президентның Дәүләт Киңәшчесе Акуловның анда 26 тапкыр барып кайтуын әйтү дә җитәдер. Талиблар аны хөрмәт белән кабул итә, ләкин җаваплары һәрвакыт бер үк була: очучылар җинаятьчеләр дип танылган, аларны шәригать законнары буенча хөкем итәчәкләр, аларны үлем көтә.

Ләкин Тимер Акулов талиблар уйлаганча ук пешмәгән булып чыкмый. «Башка халыклардагы шикелле үк, сезнең дә үз намус кодексыгыз бар, – ди ул чираттагы бер баруында. – Пуштун кодексы буенча, сез кунагыгызның сүзен тыңлап бетерергә тиеш. Без мөселманнарны дөрес аңларга теләсәгез, әйдәгез бөек Коръән теленә күчик».

Һәм гарәпчә сөйли башлый. Бу дипломат Акуловның гениаль адымы була. Үзләрен «Аллаһ уллары» дип йөртсәләр дә, кичәге бәдәвиләр гарәп телен кайдан белсен соң?!

Талиблар югалып кала һәм пауза сорый. Бераздан алар Коръән телен белүче тышкы эшләр министрын чакырталар. Сүз алып, Акулов аңа Татарстанда талибларны дошман күрмәүче мөселманнар яшәвен аңлата. Ә очучыларның гап-гади ялланган йөкчеләр генә икәнлеген әйтә.

Кыскасы, боз кузгала. Очучыларны җәзаламаска булалар. Ә мөнәсәбәтләр юмарт кунакның һәр килүе саен җылынганнан–җылына бара. Мәсәлән, сак башлыгының «Тойота» машинасының тапшырулар тартмасы сафтан чыканны белеп, Тимур Юрьевич аны Казаннан алып килеп бирә. Кирәкле кешеләргә безнең «Восток» фирмасының ул чакта модада булган ислам символикасы төшерелгән сәгатьләрен алып бара.

«Ниһаять, түләнергә тиешле акча суммасы турында килешүгә ирешелгән мизгел килеп җитте, – дип искә ала соңрак Тимур Юрьевич. – Очучылар менә-менә азат ителергә тиеш иде».

Ләкин алыш-биреш булмый кала. Каяндыр мәгълүмат саркып чыккан була. Ничек итеп? Россиянең ул чактагы тышкы эшләр министры, бигүк әйбәт булмаган дипломат Козырев үзенең тышкы сәясәт ведомствосының «зур уңышлары» белән мактанмакчы була. Тиздән шәхсән үзем Россия очучыларын әфган әсирлегеннән кайтарачакмын, диюдән дә яхшырак мисал таба алмый. Талиблар разведкасы да йоклап ятмый, алар Козырев вәгъдәсен шунда ук эләктереп ала. Ул алар өчен файдалырак була. Чөнки Россия министрының килүе күрше Пакьстаннан башка бер ил дә танымаган талиблар турында бөтен дөньяга белгертү мөмкинлеген бирәчәк!

Билгеле инде, Козырев Әфганстанга бармый – анда сугыш ич! Акуловка барысын да яңадан башларга туры килә. Гарьләнгән талиблар яңа шартлар куя башлый.

Шул чакта очучыларда качу идеясе туа. Әлбәттә, бу – бик хәтәр эш. Аның өчен махсус сценарий таләп ителә. Иран һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре белән парольләр һәм качучылар файдаланачак һава коридорлары турында килешергә кирәк була. Россия һәм халыкара оешмаларның тырышлыклары уңыш казанмагач, экипаж мөстәкыйль хәрәкәт итәргә була.

1996 елның 10 июлендә очучыларны аэродромга илтәләр. Тикшерә башлагач, самолетның бер көпчәге шартлаганы ачыклана. Бу җимереклекне төзәтү өчен самолет янына килергә сәбәп була. Самолетны аз-азлап төзәткәләп, безнең егетләр сабыр гына җай чыкканны





молет в рабочее состояние, наши ребята терпеливо ждали момента. И он настал. Вот как вспоминает об этом Газинур Хайруллин:

«В очередной раз 16 августа 1996 года привезли экипаж на аэродром для технического обслуживания самолета. Мы готовили машину, часть охраны была в кабине экипажа, часть – в грузовой кабине. Асхат начал запускать ВСУ – вспомогательную силовую установку, от которой запускаются основные двигатели. Но ВСУ выключилась на предельной температуре.

Старшему охраннику мы сказали, что нужно полчаса для охлаждения ВСУ. Он забрал большую часть охраны и направился в здание аэропорта – то ли из-за жары, то ли настало время обеденной молитвы. Часть наших ребят также вышла из кабины самолета. Остались только Юра Вшивцев, Асхат Аббязов и я. Мы поняли друг друга с полуслова. Решили запускать ВСУ, не дожидаясь ее охлаждения, пока нет основной охраны. Я кричу Асхату: «Давай запускай, охраны нет!» Фортуна была на нашей стороне – ВСУ запустилась! Я сел на командирское кресло, а Асхат начал запускать основные двигатели. Первый и второй двигатели запустились, я в это время начал готовить к полету рабочее место командира: включил бустера, расстопорил рули, включил потребители. Когда Асхат начал запускать третий двигатель, ВСУ отключилась, оказывается,

көтә. Һәм ул чыга. Бу хакта Газинур Хәйруллин менә ничек сөйли:

«1996 елның 16 августында экипажны аэродромга техник карау үткәрү өчен алып килделәр. Без машинаны әзерләдек. Сакчыларның бер өлеше экипаж кабинасында, бер өлеше йөк кабинасында иде. Әсхәт ВСУны (ярдәмче көч җайланмасы) кабыза башлады. Аңардан төп моторлар кабынырга тиеш иде. Ләкин чик температурага җиткәч, ВСУ сүнде.

Без өлкән сакчыга ВСУны суыту өчен ярты сәгать вакыт кирәклеген әйттек. Әллә кызулыктан, әллә өйлә намазы җиткәнлектәнме, ул, сакчыларның күбесен үзе белән ияртеп, аэропорт бинасына таба китте. Безнең егетләрнең дә берничәсе самолет кабинасыннан чыкты. Юра Вшивцев, Әсхәт Аббязов һәм мин генә калдык. Без бер-беребезне ярты сүздән аңлап алдык. Төп сакчылар булмаганда, суынганын көтеп тормыйча, ВСУны кабызырга булдык. Мин Әсхәткә: «Әйдә кабыз, сакчылар юк!» – дип кычкырдым. Бәхетебез бар икән – ВСУ кабынды! Мин командир креслосына утырдым, ә Әсхәт төп двигательләрне кабызырга тотынды. Беренче һәм икенче двигательләр кабынды, шул вакытта мин командирның эш урынын очышка әзерли башладым: бустерларны кабыздым, рульләрне стопордан чыгардым, кулланучыларны кабыздым. Әсхәт өченче двигательне кабыза башлагач, ВСУ сүнде. Бу вакытта Сергей

в это время Сергей Бутузов начал закрывать грузовой люк. Молодец! Оперативно сработал. Остальные два двигателя Асхат запустил от основного. Вот все двигатели запущены. В кабину торопливо поднялся Шарпатов, сел на свое место, но дальше почему-то медлит. Оказывается, вспомнил про карту проверок, а здесь дорога каждая секунда. Дает команду радисту запросить разрешения на руление у афганского диспетчера, который нас же сажал.

Я не выдержал, нервы на пределе. Кричу: «Какая, к черту, карта, какое разрешение, давай рули!» И увеличил обороты двигателей. Еще 30-40 секунд задержки на взлете – и талибы успели бы перекрыть полосу. Две их автомашины уже мчались на полосу.

С самого начала я успел предупредить Вшивцева, Бутузова и Рязанова, чтобы они стояли за нашими спинами и были готовы нейтрализовать охрану. Взлетели, до охраны, кажется, дошло, что это побег. Нужно было быстро ее разоружить, но ребята медлили. Пришлось встать с рабочего места, а ведь летели на высоте 80 метров. Я быстро разоружил Рахматуллу, снял рожок, передернул затвор, патрон вылетел в кабину, отбросил автомат подальше, чтобы не смогли достать. А между тем ребята разоружили второго охранника, после чего связали обоих. Я снова сел на свое рабочее место. Лететь на малой высоте была моей идеей. Вспомнил из тактики, которую мы изучали в училище».

Через полтора часа они приземлились в Шардже в Арабских Эмиратах.

Первыми в салон ворвались полицейские, забрали и увели незадачливую охрану. А на летчиков с громкими криками восторга набросились друзья и коллеги.

В Москве и Казани героев встречали восторженно на самом высоком уровне. Ни в одном другом городе не могли, наверное, оценить по достоинству величие их поступка, кроме как в Казани, где каждый мал и стар знает о побеге своего знаменитого земляка Михаила Девятаева на вражеском самолете из немецкого плена в годы Великой Отечественной войны. Когда уже в России пилотов спросили, как же они отважились на это, они ответили коротко: «Мы же земляки Девятаева!»

Все участники побега были награждены орденами Мужества, а командиру Владимиру Шарпатову и второму пилоту Газинуру Хайруллину вручили звезды Героев России.

10 сентября 2011 года Героя России Газинура Гарифзяновича Хайруллина принял в Казанском Кремле и поздравил с 50-летним юбилеем Президент Татарстана Рустам Минниханов. Глава республики наградил юбиляра медалью «За доблестный труд». «Такие люди, как Вы, являетесь примером для нашей молодежи. Мы гордимся Вашим подвигом, – сказал юбиляру Президент Татарстана. – Вы доказали, что сила духа людей может способствовать совершению героических поступков.»

В настоящее время Газинур Хайруллин работает командиром экипажа в авиакомпании «Волга-Днепр» и по-прежнему летает на Ил-76 в России и за рубежом.

Бутузов йөк люгын яба башлаган иде. Молодец! Бик тиз эшләде. Калган ике двигательне Әсхәт беренчесеннән кабызды. Менә двигательләр эшли башлады. Кабинага ашыгып Шарпатов керде, үз урынына утырды, тик нишләптер шуннан соң акрын кыймылдый башлады. Тикшерүләр картасы турында искә төшергән икән. Ә монда бит һәр секунд кадерле. Рульне борырга әфган диспетчерыннан рөхсәт сорарга радистка команда бирә.

Нервлар соңгы чиккә җиткән иде, мин түзмәдем, кычкырып җибәрдем: «Шайтан алгыры, нинди карта, нинди рөхсәт, рулеңне бор әйдә!» Моторларның әйләнешен арттырдым. Очып киткәндә тагын 30-40 секунд тоткарлансак, талиблар полосаны ябарга өлгерәчәк иде. Аларны ике автомашинасы полосага таба чаба иде инде.

Мин Вшивцев, Кутузов һәм Рязановны, безнең артларыбызда торырсыз һәм сакчыларны нейтральләштерергә әзер булырсыз, дип баштан ук кисәтеп куйган идем. Без кузгала башладык. Моның качу икәнлеген сакчылар да аңлап алды бугай. Тизрәк аларны коралсызландырырга кирәк иде, тик егетләр никтер ашыкмыйлар. Миңа эш урынымнан торырга туры килде, ә бит 80 метр биеклектә генә оча идек. Мин тиз генә Рәхмәтулланы коралсызландырдым. Мөгезен алып, затворны тарттым, патрон кабинага очып керде. Сузылып ала алмасыннар дип, автоматны ераккарак ыргыттым. Ул арада егетләр икенче сакчыны да коралсызландырдылар, аннары икесен дә бәйләдек. Мин яңадан урыныма утырдым. Түбәннән очу минем идея иде. Училищеда өйрәнгән тактиканы искә төшердем».

Бер сәгать ярымнан алар Гарәп Әмирлекләрендәге Шарджга төшеп утыралар. Салонга беренче булып полицейскийлар бәреп керә, сакчыларны алып китәләр. Ә очучылар өстенә, шатлыклы тавышлар белән кычкырып, дуслары һәм хезмәттәшләре ябырыла.

Мәскәүдә һәм Казанда геройларны зур соклану белән иң югары дәрәҗәдә каршылыйлар. Казаннан гайре бер генә шәһәрдә дә аларның бу адымның бөеклеген тиешле дәрәҗәдә бәяли алмаслар иде, мөгаен. Чөнки Казанда олысы да, кечесе дә үзләренең танылган якташлары Михаил Девятаевның Бөек Ватан сугышы елларында дошман самолетында немец әсирлегеннән качуы турында белә бит. Россиягә кайтып җиткәч, очучылардан, качарга ничек җөрьәт иттегез, дип сораучыларга, алар кыска гына: «Без бит – Девятаев якташлары!» – дип җавап бирәләр.

Качуда катнашканнарның барысы да Батырлык орденнары белән бүләкләнә, ә командир Владимир Шарпатовка һәм икенче пилот Газинур Хәйруллинга Россия Геройлары йолдызларын тапшыралар.

2011 елның 10 сентябрендә Россия Герое Газинур Гарифҗан улы Хәйруллинны Казан Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итә һәм 50 яшьлек юбилее белән котлый. Республика башлыгы юбилярны «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкли. «Сездәй кешеләр яшьләребез өчен үрнәк булып тора. Без сезнең батырлыгыгыз белән горурланабыз, – ди Татарстан Президенты юбилярга. – Кешеләрнең рухи көче батырлыклар эшләргә ярдәм иткәнне сез исбатладыгыз».

Хәзерге вакытта Газинур Хәйруллин «Волга-Днепр» авиакомпаниясендә экипаж командиры булып эшли һәм элеккечә үк «Ил-76» самолетында Россиядә һәм чит илләргә оча.







# ЧАБАНОВ Владимир Анатольевич

Родился 3 февраля 1967 года в городе Крымске Краснодарского края в семье военнослужащего. Занимался боксом, был чемпионом города среди юношей по этому виду спорта. В 1984 году окончил Казанское суворовское военное училище, после которого поступил в Ленинградское военное общевойсковое командное училище.

Начинал армейскую службу на Крайнем Севере, в частях Ленинградского военного округа. В 1993 году молодой офицер был переведен в Северо-Кавказский военный округ на должность командира мотострелковой роты. Участвовал в ликвидации осетино-ингушского межэтнического вооруженного конфликта, нес службу на блокпостах у границы с Чеченской Республикой.

С декабря 1994 года Владимир участвовал в боях первой чеченской войны. При штурме Грозного 4 января 1995 года Чабанов получил приказ продвигаться со своей ротой к центру города и занять укрепленное здание в районе железнодорожного вокзала. Командир роты вывел три бронетранспортера на железную дорогу и по шпалам прорвался с вверенным подразделением к намеченному объекту. Поскольку железная дорога была разрушена, дудаевцы оставили ее без наблюдения. Поэтому появление в их тылу боевых машин с десантом российских мотострелков стало для них полной неожиданностью.

Общеизвестно, что первой к вокзалу выдвинулась Майкопская мотострелковая бригада в ночь на 1 января 1995 года. Она понесла тяжелые потери, встретив хорошо

1967 елның 3 февралендә Краснодар краеның Крымск шәһәрендә хәрби хезмәткәр гаиләсендә туа. Бокс белән шөгыльләнә, бу спорт төре буенча яшүсмерләр арасында шәһәр чемпионы була. 1984 елда Казан Суворов хәрби училищесын тәмамлый, аннан соң Ленинград хәрби гомумгаскәрләр команда училищесына укырга керә.

Армия хезмәтен Себердә Ленинград хәрби округы частьларында башлап җибәрә. 1993 елда яшь офицер Төньяк Кавказ хәрби округына мотоукчылар ротасы командиры вазыйфасына күчерелә. Осетин-ингуш милләтара кораллы конфликтын бастыруда катнаша, Чечня Республикасы чигендәге блок-постларда хезмәт итә.

1994 елның декабреннән Владимир беренче чечен сугышында катнаша. 1995 елның 4 гыйнварында, Грозныйны штурмлаганда, Чабанов үз ротасы белән шәһәр үзәгенә таба барырга һәм тимер юл вокзалы тирәсендәге ныгытылган бинаны яуларга боерык ала. Рота командиры тимер юлга өч бронетранспортерны чыгара һәм шпаллар буйлап үз подразделениесе белән билгеләнгән объектка таба кузгала. Тимер юл җимерелгән булганлыктан, дудаевчылар аны күзәтмиләр. Шуңа күрә үз тылларында Россия мотоукчылары десанты белән хәрби машиналар пәйда булу алар өчен һич көтелмәгән хәл була.

Вокзал ягына 1995 елны 1 гыйнварына каршы төндә беренче булып Майкоп мотоукчылар бригадасы кузгалганлыгы билгеле. Ул, боевикларның яхшы оештырылган каршылыгына очрап, авыр югалтуларга дучар була. Ә мотоук-

организованное сопротивление боевиков. Второе появление мотострелков, на сей раз бойцов капитана Чабанова, было иным. В ходе штурма здание было захвачено, находившиеся в нем боевики выбиты. На полторы недели бойцы капитана Чабанова численностью в 87 человек оставались единственными российскими солдатами в центре Грозного. Осажденные со всех сторон дудаевцами, они, заняв позиции, превратили здание в неприступную крепость.

Десять суток ежедневного беспрерывного боя и массированного обстрела боевиками из гранатометов и стрелкового оружия выдержали мотострелки Чабанова. По занятому зданию вокзала боевики произвели более ста сорока выстрелов из гранатометов. В результате сам командир отряда получил ранение и две контузии, но продолжал командовать личным составом лежа. От предложения медиков и командира полка отправиться в госпиталь Владимир отказался. Через сутки смог все же встать на ноги, но к этому времени боевики окружили отряд, и пришлось вызывать на себя огонь своей минометной батареи. По ходу боя капитан решил расширить плацдарм. Выбор пал на самое высокое здание гостиницы «Кавказ». Штурмовой отряд разделился, и сорок человек под командованием Владимира Чабанова взяли господствующее над местностью шестнадцатиэтажное здание, что обеспечило существенное преимущество для ведения боя. Вскоре дудаевцы стали гостиницу обстреливать из танковых орудий, но и тогда отряд не отступил с занятых позиций. Оборона

чыларның икенче кат килүе, бу юлы капитан Чабанов җитәкчелегендә, башкача була. Штурм барышында бина тартып алына, эчендәге боевиклар бәреп чыгарыла. Капитан Чабановның 87 кешедән торган сугышчылары Грозный уртасында калган бердәнбер Россия подразделениесе булып бер атна ярым тора. Бөтен яктан дудаевчылар белән чолгап алынган килеш, алар позицияләргә урнашалар һәм бинаны якын килә алмаслык крепостька әйләндерәләр.

Көн саен туктаусыз барган сугышларда, гранатометлардан һәм мылтыклардан сибелгән ут астында Чабановның мотоукчылары ун тәүлек тора. Вокзал бинасына боевиклар гранатометлардан 140 тапкыр ата. Нәтиҗәдә отряды командиры үзе яралана һәм ике контузия ала, ләкин яткан килеш булса да, личный состав белән командалык итүен туктатмый. Медиклар һәм полк командирының госпитальгә китәргә дигән тәкъдименнән Владимир баш тарта. Бер тәүлектән соң ул аягына баса, ләкин бу вакытка боевиклар инде отрядны камап алган була. Миномет батареясының утын үзләренә юнәлтүне сорарга туры килә. Сугыш барган вакытта капитан плацдармны киңәйтергә була. «Кавказ» кунакханәсенең иң биек бинасы сайлап алына. Штурм отряды бүленә һәм Владимир Чабанов командалыгындагы 40 кеше биектә торучы 16 катлы бинаны яулап ала. Бу аларга сугыш алып бару өчен зур өстенлек бирә. Тиздән дудаевчылар кунакханәгә танк орудиеләреннән ата башлыйлар. Отряд шунда да үз позицияләреннән чигенми. Вокзал оборонасы ахыр чиктә боевикларның оборона сызыгын бүләргә һәм шәһәрне алырга мөмкинлек бирә.







вокзала позволила в итоге расчленить линию обороны боевиков и взять город.

Три разбитые боевые машины и около 150 человек убитых – таковы были потери дудаевцев. Потери же отряда капитана Чабанова составили два погибших и 18 раненых и контуженных.

Указом Президента РФ от 21 июня 1995 года за мужество и героизм, проявленные при ликвидации незаконных вооруженных формирований в Северо-Кавказском регионе, гвардии капитану Чабанову Владимиру Анатольевичу присвоено звание Героя России с вручением медали «Золотая Звезда».

Продолжая службу в рядах Российской армии, Владимир окончил Военную академию имени М.В. Фрунзе, был назначен командиром танкового батальона Кантемировской дивизии, а затем начальником штаба танкового Шепетовского полка. Он стоял у истоков начавшегося в 2006 году процесса возрождения горно-стрелковых подразделений Российской армии и активно координировал этот процесс в последующие годы. Имея опыт боев в горах, Чабанов как никто другой понимал необходимость горной подготовки для наших войск.

В августе 2007 года, совместно с заместителем главкома Сухопутных войск РФ генерал-лейтенантом Валерием Евневичем Владимир Чабанов руководил первым в российской истории восхождением на Эльбрус штатной мотострелковой роты с полным вооружением и проведением боевых стрельб.

В последние годы Владимир Чабанов неоднократно был руководителем высокогорных учебно-тренировочных сборов инструкторов горной подготовки, проводимых Министерством обороны РФ. Организуя и руководя спортивными сборами, Владимир Анатольевич одновременно осваивал и повышал свою спортивную горную подготовку. Федерация альпинизма России вручила ему удостоверение инструктора горной подготовки за № 1.

Последняя должность Владимира Чабанова – начальник отдела Управления боевой и тактической подготовки Сухопутных войск. Гвардии полковник Чабанов скоропостижно скончался 7 ноября 2010 года. Похоронен герой на Троекуровском кладбище в Москве.

Җимерелгән хәрби 3 машина һәм үтерелгән 150ләп кеше – дудаевчыларның югалтулары әнә шундый була. Ә капитан Чабанов отрядыннан икәү һәлак була, 18е яралана һәм контузия ала.

Төньяк Кавказ төбәгендә законсыз кораллы формированиеләрне юк иткәндә күрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен РФ Президентының 1995 елның 21 июнендәге Указы нигезендә гвардия капитаны Чабанов Владимир Анатольевичка Россия Герое исеме бирелә, «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

Россия армиясе сафларында хезмәтен дәвам иттереп, Владимир М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлый, Кантемиров дивизиясенең танк батальоны командиры, ә аннары Шепетовский танк полкының штаб начальнигы итеп билгеләнә. Ул Россия армиясенең 2006 елда башланган тау-укчы подразделениеләрен кабат яңарту процессының башында тора. Һәм бу процессны аннан соңгы елларда да актив рәвештә координацияли. Тауларда сугышу тәҗрибәсенә ия булганга, Чабанов безнең гаскәрләр өчен тауларда әзерләнүнең зарурилыгын бөтен кешедән дә яхшырак аңлый.

2007 елның августында РФ Коры җир гаскәрләре баш командующие урынбасары генерал-лейтенант Валерий Евневич белән бергә тулысынча коралланып һәм хәрби атышлар уздырып, мотоукчылар ротасының Россия тарихында беренче булып, Эльбруска менүенә җитәкчелек итә.

Соңгы елларда Владимир Чабанов берничә тапкыр таулардагы әзерлек инструкторларының биек тауларда уза торган укыту-тренировка җыеннары җитәкчесе була. Спорт җыеннарын оештырып һәм җитәкчелек итеп, Владимир Анатольевич бер үк вакытта үзенең дә таулардагы спорт әзерлеген яхшырта. Россиянең Альпинизм федерациясе аңа таулардагы әзерлек инструкторының 1 нче номерлы таныклыгын тапшыра.

Владимир Чабановның соңгы вазыйфасы – Коры җир гаскәрләренең сугышчан һәм тактик әзерлек идарәсе бүлеге начальнигы. Гвардия полковнигы Чабанов 2010 елның 7 ноябрендә тиз генә үлеп китә. Герой Мәскәүнең Троекуров зиратында җирләнгән.





# ШАГАЛЕЕВ Фарит Султанович

Родился 8 февраля 1947 года в Барнауле Алтайского края в семье рабочего. Среднюю школу окончил в Ташкенте в 1964 году. Первоначальную летную подготовку получил в аэроклубе ДОСААФ.

В Ташкентском аэроклубе Фарит впервые в свои семнадцать лет поднялся в небо на вертолете Ми-1. Чтобы по-настоящему приобщиться к небу, работал заправщиком самолетов в центре ДОСААФ, который окончил в 1967 году с присвоением воинского звания «младший лейтенант запаса».

В сентябре 1970 года его призвали в армию и направили в пограничные войска на остров Сахалин, где он прослужил 8 лет. Много летал на вертолете Ми-4, был штурманом, правым летчиком, с 1971 года Шагалеев – командир вертолета 14-й отдельной авиационной эскадрильи Тихоокеанского пограничного округа. В 1973 году экстерном окончил Сызранское высшее военное училище летчиков.

С 1974 года проходил службу в 15-м авиационном полку Тихоокеанского пограничного округа. Там Фарит служил вначале командиром звена, с 1978 года – заместителем командира эскадрильи по летной подготовке.

В октябре 1979 года звено Шагалеева совершало первые разведывательные полеты вдоль границы с Афганистаном. Вскоре его назначили заместителем командира по летной подготовке отдельной вертолетной эскадрильи Среднеазиатского пограничного округа в городе Небит-Даг Туркменской ССР.

1947 елның 8 февралендә Алтай краеның Барнаул шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. Урта мәктәпне 1964 елда Ташкентта тәмамлый. ДОСААФ аэроклубында очарга өйрәнә.

Ташкент аэроклубында 17 яшьлек Фәрит «Ми-1» вертолетында күккә күтәрелә. Күккә чын-чынлап якынаю өчен, ДОСААФ үзәгендә самолетларга ягулык салучы булып эшли. ДОССАФны 1967 елда «запастагы кече лейтенант» хәрби званиесе белән тәмамлый.

1970 елның сентябрендә аны армиягә алалар. һәм Сахалин утравына чик буе гаскәрләренә җибәрәләр. Анда сигез ел хезмәт итә. «Ми-4» вертолетында күп оча, штурман, уң як очучы була. 1971 елдан Шагалеев – Тын океан чик буе округының 14 нче аерым авиация эскадрильясында вертолет командиры. 1973 елда экстерн рәвешендә Сызрань югары хәрби очучылар училищесын тәмамлый.

1974 елдан Тын океан чик буе округының 15 нче авиация полкында хезмәт итә. Фәрит анда башта звено командиры, 1978 елдан эскадрилья командирының очу әзерлеге буенча урынбасары булып хезмәт итә.

1979 елның сентябрендә Шагалиев звеносы Әфганстан чигендә беренче разведка очышлары уздыра. Озакламый аны Төрекмәнстан ССРның Небит-Даг шәһәрендәге Урта Азия чик буе округы аерым вертолет эскадрильясы командирының очу әзерлеге буенча урынбасары итеп билгеләп куялар.



В декабре 1979 года советское руководство приняло решение о вводе на территорию Афганистана подразделений пограничных войск КГБ СССР, мотивируя этот шаг угрозой безопасности Советского Союза на участке границы Московского и Хорогского погранотрядов.

Советско-афганская граница всегда была источником напряженности в Средней Азии. Начиная с 20-х годов прошлого века там практически не прекращались столкновения, которые в советской историографии получили название «борьбы с басмачеством». Да и послевоенное время тут было неспокойным. Одной из малоизвестных страниц афганской войны 1979-1989 годов является участие частей пограничных войск СССР в этом конфликте. Еще менее известными остаются действия погранавиации в этой не-знаменитой войне.

С декабря 1979-го по апрель 1983 года Фарит Шагалеев находился в составе Ограниченного контингента советских войск в Афганистане, где выполнял боевые задания по оказанию интернациональной помощи афганскому народу. За плечами Шагалеева – 10 лет афганской войны, 1200 боевых вылетов.

В Афганистане его экипаж первым начал высаживать десанты на высоту свыше 3,5 тысячи метров, в том числе ночью. Вертолетчики десантировали маневренные группы, доставляли боеприпасы, возили раненых, выручали сражавшихся на земле бойцов из самых тяжелых ситуаций. Все знали: если на помощь летит экипаж Шагалеева – все будет хорошо.

С января 1980 года части ПВ СССР получили приказ пересечь государственную границу с Афганистаном. Формально этот месяц считается началом участия пограничников в афганской войне, однако заметим, что «зеленые фуражки» появились на территории соседней страны по крайней мере на три месяца раньше: дело в том, что 4 сентября 1979 года в Кабул для охраны посольства СССР был отправлен отряд пограничников численностью 50 человек. Для обеспечения их деятельности и решения других задач были направлены два пограничных вертолета Ми-8 с экипажами.

Однако на начало 1980 года авиачасти погранавиации на афганском направлении были более чем скромные: в составе Среднеазиатского пограничного округа числилась только одна отдельная эскадрилья (базирование – аэродром Мары), на вооружении которой было всего 12 вертолетов Ми-8 и два самолета Ан-24. Понятно, что с увеличением масштабов участия пограничников в войне потребность в авиатехнике только возрастала, и уже в середине все того же 1980 года авиаэскадрилью сначала усилили двумя звеньями вертолетов Ми-8, а вскоре вообще развернули в 17-й отдельный авиаполк в составе двух эскадрилий с 36 вертолетами Ми-8 и Ми-24. Кроме того, в 1981 году была сформирована отдельная авиаэскадрилья в Душанбе, располагавшая 16 вертолетами и 4 самолетами. Для перевозок широко привлекался и отряд самолетов Як-40.

Укомплектование экипажей осуществлялось переводом летно-технического состава из частей и подразделений других погранокругов. Что касается спектра пограничной авиации, то в силу своей универсальности она привлекалась для решения широкого круга задач, а зачастую ста-

1979 елның декабрендә совет җитәкчелеге, Мәскәү һәм Хорог чик буе отрядлары чигендәге участокта Советлар Союзы иминлегенә куркыныч янауны сылтау итеп, Әфганстан территориясенә СССРның Дәүләт куркынычсызлыгы комитетының (КГБ) чик буе гаскәрләре подразделениеләрен кертү турында карар кабул итә.

Урта Азиядә совет-әфган чиге һәрвакыт киеренкелек чыганагы булып торды. Узган гасырның егерменче елларыннан башлап анда бәрелешләр туктап та тормады диярлек. Алар совет тарихчылары тарафыннан «басмачыларга каршы көрәш» дип аталды. Сугыштан соңгы еллар да монда тыныч кына узмады. Бу низагта СССР чик буе гаскәрләре частьларының катнашуы 1979–1989 еллардагы әфган сугышының аз билгеле битләреннән берсе булып санала. Киң таралыш алмаган бу сугышта чик буе авиациясе гамәлләре тагын да билгесезрәк булып кала бирә.

1979 елның декабреннән 1983 елның апреленә кадәр Фәрит Шагалиев совет гаскәрләренең Әфганстандагы чикләнгән контингенты составында була. Анда әфган халкына интернациональ ярдәм күрсәтү буенча хәрби заданиеләр үти. Шагалиев биографиясендә – ун ел әфган сугышы, 1200 сугышчан очыш.

Әфганстанда аның экипажы беренчеләрдән булып 3,5 мең метрдан да артыграк биеклекләргә десантлар төшерә башлый, шул исәптән төнлә дә. Вертолетчылар маневр төркемнәрен десантлый, боеприпаслар илтә, яралыларны ташый, сугышчыларны иң катлаулы хәлләрдән алып чыга. Ярдәмгә Шигалиев экипажы очса, барысының да әйбәт булачагын бөтен кеше белеп тора.

1980 елның гыйнварында СССР чик буе гаскәрләре Әфганстан дәүләт чиген кисеп чыгарга дигән боерык ала. Формаль яктан пограничникларның әфган сугышында катнаша башлаган вакыты булып шушы ай санала. Ләкин, әйтергә кирәк, күрше илнең территориясендә «яшел фуражкалар» ким дигәндә өч айга иртәрәк пәйда була. Эш шунда: 1979 елның 4 сентябрендә СССР илчелеген саклау өчен Кабулга илле кешелек пограничниклар отряды озатыла. Аларның эшчәнлеген тәэмин итү һәм башка бурычларны үтәү өчен экипажлары белән бергә ике «Ми-8» вертолеты да җибәрелә.

Ләкин 1980 елның башына чик буе авиациясенең әфган юнәлешендәге авиачастьлары бик аз була: Урта Азия хәрби округы составында бары тик бер аерым эскадрилья (Мары аэродромында урнашкан) исәпләнә. Аның карамагында барлыгы 12 «Ми-8» вертолеты һәм 2 «Ан-24» самолеты гына була. Аңлашыла ки, пограничникларның сугышта катнашу масштаблары киңәю белән авиатехникага ихтыяҗ арта гына бара. Шул ук 1980 ел уртасына авиаэскадрильяны башта «Ми-8» вертолетларының ике звеносы белән көчәйтәләр, ә тиздән 36 «Ми-8» һәм «МИ-24» вертолетларыннан торган ике эскадрильялы 17 нче аерым авиаполк оештыралар. Моннан тыш 1981 елда Дүшәнбедә 16 вертолеты һәм 4 самолеты булган аерым авиаэскадрилья оештырыла. Өстәвенә, «Як-40» самолетлары отряды да җәлеп ителә.

Экипажларны комплектлау очучы-техник составның башка чик буе округлары частьлары һәм подразделениеләреннән күчерү юлы белән хәл ителә. Универсаль булуы аркасында чик буе авиациясе күп мәсьәләләрне хәл итүдә кулланыла, ә еш кына чик буе гаскәрләренең күпкырлы

новилась единственным средством обеспечения и поддержки многообразной деятельности пограничных войск. В числе этих задач было обеспечение гарнизонов сборных боевых отрядов боеприпасами, продовольствием, водой и материально-техническими средствами, прикрытие с воздуха транспортных колонн, мотоманевренных групп на маршруте, воздушная разведка, нанесение ракетно-бомбовых ударов по огневым точкам, базам и складам моджахедов, доставка и высадка десантно-штурмовых групп при проведении операций, огневая поддержка с воздуха при ведении боевых действий, эвакуация убитых и раненых. Полеты на войну совершались днем и ночью, в простых и сложных метеоусловиях, в горной и пустынной местностях.

Авиацию пограничных войск использовали практически во всех операциях. Вертолетам, как боевой силе, способной решать широчайший круг задач, отводилось особое место, очень часто вертолетчики становились единственным средством поддержки наземных войск, единственной надеждой на победу и на жизнь. Подразделение Шагалеева из 16 вертолетов базировалось в Душанбе. Боевые командировки занимали 45-50 дней, из них экипажи возвращались в казавшийся нереальным советский город, где ничего не происходило, где по ночам спали, а мир и покой можно было черпать ложками. Несколько драгоценных суток в семейном кругу – и снова в бой.

– В конце 1980 года на перевале Гумбак заканчивалась операция и надо было снимать оттуда десантно-штурмовую группу подполковника Файзиева,– вспоминает Фарит Султанович. – Выяснилось: бойцов там 38 человек, это намного больше, чем может взять Ми-8. А до утра их оставлять нельзя – погибнут…

Я дистанцию взлетную промерил шагами, прикинул, в какой точке можно оторваться. С экипажем все обговорил, предупредил, на что идем. Забрали всех. Перегруз килограммов 700. Вырулил, дал максимальную мощность, поднял вертолет на несколько сантиметров – висит. Для разбега – не больше 35 метров. Взлетели на переднем колесе. Когда вывалились из ущелья, на прямую связь вышел начальник авиации округа Колокольников: «Фарит, сколько везешь?». Всех, говорю, забрал. Кажется, не поверил. Прилетели – Колокольников встретил лично, всех пересчитал. Я последним из вертолета вышел…

В апреле командование приступило к формированию 23-й эскадрильи в аэропорту Душанбе. В эскадрилье 18 вертолетов Ми-8, Ми-24, пять самолетов Ан-26, личного состава в общей сложности 350 офицеров и прапорщиков. Позже, в 1983 году, эскадрилью переименовали в отдельный авиаполк. К тому времени в ней уже стало 28 Ми-8, 20 Ми-24, отряд самолетов и отряд вертолетов Ми-26. Летали на войну днем и ночью в любых метеоусловиях. Иногда экипажам Ми-8 приходилось высаживать десант на крохотных площадках, которые едва находили с высоты 3500 метров.

В 1980 году Фарит Шагалеев был награжден орденом Октябрьской Революции.

13 апреля 1981 года на базе 4-й отдельной вертолетной эскадрильи была создана эскадрилья вертолетов Пограничных войск КГБ СССР под командованием подполковника Шагалеева. При выполнении боевых вылетов комэск проявил исключительную храбрость, летное мастер-

эшчәнлеген тәэмин итүнең бердәнбер чарасына әверелә. Бу бурычлар рәтенә җыелма сугышчан отрядлар гарнизоннарын боеприпаслар, азык-төлек, су һәм матди-техник чаралар белән тәэмин итү, транспорт колонналарын, маршруттагы маневр төркемнәрен һавадан каплап тору, һава разведкасы, мөҗәһитләрне база һәм складларына, ут нокталарына ракета-бомбалар ташлау, операцияләр уздырганда десант-штурм төркемнәрен илтү һәм төшерү, сугыш хәрәкәтләре вакытында һавадан ут белән ярдәм итү, үтерелгәннәрне һәм яралыларны эвакуацияләү керә. Сугышка очышлар көндез дә, төнлә дә, гади һәм катлаулы һава шартларында, таулы һәм тигезлекле урыннарга ясалып тора.

Чик буе гаскәрләре авиациясе барлык операцияләрдә диярлек кулланыла. Бик күп мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле хәрби көч буларак, вертолетларга аерым урын бирелә. Вертолетчылар бик еш җир өсте гаскәрләренә ярдәм итүнең бердәнбер чарасына, җиңүгә һәм яшәүгә бердәнбер өметкә әверелә. Шигалиевнның 16 вертолеттан торган подразделениесе Дүшәнбедә урнашкан була. Сугышчан командировкалар 40-50 көнгә сузыла. Аннан экипажлар берниндИ сугыш бармаган, төнлә йоклый торган, ә тынычлыкны кашыклап ашарга мөмкин булган әкияттәгедәй совет шәһәренә әйләнеп кайталар. Гаиләдә бик кадерле тоелган берничә тәүлек яшәү һәм кабат ут эченә китү…

– 1980 елның ахырында Гумбак кичүендә операция тәмамлана һәм аннан подполковник Фәйзиевның десант-штурм төркемен алырга кирәк иде, – дип искә төшерә Фәрит Солтан улы. – Анда 38 кеше булуы ачыкланды. Бу «Ми-8» сыйдыра алырлыктан күпкә артыграк. Ә иртәнгә кадәр аларны анда калдырырга ярамый – һәлак булачаклар…

Мин очып китү дистанциясен адымлап үлчәдем, кайсы ноктадан аерылып китәргә мөмкин булуын фаразладым. Экипажга нинди адымга баруыбызны аңлаттым. Сугышчыларның барысын да төядек. 700 килограмм артык авырлык килеп чыкты. Иң югары егәрлектә вертолетны берничә сантиметрга күтәрдем – эленеп тора. Йөгереп китү өчен күп дигәндә 35 метр ара бар. Алгы көпчәкләрдә күтәрелеп киттек. Тарлавыктан чыккач, округ авиация начальнигы Колокольников элемтәгә керде: «Фәрит, күпме алып кайтасың?» Барысын да алдым, дидем. Ышанмады бугай. Очып кайтып җиткәч, Колокольников үзе каршы алды, барысын да санап чыкты. Мин вертолеттан иң ахыргы булып төштем…

Апрельдә командование Дүшәнбе аэропортында 23 нче эскадрильяны оештыруга керешә. Эскадрильяда 18 «Ми-8», «Ми-24» вертолеты, 5 «Ан-26» самолеты, личный состав 350 офицердан һәм прапорщиктан торырга тиеш була. Соңрак, 1983 елда, эскадрильяны аерым авиаполк итеп үзгәртәләр. Ул вакытка анда инде 28 «Ми-8», 20 «Ми-24», «Ми-26» самолетлары һәм вертолетлары отряды була. Сугышка көндез дә, төнлә дә теләсә нинди һава шартларында очалар. Кайчакта «Ми-8» экипажларына десантны 3500 метр биеклектә көчкә эзләп табылучы бик кечкенә мәйданчыкларга төшерергә туры килә.

1980 елда Фарит Шагалиев Октябрь революциясе ордены белән бүләкләнә.

1981 елның 13 апрелендә 4 нче аерым вертолет эскадрильясы базасында подполковник Шагалиев команда-

ство и высочайший профессионализм. В марте 1981 года обнаружил в горах экипаж сбитого советского самолета и эвакуировал его. В октябре вывез окруженную душманами маневренную группу пограничных войск в составе 80 человек. Первым в СССР стал высаживать десанты на высоте свыше 3500 метров над уровнем моря, а затем стал выполнять это в ночное время. Вертолетчики участвовали не только в боевых действиях, экипажи спасали раненых, вывозили погибших.

– У меня было 238 вылетов по санитарному заданию – вспоминает Фарит Шагалеев.– Душанбинские медики говорили, что благодаря нам спасено до 80 процентов раненых. Представьте, что бойца тяжело ранили в живот. Если через шесть часов он не окажется на операционном столе, он умрет. Поэтому и в облачную погоду вылетали, и в туман. В ясную ночь плохо видны световые ориентиры, особенно зимой, когда снег дает подсветку. А в тумане и в облаках даже днем ходили только по приборам.

В декабре 1981-го в районе Дашти-Кала попала в засаду колонна БТР и БМП, следовавшая в район спецоперации. На подмогу вызвали авиацию. Первыми вылетела пара Шагалеева с ведомым, на машине которого висели САБы – осветительные бомбы. Пока бомбы медленно опускались на парашютах, на позиции душманов с неба лился шквальный огонь из всех видов бортового оружия ведущего. На земле не отставали, поддержка с воздуха – мощный заряд духа для наземных войск. Моджахедов быстро подавили, хватило двух вертолетов.

В 1982 году обстановка в Афганистане накалилась. Среднеазиатский пограничный округ получил несколько вновь сформированных мотоманевренных групп. В ходе серии операций «Долина-82» их ввели в страну и разместили в шести провинциальных центрах. В мае в районе Кафабского ущелья провели спецоперацию, которой руководил лично начальник погранвойск КГБ СССР генерал ар-

лыгында СССР КГБсының чик буе гаскәрләре вертолетлар эскадрильясы төзелә. Сугышчан очышлар вакытында эскадрилья командиры гаять зур кыюлык, очу осталыгы һәм иң югары дәрәҗәдәге профессионал булуын күрсәтә. 1981 елның мартында таулар арасында бәреп төшерелгән совет самолеты экипажын күреп ала һәм аны эвакуацияли. Октябрьдә чик буе гаскәрләренең дошманнар чолганышында калган 80 кешелек маневр төркемен алып чыга. СССРда беренче булып диңгез тигезлегеннән 3500 метр югарылыктагы биеклекләргә десантлар утырта, ә аннары моны төнлә дә эшли башлый. Вертолетчылар сугыш хәрәкәтләрендә генә катнашып калмыйлар, яралыларны коткаралар, һәлак булганнарны алып чыгалар.

– Санитар заданиеләр буенча 238 очыш ясадым, – дип искә ала Фәрит Шагалиев. – Дүшәнбе медиклары, сезнең аркада яралыларның 80 проценты коткарыла, дип әйтәләр иде. Күз алдына китерегез: сугышчының корсагы бик каты яраланган. Әгәр алты сәгатьтән соң операция өстәленә ятмаса, ул үләчәк. Шуңа күрә болытлы вакытта да очтык, томанда да. Аяз төннәрдә яктылык ориентирлары начар күренә. Бигрәк тә кыш көне, кар яктысы булганда. Ә томанда һәм болытлар эчендә хәтта көндез дә приборларга карап кына йөри идек.

1981 елның декабрендә Дәште-Кала тирәсендә махсус операция уздыру районына баручы БТР һәм БМПлардан торган колонна засадага эләгә. Ярдәмгә авиацияне чакыралар. Беренче булып Шагалиевлар пары кузгала. Ияреп баручы икенче машинага САБлар (яктырткыч бомбалар) асылган була. Аның бомбалары парашютларда әкренәкрен генә аска төшкән арада алдан баручы вертолетның бортында булган барлык кораллардан дошманнар позицияләренә ут ява. Җирдәгеләр дә кимен куймыйлар, чөнки күктән ярдәм булу җир өсте гаскәрләренең рухын күтәреп җибәрә. Мөҗәһитләрне тиз бастыралар, ике вертолет та җитә.



мии Вадим Матросов. В операции, длившейся 17 дней, задействовали 15 вертолетов Ми-8 и Ми-24. Летали парами. По первому вертолету душманы огонь не открывали: со второго видно, откуда бьют, можно нарваться на прицельный ответный огонь. Поэтому били по второй.

«Что такое «летать по-афгански?» – пишет командир вертолета эскадрильи Шагалеева Виктор Рыбаков. – Первое время, когда не было ПЗРК, летали на высоте 700-1200 метров. Когда появились «стингеры», летать на такой высоте стало опасно, у них дальность стрельбы почти 5 километров. Но не на восемь же тысяч подниматься! Сделали наоборот – ушли на предельно малые высоты, это позволяло и вероятность обнаружения уменьшить, и время прицеливания до минимума сократить. Идешь на высоте 3-5 метров неровно, рыскаешь вправо-влево… Пыль за тобою столбом, как дымовая завеса.

Шли рядовые боевые вылеты. Кто-то перевозил запчасти к технике, кто-то перебрасывал десант на перевалы, кто-то доставлял продовольствие и боеприпасы. В этот день мы четырьмя бортами полетели на север Афганистана в город Тулукан. На моем борту находились хлеб и колеса к БТР. Садились мы, как всегда, парами. Два вертолета разгружались, а два других барражировали в воздухе, прикрывая нас. Но в этот раз, как только солдаты приступили к разгрузке нашего вертолета, мы заметили вдалеке «уазик», который несся к нам на большой скорости. Чуть погодя из него вышли три офицера и афганец. По их взволнованным лицам стало понятно, что возникла какая-то сложная ситуация, требующая нашей помощи.

Прибывшие сообщили, что на северо-западной окраине Тулукана душманы сгоняют местных жителей – стариков, женщин и детей – и расстреливают их за то, что их мужья и сыновья перешли на сторону регулярной армии. Через несколько минут машина была в воздухе. Афганец сидел в вертолете на месте штурмана и показывал направление полета. Подлетев, мы увидели, как душманы расстреливают местных жителей. Увидев нас, они спрятались за дувалы. Сходу, заложив левый вираж и выправив вертолет, мы серией ракет стали обстреливать душманов. После второго захода посадили машину, но тут же поняли, что это решение было опрометчивым, так как по нам тут же открыли шквальный огонь. Взлетели вновь и совершили посадку в более безопасном месте. Как только колеса коснулись земли, к машине бросились жители. Старший лейтенант Владимир Сараев что-то им кричал, пытался успокоить, но толку от этого было мало. Толпа штурмовала вертолет. У людей, многие их которых были ранены, было одно спасение – наша машина.

Посадка жителей продолжалась, а душманы, скорректировав огонь, обстреливали вертолет автоматными очередями. Посоветовавшись с майором Николаем Мизиным, мы приняли единственно верное в данной ситуации решение – прикрыть посадку женщин и детей. Прижимаясь к земле, я отбежал метров на 25 и из небольшого углубления повел ответный огонь. Думается, душманы не ожидали отпора, на время их стрельба прекратилась. Патроны у меня быстро закончились, но я какое-то время все еще жал на спусковой крючок автомата.

Оглянувшись, увидел, что посадка закончилась и экипаж ждет меня. Запрыгнул в машину, и мы стали взлетать.

1982 елда Әфганстанда хәл катлаулана. Урта Азия чик буе округы яңа гына төзелгән берничә мотоманевр төркеме белән тулыландырыла. «Долина-82» операцияләре сериясе барышында аларны илгә кертеп, алты провинциаль үзәктә урнаштыралар. Майда Кафаб тарлавыгы буенда махсус операция уздыралар. Аңа СССР КГБ чик буе гаскәрләре начальнигы армия генералы Вадим Мотросов шәхсән үзе җитәкчелек итә. 17 көнгә сузылган операциядә 15 «Ми-8» һәм «Ми-24» вертолетлары катнаша. Пар-пар булып очалар. Дошманнар беренче вертолетка ут ачмыйлар, чөнки кайдан атулары икенче вертолеттагыларга күренә. Шуңа күрә икенчесенә төзәп аталар.

«Әфганча очу» нәрсә ул? – дип яза Шагалиев эскадрильясы вертолеты командиры Виктор Рыбаков. – Баштарак ПЗРК (зенит-ракета комплексы)  булмаганда, 700-1200 метр биеклектә оча идек. «Стингерлар» барлыкка килгәч, андый биеклеккә очу  куркыныч була башлады: аларның ату ераклыгы 5 чакрымга якын. Әмма 8 меңгә күтәрелмәссең бит инде! Киресенчә эшләдек – иң түбән биеклекләргә күчтек. Бу безнең күренү ихтималын да азайтты, төзәү вакытын да кыскартты.   3-5 метр биеклектә барасың, уңга-сулга чайкаласың… Синең артыңда багана булып тузан күтәрелә.

Көндәлек хәрби очышлар барган чак иде. Кемдер техникага запчастьлар күчерә, кемдер кичүләргә десантлар ташлый, кемдер азык-төлек һәм боеприпаслар илтә. Ул көне без дүрт вертолет Әфганстанның төньягындагы Тулукан шәһәренә очтык. Минем бортта ипи һәм БТР көпчәкләре иде. Без һәрвакыттагыча парлап төшеп утырабыз. Ике вертолет йөкне бушатканда, икесе безне каплап, һавада әйләнгәләп йөри. Ләкин бу юлы солдатлар безнең вертолетны бушата башлауга без ерактан безгә таба бик зур тизлектә килүче «уазик»ны күреп алдык. Бераздан аннан өч офицер һәм бер әфганлы төште. Аларның дулкынланган йөзләреннән ниндидер катлаулы хәл килеп чыкканын, безнең ярдәм кирәклеген аңларга була иде.

Килүчеләр Тулуканның төньяк- көнбатыш кырыенда дошманнар җирле халыкны – картларны, хатын-кызларны һәм балаларны куып чыгарып, аларның ирләре һәм уллары регуляр армия ягына чыккан өчен атып үтерәләр, дип хәбәр итте. Берничә минуттан машина һавада иде инде. Әфганлы вертолетта штурман урынына утырып, очу юнәлешен күрсәтеп барды. Килеп җиткәч, без дошманнарның җирле халыкны атканнарын күрдек. Безне күргәч, алар дуваллар артына качтылар. Килә-килешли үк сул як виражга кереп, вертолетны турылаганнан соң, без дошманнарга ракеталардан ата башладык. Икенче кат әйләнеп килеп, машинаны утырттык, ләкин шунда ук ялгышканыбызны аңлап алдык. Чөнки безгә өермәдәй ут ачтылар. Яңадан күтәрелеп киттек. Һәм куркынычсызрак урынга төшеп утырдык. Көпчәкләр җиргә тиюгә үк, машина янына кешеләр йөгереп килде. Өлкән лейтенант Владимир Сараев аларга нәрсәдер кычкырды, тынычландырырга тырышты, ләкин файдасы булмады. Халык вертолетка ябырылды. Күбесе яраланган, кешеләр өчен котылу урыны бер генә – безнең машина иде.

Без халыкны утыртканда, дошманнар вертолетка автоматлардан ата башладылар. Майор Николай Мизин белән киңәшеп алгач, без әлеге вәзгыятьтә бердәнбер дөрес карар кабул иттек: хатын-кызлар һәм балаларны утыртуны ут





Но вертолет был настолько перегружен, что слабо слушался управления, и мы еле-еле оторвали колеса от земли. Мирные жители были спасены. Развезли их по свободным от душманов кишлакам и благополучно вернулись на базу, где, подзаправившись боеприпасами, вновь взяли курс на Тулукан. В городе мы вновь сериями ракет обработали дувалы, в которых засели оставшиеся душманы, и только с наступлением сумерек вернулись на аэродром, где нас встретил наш командир Фарит Шагалеев».

За период участия в боевых действиях Шагалеев Ф.С. выполнил свыше 1200 боевых вылетов, имел 1600 часов боевого налета на вертолетах Ми-8 и Ми-24.

Указом Президиума Верховного Совета СССР от 8 апреля 1982 года за мужество и героизм, проявленные при оказании интернациональной помощи Демократической Республике Афганистан, подполковнику Шагалееву Фариту Султановичу присвоено звание Героя Советского Союза с вручением ордена Ленина и медали «Золотая Звезда».

Начиная с января 1982 года обстановка в Афганистане заметно осложнилась. Вооруженные преступления против установившейся власти стали принимать все более массовый характер. Около 40 процентов уездов и волостей северных провинций ДРА оказались под контролем оппозиции. В связи с этим была значительно увеличена группировка спецподразделений пограничных войск. Среднеазиатский пограничный округ получил семь вновь сформированных однотипных мотоманевренных групп, которые в ходе серии операций «Долина-82» были введены в Афганистан и размещены там.

В 1987 году Фарит Шагалеев окончил Военно-воздушную академию имени Ю.А. Гагарина. Еще несколько раз

белән каплап торырга. Җиргә сыенып диярлек, мин 25 метрлар читкә йөгердем һәм кечкенә генә чокырдан дошманнарга ут ачтым. Алар моны көтмәгәннәр иде, күрәсең. Атудан туктап калдылар. Патроннарым тиз бетте, ләкин мин күпмедер вакыт автоматның тәтесенә басып торуны дәвам иттем.

Борылып карагач, утырту тәмамланганны һәм экипажның мине көтеп торганын күрдем. Машинага сикереп мендем һәм без кузгала башладык. Ләкин вертолетта йөк шулкадәр артык иде ки, ул идарәгә буйсынырга теләмәде. Без көчкә-көчкә көпчәкләрне җирдән аердык. Халык коткарылды. Аларны дошманнар булмаган кышлакларга тараттык һәм әйбәт кенә базага әйләнеп кайттык. Анда боеприпаслар төяп, яңадан Тулуканга юл алдык. Шәһәрдә без кабат ракеталардан атып, калган дошманнар оялаган дувалларны чистарттык. Аэродромга караңгы төшкәндә генә кайтып җиттек. Анда безне командирыбыз Фәрит Шагалиев каршы талды».

Сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан чорында Ф.С.Шагалиев 1200 дән артык очыш ясаган, «Ми-8» һәм «Ми-24» вертолетларында 1600 сәгать очышы бар.

Әфганстан Демократик Республикасына интернациональ ярдәм күрсәткәндәге батырлыгы һәм каһарманлыгы өчен СССР Югары Советы Президиумының 1982 елның 8 апрелендәге Указы нигезендә подполковник Шагалиев Фәрит Солтан улына Советлар Союзы Герое исеме бирелә, Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медале тапшырыла.

1982 елның гыйнварыннан Әфганстанда хәл күзгә күренеп катлаулана. Анда урнашкан хакимияткә каршы кораллы җинаятьләр һаман арта бара. ӘДРның төньяк провинцияләрендәге өязләр һәм волостьларның 40 процент-



бывал в командировках в Афганистане, обеспечивал воздушное прикрытие вывода советских войск в 1988-1989 годах.

В 1987 же его назначают начальником службы безопасности полетов в Главном управлении пограничных войск КГБ СССР в Москве. Летом 1989-го переводят на Камчатку командовать авиацией Северо-Восточного пограничного округа. В 1993 году ему присвоили звание генерал-майора. Через год вернулся в Среднюю Азию командующим авиацией Группы пограничных войск в Таджикистане, где три года возглавлял боевые действия вертолетчиков, защищавших таджико-афганскую границу.

С 1997 года Фарит Султанович – в запасе. Работал помощником генерального директора ОАО «Камов», где курировал вопросы строительства летно-испытательного комплекса имени Чкалова.

ка якыны оппозиция контрольлегендә кала. Моңа бәйле рәвештә чик буе гаскәрләренең махсус подразделениеләре төркеме шактый арттырыла. Урта Азия чик буе округы яңа оештырылган, «Долина-82» операцияләре сериясе вакытында Әфганстанга кертеп урнаштырылган бер типтагы җиде мотоманевр төркемнәренә ия була.

1987 елда Фәрит Шагалиев Ю.А.Гагарин исемендәге Хәрби-һава академиясен тәмамлый. Тагын берничә тапкыр Әфганстанда командировкада була, 1988-1989 елларда совет гаскәрләрен чыгаруны һавадан каплап торуны тәэмин итә.

Шул ук елны аны СССР КГБ чик буе гаскәрләренең Мәскәүдәге баш идарәсенә очышлар куркынычсызлыгы хезмәте начальнигы итеп билгелиләр. 1989 елның җәендә Камчаткага Төньяк-Көнчыгыш чик буе округы авиациясенә командалык итәргә күчерәләр. 1993 елда аңа генерал-майор званиесе бирәләр. Бер елдан соң ул Урта Азиягә Таҗикстандагы чик буе гаскәрләре төркеме авиациясе командующие булып әйләнеп кайта. Анда өч ел таҗик-әфган чиген саклаучы вертолетчыларның сугыш хәрәкәтләренә җитәкчелек итә.

1997 елдан – Фәрит Солтан улы запаста. «Камов» ААҖнең генераль директоры ярдәмчесе булып эшләп, Чкалов исемендәге очу-сынау комплексы төзелеше мәсьәләләре буенча җаваплы була.







# ШАДРИН Роман Александрович

Родился 23 января 1963 года в станице Кутейниковской Зимовниковского района Ростовской области в крестьянской семье. После окончания средней школы и трех лет работы на производстве в 1984 году поступил в Казанское высшее танковое командное училище, которое окончил в 1988 году. Службу начинал в Группе советских войск в Германии. Ступени служебного роста – командовал танковым взводом, ротой, служил заместителем командира разведывательного мотострелкового батальона.

После объединения вследствие распада СССР и соцлагеря двух немецких государств – ГДР и ФРГ – батальон в 1993 году вывели в Волгоград и включили в состав Северо-Кавказского военного округа. На первой чеченской войне Шадрин был начальником штаба – заместителем командира 68-го отдельного разведывательного батальона 8-го армейского корпуса генерал-лейтенанта Льва Рохлина.

В составе группировки «Северо-Восток», затем «Север» батальон прорвался в Грозный 31 декабря 1994 года. В тяжелых боях в первые январские дни 1995 года батальон понес значительные потери, но во многом благодаря умелым действиям Романа Шадрина избежал разгрома, удержал захваченные позиции в Грозном, что благоприятно сказалось на ходе дальнейших боев.

1963 елның 23 гыйнварында Ростов өлкәсе Зимовниковский районы Кутейниковская станицасында крестьян гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлап, производствода өч ел эшләгәннән соң, 1984 елда Казан югары танк команда училищесына укырга керә, аны 1988 елда тәмамлый. Хезмәтен совет гаскәрләренең Германиядәге төркемендә башлый. Танк взводына, ротага җитәкчелек итә, мотоукчылар разведка батальоны командиры урынбасары булып хезмәт итә.

СССР һәм социалистик лагерь таркалу нәтиҗәсендә ике немец дәүләте ГДР һәм ФРГ берләшкәннән соң, 1993 елда, батальонны Волгоградка чыгарып, Төньяк Кавказ хәрби округы составына кушалар. Беренче чечен сугышы вакытында Шадрин штаб начальнигы – генерал-лейтенант Лев Рохлинның сигезенче армия корпусы 68 нче аерым разведка батальоны командиры урынбасары була.

«Северо-Восток», аннары «Север» төркемнәре составында батальон 1994 елның 31 декабрендә Грозныйга бәреп керә. 1995 елның беренче көннәрендә батальон зур югалтуларга дучар була, ләкин Роман Шадринның оста гамәлләре аркасында тар-мар ителүдән котыла, Грозныйда яуланган позицияләрен саклап кала. Шуннан соңгы сугышлар барышында моның бик файдасы тия.

10 января 1995 года капитана Шадрина назначили командиром 68-го отдельного разведывательного батальона. Изучив обстановку, комбат провел успешную операцию по захвату превращенного дудаевцами в хорошо укрепленный опорный пункт здания главпочтамта. 17 и 18 января Шадрин с группой бойцов в ходе упорных боев пробился к президентскому дворцу, а затем во главе штурмовой группы батальона в ночь с 18 на 19 января вышел в тыл боевикам, оборонявшимся в бывшем здании обкома партии в районе гостиницы «Кавказ». Здесь шадринцы попали в окружение и в течение двух суток отбили несколько атак противника. Своими действиями подразделение Шадрина помогло федеральным войскам взять здание обкома и подступиться к президентскому дворцу. Не останавливая наступления, Шадрин с группой из 27 разведчиков выбил дудаевцев из здания краеведческого музея и там закрепился. Разведчики отразили 11 атак боевиков, несколько раз сходились с ними врукопашную. Умелыми действиями разведчики во главе с комбатом Шадриным способствовали успеху других подразделений, штурмовавших гостиницу «Кавказ», а затем центр Грозного.

Комбат и его подразделение находились в прямом подчинении у командующего группировкой войск «Север» генерал-лейтенанта Рохлина, и поэтому ему поручались самые сложные боевые задачи. Находясь на острие боестолкновений, батальон нес потери. Газета «Коммерсантъ», ничтоже сумняшеся и не потрудившись перепроверить данные, опубликовала потери батальона Шадрина. По газете выходило, что потери батальона составили аж 85 процентов личного состава и 60 процентов техники. К счастью, это оказалось уткой, на которую так горазды иные либеральные журналисты. На самом же деле из состава батальона погибли 15 человек (3 офицера, 1 прапорщик и 11 сержантов и рядовых, 2 рядовых пропали без вести). В этом заслуга не только талантливого командующего Льва Рохлина, но и комбата Романа Шадрина, сумевшего сохранить своих солдат и офицеров. И не случайно еще в ходе боев ему было присвоено звание майора, а указом Президента РФ от 1 декабря 1995 года майору Шадрину Роману Александровичу присвоено звание Героя России. На его долю выпала и вторая чеченская война, и миротворческая миссия в Южной Осетии. И везде, где бы ни был, он проявлял себя как настоящий герой.

Роман Александрович не ушел в запас, а продолжает служить Отечеству. С 2008 года Герой России генерал-майор Шадрин – заместитель командующего войсками Уральского военного округа Внутренних войск МВД Российской Федерации.

1995 елның 10 гыйнварында капитан Шадринны 68 нче аерым разведка батальонына командир итеп билгелиләр. Вәзгыятьне өйрәнеп, комбат дудаевчылар тарафыннан яхшы ныгытылган терәк пунктка әйләндерелгән почта бинасын яулап алу буенча уңышлы операция уздыра. Гыйнварның 17е һәм 18ендә каты сугышлардан соң сугышчылар төркеме белән бергә Шадрин Президент сарае янына үтеп керә ала, ә аннары гыйнварның 18еннән 19ына каршы төндә батальонның штурмлаучы группасы башында торып, «Кавказ» кунакханәсе тирәсендәге элекке партия обкомы бинасына тупланган боевикларның тылына төшә. Шадринчылар монда камалышка эләгә һәм ике тәүлек буе дошманның берничә һөҗүмен кире кайтара. Шулай итеп, Шадрин подразделениесе федераль гаскәрләргә обком бинасын алырга һәм Президент сараена якын килергә ярдәм итә. Һөҗүм итүдән туктамыйча, 27 разведчиктан торган төркем белән Шадрин дудаевчыларны крайны өйрәнү музее бинасыннан бәреп чыгара һәм шунда урнаша. Разведчиклар боевикларның 11 һөҗүмен кире кайтара, берничә тапкыр кара каршы сугыша. Комбат Шадрин җитәкчелегендәге разведчиклар, оста хәрәкәт итеп, «Кавказ» кунакханәсен, ә аннары Грозный үзәген штурмлаган башка подразделениеләрнең уңышка ирешүенә ярдәм итә.

Комбат һәм аның подразделениесе «Север» гаскәрләре төркеме командующие генерал-лейтенант Рохлинга турыдан-туры буйсына, шуңа күрә иң катлаулы хәрби бурычларны үтәү аңа тапшырыла. Батальон шактый гына югалтуларга дучар була. Мәгълүматларны яңадан тикшереп тә тормыйча, «Коммерсантъ» газетасы Шадрин батальонының югалтуларын бастырып чыгара. Газетада батальон личный составның 85 процентын һәм техниканың 60 процентын югалткан дип языла. Бәхеткә, бу хәбәр дөрес булып чыкмый. Чынлыкта батальонның 15 кешесе (3 офицер, 1 прапорщик, 11 сержант һәм рядовой) һәлак була һәм 2 рядовой хәбәрсез югала. Бу – талантлы командующий Лев Рохлинның гына түгел, үзенең солдат һәм офицерларын саклап кала алган комбат Роман Шадринның да казанышы. Сугышлар барган вакытта ук аңа майор званиесе бирелү юкка гына түгел. Ә РФ Президентының 1995 елның 1 декабрендәге Указы нигезендә Шадрин Роман Александровичка Россия Герое исеме бирелә. Икенче чечен сугышы да, Көньяк Осетиядәге тынычлык урнаштыру миссиясе дә аның өлешенә тия. Кайда гына булса да, ул үзен чын геройларча тота.

Роман Александрович запаска чыкмый, Ватанга хезмәтен дәвам иттерә. Россия Герое генерал-майор Шадрин 2008 елдан бирле Россия Федерациясе ЭЭМның Эчке гаскәрләре Урал хәрби округы гаскәрләре командующие урынбасары булып тора.







## ШАРПАТОВ Владимир Ильич

Родился 21 марта 1940 года в поселке Красногорский Звениговского района Республики Марий Эл. После окончания средней школы решил поступить в летное училище, однако первая попытка оказалась неудачной. Проработав некоторое время столяром, водителем, упрямый юноша решил вновь попытать счастье. Оно улыбнулось парню – он поступил в Казанский авиационный институт на вечернее отделение. Мечта о небе привела Владимира в Казанский аэроклуб, и он одновременно с учебой в институте освоил мастерство планериста. Оставив после трех курсов институт, Владимир отправился в Краснокутское летное училище гражданской авиации, которое успешно окончил в 1965 году.

Работать по распределению поехал в Тюмень, где за многие последующие годы приобрел солидный летный опыт. Почти в восьмидесяти государствах побывал его самолет. За плечами были сотни налетанных часов и тысячи тонн перевезенных различных грузов.

В 1971 году Владимир поступает в Университет гражданской авиации и по его окончании получает специальность инженера-пилота. После развала Советского Союза многие советские летчики вынуждены были искать работу в различных странах мира. Так судьба забросила Шарпатова в Объединенные Арабские Эмираты. Работая в акционерной компании «Аэростан», экипаж 2 сентября, загрузив в Албании 1200 ящика патронов для автомата Калашникова с китайской маркировкой, взял курс на город Баграм Северного Афганистана. Груз предназначался правитель-

1940 елның 21 мартында Мари Иле Республикасының Звенигов районы Красногорский бистәсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, очучылар училищесына укырга керергә тели. Ләкин аның беренче омтылышы уңышсыз булып чыга. Күпмедер вакыт столяр, машина йөртүче булып эшләгәннән соң, үҗәт яшүсмер яңадан бәхетен сынап карарга була. Бу юлы аңа бәхет елмая: ул Казан авиация институтының кичке бүлегенә укырга керә. Һавада очу турындагы хыялы Владимирның Казан аэроклубына китерә, һәм ул институтта уку белән бергә планерчы осталыгын да үзләштерә. Өченче курсны тәмамлагач, Владимир институтны калдырып, Краснокутскидагы гражданнар авиациясе очучылар училищесына китә. Аны 1965 елда уңышлы гына тәмамлый.

Аны эшкә Төмәнгә җибәрәләр, шунда озак еллар эшләп, зур тәҗрибә туплый. Аның самолеты 80 гә якын дәүләттә була. Шулвакыт эчендә ул йөзләрчә сәгать очыш ясый һәм меңләгән тонна төрле йөкләр күчерә.

1971 елның Владимир гражданнар авиациясе университетына керә һәм аннан инженер-пилот белгечлеге алып чыга. Советлар Союзы таркалгач, бик күп совет очучылары чит илләрдән эш эзләргә мәҗбүр ителә. Шарпатовны да язмыш Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә илтеп ташлый. «Аэростан» акционерлык компаниясендә эшләгәндә, 2 нче сентябрь көнне экипаж Албаниядә Калашников автоматлары өчен 1304 әрҗә патрон төяп, Төньяк Әфганстанның Баһрам шәһәренә курс ала. Йөк хөкүмәт гаскәрләре өчен

ственным войскам. Маршрут был знакомым, и казалось, что никаких неожиданностей не должно было быть. Однако на подлете к Кандагару, который контролировался вооруженным движением «Талибан», Ил-76 с бортовым номером 76842 принудили к посадке. Талибы находились в состоянии войны с правительственными войсками, и именно они выслали на перехват МиГ-21, вооруженный ракетами.

Так был захвачен талибами самолет Ил-76. Начались изнурительные дни плена, продолжавшегося более года. Усилия дипломатов, в том числе и Татарстана, обращения в различные международные организации результатов не давали. И тогда экипажем овладела мысль о побеге. Охранявшим им талибам пленникам удалось внушить мысль о том, что без профилактики и регулярного техобслуживания самолет вскоре безнадежно выйдет из строя.

Итак, в один из августовских дней 1996 года во время очередного техобслуживания экипажу захваченного талибами Ил-76 удалось обмануть охрану и поднять машину в воздух.

Чтобы представить, как все происходило с самого начала, воспользуемся дневником Владимира Шарпатова, который он вел в плену.

«15 сентября 1995 года. 40 дней как мы здесь. С утра пришел старый проповедник, который хотел выучить нас Корану. Взамен обещал походатайствовать о нашем освобождении. Я высказал свое сомнение…

17 сентября. С утра попросили переводчика, чтобы вызвал Красный Крест. У меня постоянная головная боль. Таблетки помогают на 2-3 часа, но ведь не будешь глотать их постоянно. Это скорее всего от нервов и от жары. Не дай бог в моем возрасте попадать в подобные переделки, нас бросили все: МИД, Россия, а уж Ельцину, похоже, вообще наплевать. Он в одной Чечне теряет ежедневно больше людей, чем наш экипаж…»

Такие мысли приходили скорее от отчаяния и незнания реальности. В действительности же предпринимались все возможные меры и по разным каналам. В результате Совет безопасности ООН дважды выдвигал требование освобула. Маршрут таныш булгач, аларга бернинди көтелмәгән хәлләр дә килеп чыкмас кебек тоела. Ләкин «Талибан» контроле астындагы Кандагарга якынлашканда (сноска) ...



була. Маршрут таныш булгач, аларга бернинди көтелмәгән хәлләр дә килеп чыкмас кебек тоела. Ләкин «Талибан» кораллы хәрәкәте контрольлегендә булган Кандагарга килеп җитәрәк, 76842 номерлы «Ил-76»ны утырырга мәҗбүр итәләр. Талиблар хөкүмәт гаскәрләре белән сугыш халәтендә тора, һәм нәкъ менә алар самолетны эләктерү өчен, ракеталар белән коралланган "МИГ-21" истребителен җибәрәләр.

Елдан артыкка сузылган җәфалы әсирлек көннәре башлана. Дипломатларның, шул исәптән Татарстанныкыларның да тырышлыклары, төрле халыкара оешмаларга мөрәҗәгать итүләр нәтиҗә бирми. Шуңа күрә экипаж качарга дигән карарга килә. Үзләре саклап торган талибларны әсирләр, даими рәвештә техник карау үткәрәп тормасаң, тиздән самолет эштән чыгачак, дип ышандыра алалар.

Димәк, 1996 елның август көннәренең берсендә чираттагы техник карау вакытында талиблар кулга төшергән «Ил-76»ның экипажына сакчыларны алдап, машинаны һавага күтәрү насыйп була.

Баштан ук хәлләрнең ничек булганын күз алдына китерү өчен Владимир Шарпатов әсирлектә язып барган көндәлеккә күз салыйк.

«1995 елның 15 сентябре. Безнең монда булуыбызга 40 көн узды. Иртүк карт мулла килде. Безне Коръән укырга өйрәтергә теле. Шуның бәрабәренә безне азат итәргә булышырга вәгъдә бирә. Мин үземнең шикләнүемне әйттем…

17 сентябрь. Иртә белән тәрҗемәчедән Кызыл Хач чакырыун үтендек. Минем һаман башым авырта. Таблеткаларның тәэсире 2-3 сәгатькә җитә, ләкин аларны бертуктаусыз эчеп торып булмый бит инде. Мөгаен, бу нервыдан һәм кызуданды. Минем яшьтәге кешеләрне мондый хәлләргә төшүдән Алла үзе сакласын. Безне барысы да ташлады: Тышкы эшләр министрлыгы, Россия, ә Ельцин гомумән, төкереп тә бирми бугай. Ул бер Чечняда гына да көн саен безнең экипажга караганда күбрәк кеше югалта...»

Мондый фикерләр аларның башына гаҗизлектән һәм чынбарлыкны белмәүдән килә. Чынлыкта исә төрле каналлар буенча мөмкин булганның барысы да эшләнелә.

бодить экипаж. Министр иностранных дел РФ обращался к руководству Саудовской Аравии и Пакистану, в Организацию исламских государств за содействием по освобождению экипажа. Несколько раз в Кандагар приезжали представители российского МИДа и посольства в Пакистане.

Президент и правительство Татарстана также не оставляли без внимания экипаж. В Кандагар неоднократно выезжал советник Президента РТ по международным делам Тимур Акулов. Были собраны деньги на выкуп пленников – 2,4 миллиона долларов, а Мунир Файзуллин, менеджер компании «Аэростан», с риском для жизни возил продукты, почту, пароли для побега. Но все попытки освободить экипаж оставались тщетными.

«…Сентябрь 1995 года. Исполнилось 50 дней плена. Торжественная дата с черной каймой… Радио «Голос России» сообщило о некоем «позитиве» в отношении нас. Через час еще весть: талибы предъявили ультиматум Кабулу, чтобы в течение пяти дней правительственные войска сдались. Иначе штурм Кабула. Самолет и экипаж освободят в обмен на списки шести тысяч афганцев, якобы угнанных в СССР.

…Октябрь 1995 года. Вроде началось наступление на Кабул. Исполнилось 70 дней плена. Ельцин встречается с Клинтоном. Может, поднимет наш вопрос?

Ноябрь 1995 года. Сегодня исполняется 100 суток нашего плена. Поймал по волнам «Радио России» известие, что Шаймиев встречался с послом Пакистана. Российские усилия мне кажутся дымзавесой. Я подумал, что реально пытаются нас освободить только Шаймиев и его команда.

Декабрь 1995 года. 130 дней плена и бесконечных ожиданий. Вечером нас буквально ошарашил Ельцин. Он заявил о "личном контроле" за освобождением французских летчиков, сбитых в Югославии во время бомбежки мирных жителей. А как же мы? Мы не бомбили, не стреляли. Нас на полет толкнули нужда и безработица.

Радио сообщило: французские летчики найдены, освобождены и переданы своим! При посредничестве России!.. Все благодарят Ельцина за благородство и участие…

Январь 1996 года. Перед ужином пришли Али-Хан (начальник охраны) с муллой Сулейманом. Мы стали их спрашивать о возможности побывать на самолете для смазки шасси и шарниров. Ничего не ответили.

Март 1996 года. Вновь радионовости: Хекматиар объединился с Раббани, и они собираются наступать на талибов. Чем это обернется для нас? Талибское радио сообщило, что нас может отпустить только афганский народ.

Апрель 1996 года. Кабул, по вестям «Голоса России», готовится к широкомасштабным операциям. Весь вчерашний день шли ожесточенные бои в центральной провинции. Все утро кричат громкоговорители. Наверное, талибы собирают ополчение.

Заявились к нам молодой профессор Корана, три охранника и корреспондент Би-би-си по арабскому региону. Фотографировать нас ему запретили, но кадра три корреспондент успел сделать. Его мнение: Россия занимается нами плохо, а талибы стараются как можно быстрее освободить нас. Всяк, в общем, врет по-своему. Профессор объясняет наш долгий плен тем, что Россия помогает Раббани, что, конечно, не по нраву талибам.

БМОның Куркынычсызлык советы ике тапкыр экипажны азат итү таләбе белән чыга. РФ тышкы эшләр министры Согуд Гарәбстаны һәм Пакьстан җитәкчелегенә, Ислам дәүләтләре оешмасына экипажны коткаруда ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итә. Кандагарга берничә тапкыр Россия Тышкы эшләр министрлыгы һәм Пакьстандагы илчелек вәкилләре килеп китә.

Татарстан Президенты һәм Хөкүмәте шулай ук экипажны игътибарсыз калдырмый. Кандагарга ТР Президентының халыкара эшләр буенча киңәшчесе Тимур Акулов берничә тапкыр бара. Әсирләрне сатып алу өчен 2,4 миллион доллар акча җыела. Ә «Аэростан» компаниясе менеджеры Мөнир Фәйзуллин, гомерен куркыныч астына куеп, азык-төлек, почта, качу өчен парольләр илтә. Ләкин экипажны азат итүнең бөтен омтылышлары файдасыз була.

«...1995 елның сентябре. Әсирлекнең 50 көне тулды. Кара каймалы тантаналы көн... «Голос России» радиосы безгә карата ниндидер «позитив» булуы хакында хәбәр итте. Бер сәгатьтән яңа хәбәр: талиблар, биш көн эчендә хөкүмәт гаскәрләре бирелсен дип, Кабулга ультиматум куйган. Юкса, Кабулны штурмлаячаклар икән. Самолетны һәм экипажны имештер СССРга куып алып кителгән алты мең әфганлы исемлегенә алмашып кына азат итәчәкләр.

...1995 елның октябре. Кабулга һөҗүм башланган, ахрысы. Әсирлекнең 70 көне тулды. Ельцин Клинтон белән очрашкан. Бәлки, безнең мәсьәләне күтәрер?

1995 елның ноябре. Бүген безнең әсирлектә булуыбызга 100 тәүлек тула. «Радио России» дулкыннарыннан Шәймиевнең Пакьстан илчесе белән очрашуы турында хәбәр тоттым. Россиянең тырышлыклары миңа күзгә төтен җибәрү генә булып тоела. Безне азат итәргә чын-чынлап бары тик Шәймиев һәм аның командасы гына тырыша, дип уйлап куйдым.

1995 елның декабре. Әсирлекнең һәм иге-чиге булмаган көтүнең 130 көне. Кич белән безне Ельцин шаккатырды. Ул тыныч халыкны бомбага тотканда Югославиядә бәреп төшерелгән Франция очучыларын азат итүне «шәхси контролендә» тотачагын игълан итте. Ә без нәрсә? Без бомбага тотмадык, атмадык. Очарга безне мохтаҗлык һәм эшсезлек мәҗбүр итте.

Радио хәбәр итә: Франция очучылары табылган, коткарылган һәм үзләренекеләргә тапшырылган! Россия арадашлыгы белән!.. Киң күңеллелеге һәм хәлгә керә белүе өчен барысы да Ельцинга рәхмәт укый...

1996 елның гыйнвары. Кичке аш алдыннан Сөләйман мулла белән Али-Хан (сакчылар начальнигы) килделәр. Без алардан самолетка барып, шасси һәм шарнирларны майларга мөмкин булырмы икән, дип сорадык. Җавап бирмәделәр.

1996 елның марты. Тагын радиодан хәбәр ишетелә: Хикмәтияр Раббани белән берләшкән, алар талибларга һөҗүм итәргә җыеналар. Безнең өчен бу ничек булып бетәр? Талиблар радиосы безне бары тик әфган халкының гына җибәрә алуын хәбәр итте.

1996 елның апреле. «Голос России» хәбәрләренә караганда, Кабул киң масштаблы операцияләргә әзерләнә. Кичә көн буе үзәк провинциядә каты сугышлар барды. Иртәдән бирле громкоговорительләр кычкыра. Мөгаен, талиблар ополчение җыялардыр.

Июнь 1996 года. Радио передает: правительственные войска отбили атаку талибов. Узнали от Мунира, что прибывшие в Кандагар полевые командиры талибов требовали нашего «сидения», некоторые даже грозились взорвать самолет и нас.

